# ТАТАР КЫЗЫ

Соңгы көннәрдә Җаһидә бик күңелсезләнде, аның кәефе китте, шул мәгълүм бер мәсьәлә аркасында, әнисе белән икесе арасындагы элеккеге самимилек юкка чыккан кебек булды. Бу хәл Җаһидәне бик тә борчый иде. Ләкин әнисенең таләбен кабул итү дә аңа мөмкин булмаган бер эш кебек күренә.

Әнисе кызын борынгы затлы нәсел, пашазадәләр токымыннан булган, бүгенге көндә исә, тәэминатчы буларак яхшы гына акча эшләп, абруйлы урын казанган Лотфи бәйгә кияүгә бирергә бик тә тели иде.

Кыска буйлы, черек тешле, хатыннарныкы кебек нечкә тавышлы, өзлексез «моң шер» дип, француз сүзләрен бик еш кыстырып сөйләшүче бу әфәндене Җаһидәнең җене сөйми иде. Бигрәк тә, күрешкәндә учының тирләгән булуы аңа карата нәфрәт хисе уята иде. Һәм никадәр генә тырышса да, ул яһүд маклерына охшаган шул булыр-булмас асылзадәне үзенең ире сыйфатында күз алдына да китерә алмый иде.

Ире кем булса да булсын, аның өчен барыбер, тик иң әүвәл аның буе-сыны Җаһидәнекеннән озын булсын, ул көчле ир булсын. Сөйләшүе ачык, тавышы чын ирләрнекечә көр чыксын. Шулай да ул бераз кырыс, аның бөтен рәвешеннән куәт-кодрәт бөркеп торган, мөлаем карашлы, әмма әмиранә горур ир булырга тиеш иде.

Лотфи бәйдә боларның берсе дә булмаганы кебек, киресенчә, ул Җаһидәнең гел ачуын чыгара торган хатыншак йөрешле иде. Аның борынгыдан килгән асылзатлылыгы да, бүгенге тәэминатчылыгыннан кергән байлыгы да Җаһидәнең җирәнүен капларлык дәрәҗәдә кодрәтле түгел иде.

Әнисе белән икесе арасындагы фикер каршылыгының да шул бер ноктага тупланoccurs аның җанын телгәли. Җаһидә әнисенә бик тә бурычлы һәм аңа бик тә бәйле иде. Әмма әнисенең һәрвакыт акчасызлыкта яшәп, шул кысанлыктан котылып, тыныч тормыш корыр өчен дип, аны шул никахка ирексезләргә мәҗбүр икәнлегенә ул ышана алмый иде.

Әнисенең аны укытып-тәрбия итәр өчен фидакарьләрчә эшләвен, яман мохиткә иялəшмәс өчен хәтта иреннән аерылганын күз алдына китергәннән соң, һәр җәһәттән өлгергән кызы киләчәктә яхшы тормыш корсын, дигән булып, икмәк, сыр бәясенә аны корбан итү ихтималын башына да китерә алмый иде.

Анасының яп-яшь кызын шундый килешсез кешегә кияүгә бирергә атлыгып торуын яшьлеге аркасында Җаһидә аңламый торган бер сердер, бәлки. Ләкин ни булса да, Җаһидә Лотфины ир буларак кабул итә алмый. Єнисе исә шул фикергә ябышкан да мәҗбүрләвен дәвам итә.

Баштарак алар бу турыда үзара тыелып кына, сабыр гына сөйләшкән булса, соңгы атналарда аларның сөйләшүе ачыктан-ачык гауга рәвешен ала башлады. Көннәр буе дәвам итеп килә торган бу гауга Җаһидәне әкренләп борчуга салды.

Бүген янә шул турыда сүз биш-ун тапкыр кабатлангач, Җаһидә башын ял иттерергә, шул ук вакытта мохитне алыштыру уе белән Адаларга китәргә карар кылды. Єнисе дә, «үз башы белән уйлап карар өчен уңай форсат булыр», дип, аңа юл куйды...

Берничә көн дәвамында кирәк булачак әйберләрен кечкенә букчасына җирләштереп, элеккеге дуслары мадам Марикаларда кунак булырга дип, ул Адаларга йөри торган көймәгә утырды. Ләкин башындагы уй Җаһидәгә һич тә тынгылык бирмәде. Укый башлаган романын ул тагын дәвам итәргә булды. Ләкин игътибарын китапка туплый алмады.

Гәзитә сатып йөрүчедән ул тагын бер мәҗмуга сатып алды. Анда да ул башына төшкән уен оныттырырлык бер генә сүз дә табалмады. Әкрен-әкрен генә тирә-юненә караштыргалап, ул салондагы юлчыларны күзәтә башлады. Берсе дә таныган-белгән адәмнәр түгел иде. Менә хәзер аның янында берәр апасы яки чын аркадашы булса, юл йөргәндә бик тә яхшы булыр иде. Атасы булса, бәлки анасы белән аңлашуы җиңелрәк булыр иде. Ата кеше белән кыз кеше шушындый мәсьәләләрдә романнарда да ачыктан-ачык сөйләшми. Әмма Җаһидә бу хакта ап-ачык итеп атасына сөйләгән булыр иде.

Әгәр атасы булса, акча кытлыгы, анасының кечкенә мәктәпләрдә мөгаллимә булып эшләп алган акчага яшәү мәҗбурияте булмас иде. Хәтта Лотфи бәй мәсьәләсе турында сөйләшү дә булмас иде. Гаҗәп сәер, минем атама ни булды икән? Дәү әнием сөйләгәнчә, чыннан да, ул бөтен кешелек хисләреннән мәхрүм Чыңгыз сугышчысының токымыннан калган вәхши татар булганмы? Әгәр бу дөрес булмаса, ни өчен ул кызын ташлап, шушындый хәлдә калдырган һәм аның укуы- тәрбиясе турында кызыксынмаган һәм ничек итеп мәктәпне бетергәнченә кадәр ул кызын, ичамасам, бер тапкыр да эзләп карамаган?

Дәү әнисе белән Зөһрә җиңгәсе үзара ызгышкан вакытта: «Җылан хатын! Үз капризың өчен үз кызыңны иреннән аерттырдың, алтындай Җаһидәне ятим иттең», дигәне исенә төште. Әгәр бу хак булса, ни өчен атам мине эзләп тапмаган? Ул мине эзләгәндер, ләкин табалмагандыр; бәлки ул Истанбулга күчмичә, Анадолуда калгандыр; бәлки мине атамнан яшереп тотканнардыр, дип уйлады.

Сабый чагында ул чегәннәрнең кеше әйберсен урлаган карак балаларын ничек итеп качырганнарын күргәләгән иде. Аның үзен дә әбисе белән анасы ишектән, тәрәзәләрдән чыгарып, кемнәндер яшергәләгәннәрен исенә төшерде. Үсә барган саен үзләренә килгән бер генә хатны да ачып карарга рөхсәт итмәгәннәрен хәтерләде. Ул аңламаган нәрсәләр, серләр бар иде.

Бу уйларыннан ул тиз генә котыла алмады, шул чак ишектән унике-унөч яшьләрендәге ике укучы кыз бала, кабалана-кабалана эчкә кереп, Җаһидә янындагы буш урынга утырдылар. Сөйләшә башлаган сүзләрен дәвам иттеләр. Сөйкемле кызларның кош сайраган кебек тавыш белән мәктәп һәм сыйныфтан сыйныфка күчү мәсьәләләре турында чөкердәшкәннәре Җаһидәне ирексездән кызыксындыра башлады. Үзенең дә көндәлегеннән башка кайгысы булмаган бәхетле сабый чагы күз алдына килде. Сабыйларның сүзенә колак салды. Тыңлаганын сиздермәс өчен, ул китап битләрен актара башлады.

Кызларның берсе үзенең көндәлегендәге билгеләрдән канәгать түгел иде:

— Хәзер ничек итеп әнигә күрсәтермен инде? Ул гына да түгел, бүген әти дә кайтырга тиеш, җә, ничек итеп мин бу көндәлекне аңа күрсәтермен? Бәй атам: сыйныфны яхшы бетер, сиңа кул сәгате алып бирермен, дигән иде. Хәзер ни булачак?

Зуррак кыз:

— Сыйныфтан күчтең бит инде, ни булсын?— диде.

— Күчтем күчүен, әмма мондый күчүне мин теләмәгән идем.

— Теләмәгән булсаң, тырышырга кирәк иде.

— Минме тырышмадым? Мин географиядән бөтен нәрсәне беләм. Елгаларны, тауларны, иң биек тау түбәләрен. Әмма тозны кайдан чыгаралар? Мин белмим... Шул да булдымы имтихан? Тоз азык- төлек кибетеннән чыга.

Кызлар букчаларыннан көндәлекләрен чыгарды. Көймә кузгалганга байтак вакыт узды. Җаһидә, бу кызлар белән сөйләшеп, аларның кечкенә мәшәкатьләре белән мәшгуль булып, үзенең олы исәбен оныттырырлык бер чара эзли иде.

Балаларга мөрәҗәгать итеп ул:

— Кайсы мәктәптә укыйсыз? — дип сүз башлады. Кызлар беравыздан:

— Нишан-ташы мәктәбендә укыйбыз, — диде.

— Көндәлегегезне карарга мөмкинме?

Икесе берьюлы, бик теләп, көндәлекләрен Җаһидәгә суздылар.

Җаһидә беркайчан да ишетмәгән-белмәгән нәсел исемнәре белән рәттән кызларның берсе Сөем, икенчесе Гөлчәчәк атлы икәнен белде. Көндәлектәге билгеләргә күз ташлады.

— Машаллаһ! Яхшы билгеләр алгансыз, ә ни өчен бик борчыласыз?— диде.

Гөлчәчәк дигәне:

— Мин географияне бик яхшы беләмен. Әмма «тугызлы» гына алдым... Тырышлыгым өчен «алтылы» гына куйды.

— Булгалый инде андый хәлләр, ләкин бу борчылырлык нәрсә түгел.

— Әлбәттә, бочылырлык нәрсә түгел, әмма әти ни әйтер бит әле?

— «Әти» ни дигән сүз ул?
Сөем:
— Без атабызга «әти» дибез, анабызга «әни» дип дәшәбез, —
Гөлчәчәк исә:
— Без—татарлар, — диде.
Җаһидә кызларга игътибарлабрак карады:
— «Татар» дигәнегез ул нәрсә тагын, барыбыз да төрек түгелмени? Инде хәзер албаны, бушнәкләре калмады — барыбыз да төрек түгелмени? — диде.
Кечерәк кыз:
— Юк! Безгә һәр җирдә «татар» диләр. Мәктәптә дә, урамда да... Без татарлыгыбызны яшермибез дә. Анамыз да, атамыз да татар, — диде.
Бу сабый кызларның самимилеге, ачык сүзле булулары Җаһидәнең хушына китте:
— Татар белән төрек арасында нинди аерма бар? Зинһар, аңлатып бирегезче, — диде Җаһидә.
Кече кыз:
— Татарлар икейөзле була белми. Алар тугры сүзле, тырыш инсаннардыр, — диде.
Олы кыз:
— Бераз кырыс, әмма бик самими кешеләр, — диде. Алар юл буе шулай сөйләшеп барды.
Җаһидә боларның аталары мөһәндис булып эшләгәнен һәм моңа чаклы Анадолуның төрле җирләрендә хәрби мөһәндислек кылганын, кызларның бүгенгә чаклы Анадолуның төрле бистәләрендә укыганнарын, бары тик быел гына Истанбулга күчеп килгәннәрен белде.
Аларның ата-аналары белән булган мөнәсәбәтендә моңа чаклы күрелмәгән хөрмәт һәм самимият хөкем сөргәнлеген күрде. Болар Җаһидә өчен өр-яңа нәрсәләр иде. Ул кызларга татарча шигырь сөйләтте, ашый торган ризыклары турында сораштырды. Аларның гореф-гадәтләрен өйрәнергә теләде. Кызлар бик теләп, самимилек белән барысын да сөйләп бирделәр. Җаһидә дә башына төшкән уйларыннан арынды. Шул рәвешле сәяхәт тә ахырына килеп җитте. Һәйбәлия тукталышына килеп җиткәч, кызлар эрҗиңкә туп кебек сикерә- сикерә пристенгә төштеләр дә юк булдылар. Җаһидә әкрен-әкрен генә мадам Мариканың өенә таба юл тотты. Марика Җаһидәне ачык чырай белән каршы алды.
— Ялгыз килдеңме? Анаң кайда? Хәлләре яхшыдыр, шәт? — дип хәл-әхвәл сораштырды.— Хәзер мин сиңа каһвә әзерләп, сине Катина бүлмәсенә урнаштырырмын. Кечкенә инде, әмма нишләмәк кирәк. Тормыш бик кыйбатланды. Сез яшәгән бүлмәләргә акча бәрабәренә кеше кертергә мәҗбүр булдым. Анаң килгәч, багарбыз, берәр ни кылырбыз. Катинадан һич хәбәр юк. Бер ни белмимен ки, кызчыкка ни булды икән? Без- аналар балаларны мең мәшәкать белән үстерәбез, шуннан соң алар аналарын оныта, — диде, күзеннән яңагына тәгәрәгән ике тамчы күз яшен силпеп алды. Бу сүзләр Җаһидәне бик тә әсәрләндерде.
— Юк, мадам! Катина сезне һич онытмас? Беләсез бит, нормаль рәвештә хат алышу бозылды. Кем белә, ул да шулай өзгәләнә торгандыр!
— Барысы да шулай ди... Сау гына булсын да бит! «Коткарылыш» көймәсе белән бер хат юлладым, бәлки җавап килер. Кыз баланы еракка җибәрү дөрес нәрсә түгелдер, әмма шулай килеп чыкты менә. Сез- кызлар, аналарны тыңламыйсыз.
Җаһидә янә кызарды.
— Нигә болай дисез, мамам Марика? Катинаны сез үз теләгегез белән Юнанстанга күндермәдегезмени? Катинаның Истанбулдан аерылырга һич тә нияте юк иде.
— Әлбәттә, әлбәттә!
Мадам Марика Җаһидәне иң югаргы каттагы бүлмәгә менгезде. Күрше бакчасына карый торган тәрәзәне ачты, аның карашы Катинаның диварга асылган рәсеменә төште. Янә дә күзеннән аккан яшьләр аның йөзен чылатты. Шулчак күрше бакчада нининдер тавыш

ишетелде. Хәрбиләр чалбары кигән, кыска җиңле күлмәктән, урта яшьләргәге бер ир, төтенләп торган галәмәт зур самавырны күтәргән, аның артыннан тугыз-ун яшьләрендәге бер углан мич торбасы кебек бер торба тоткан килеш, бакча уртасына таба баралар иде. Бераз арттарак дүрт-биш яшендәге бер сабый-углан агачтан ясалган уенчык атын әйдәкли:

— Көймә китә... Атауга бара торган көймә.., — дип атасы белән абыйсы артыннан чаба иде.

Ир кеше самавырны зур гына бер нарат астына куйды. Олы углан самавырның астагы тишекләренә очкыннар чыгарырдай итеп өргәчтен, зур торбаны самавырның башына куйды.

Төпчек бала:

— Цемент заводының торбасы кебек булды бу. Әти! Без көймәле уйныйбыз, мин капитан булам, — диде.

Җаһидә «әти» сүзен кабат ишеткәч:

— Мадам, болар кем? — дип сорады. Мадам Марика:

— Хулуси бәйләрдә фатирда торучылар, ата кеше бүген кайтты. Һәркөн шушы вакытта чәй эчә башлыйлар. Ничек итеп кенә эчәләр әле!.. Беркөнне дикъкать иттем, әнә шул кечкенә бала өч чокыр эчте. Кунак килсә, төн уртасына чаклы самавыр янында утыралар. Янгын чыгармагайлары дип куркам, әмма җаен беләләр булыр, хатыны бик тә пөхтә... Татарлар, имеш, — диде.

Аның сүзләрен куәтләгәндәй, кулына тустаганнар, чәй әсбаплары, икенчесе ашьяулык белән тәлинкәләр тоткан Җаһидәнең көймәдәге юлдашлары Сөем белән Гөлчәчәк килеп чыкты. Кызларның икесе дә бер үк тегелешле, берүк чигешле халат кигән иде. Аякларында бертөсле фасондагы җиңел чүәкләр. Җаһидә дикъкать белән аларны күзәтәбашлады. Сөем агач астындагы өстәлгә ашьяулык җәеп куйды. Ике кыз бердән табын хәзерләде. Олы углан агач эскәмияләр ташый. Кечкенә углан атасы янында кайнаша, үзе туктаусыз нидер сөйли.

Бераздан соң юка гына халат кигән, урта яшьтәге, озын буйлы, сәламәт йөзле бер хатын өсте каплаулы бер казанны гаҗәеп саклык белән күтәреп, табын янына килде. Самавырга кулын тигезеп карады. Олы улына нидер әйтте. Тегесе яшен тизлеге белән өйгә атылды да атасының иске күн итеген самавыр янына алып килде. Торбаны алып, итекне самавыр башына кигезде, тимерче алачыгындагы кебек итеп, күрекли башлады. Самавырга җан керде. Аскы тарафтагы тишекләрдән очкыннар ургыла башлады.

Мадам Марика:

— Ул нинди шайтан баласыдыр, менмәгән агачы калмады. Узган елдан калган нарат күркәләренең барысын да җыеп бетерде, — диде.

Хезмәтче хатын кечкенә газ плитәсе белән таба кебек нәрсәләр китерде. Ханым бер кулын самавырга тигезеп (ихтимал, кайнаган- кайнамаганын белер өчен), алып килгән казанның капкачын ачып карады... Хезмәтче хатын газ плитәсен кабызды. Ул арада самавыр завод кебек пар чыгарып кайный башлады. Ханым зур гына чәйниккә чәй салып, самавыр башына куйды. Газ плитәсе өстенә мул май салынган табаны куйды. Бәй-әфәнде дә табын башына урнашты һәм баларларына кулларын юарга кушты. Ханым, казаннан алып табадагы кызган майга пөхтә-сак рәвештә кашыклап камыр сала. Кызган майга салынган камыр чыжылдап пешә башлады.

Җаһидә мадамга:

— Ни пешерәләр алар? — диде. Мадам:

— Камыр ашы, кунак-фәлән килсә, шундук кайнар камыр ризыклары әзерли башлыйлар. Аталары кунак сурәтендә бит, шуның хөрмәтенә, — диде.

Күренмәс өчен, Җаһидә тәрәзәдән читкәрәк китте, шымчы политсәй кебек тегеләрне күзәтергә булды. Бераздан соң анасы Гөлчәчәккә нидер әйтте. Шуннан соң Гөлчәчәк анасы урынына басып, коймак пешерүне дәвам итте. Анасы аталарының каршысына утырды. Сөем чокыр белән ...

Ата белән ана кара-каршы утырды, балаларның да һәркем үз урынын белеп утырулары шулкадәр гүзәл күренеш иде...

Җаһидә бөтен дикъкате белән тегеләргә бага һәм сөйләшүләренә колак сала иде. Ләкин ни сөйләгәннәренең күбесе ишетелми кала, бары тик аерым-аерым сүзләр генә колагына чалына иде...

Кинәттән хуҗа-ата:

— Бисмиллаһ, — диде вә алдына бер чокыр куйды. Бу хәрби боерык кеби булды, ханым да шулай эшләде, балалар да үз чиратында чокырларын алып, табактагы коймакка үрелде. Чәй эчү башланды. Биш минут чамасы тавыш-тынсыз узды. Самавыр өзлексез пар чыгарып кайнап тора. Сөем...барлыгыннан хәбәр бирә иде... Гөлчәчәк тә ата- анасының, ир туганнарының бушаган тустаганнарына өзлексез чәй коя торды. Сөйләшә башладылар... Ләкин әкрен тавыш белән сөйләшкәнгә күрә Җаһидә берни дә аңламады. Кинәттән генә табын янында гөрелте купты. Ата-ана, балалар кычкырып көлә башладылар. Җаһидә аларга кызыгып карый иде. Аларның һәрберсенең ничәшәр чокыр чәй эчкәннәрен санап караса да, буталды. Табын янындагылар көлешә- көлшә сәгатьләр буе чәй эчтеләр. Ниһаять, самавыр тәмам арыды, сүнде.

Аталы-аналы шат гаиләнең бәхете-сәгадәте Җаһидәнең мәгълүм борчуларын оныттырды бугай, ул яшьлек дәрте белән урамга атлады. Таныш-белеш күршеләре белән бераз сөйләшеп торганнан соң диңгезгә китте.

***

Диңгездән соң ул наратлыкта йөрде. Кич җиткәч, өйгә кайтып, мадам Марика белән бергә ризык җыйды. Каһвә эчеп, бераз иркенләп ятып торыр өчен бүлмәсенә кергәндә күрше гаиләнең янә бакчада утырганын күрде. Аерма шунда гына иде, бу юлы Җаһидәгә таныш гаилә әгъзаларыннан башка берничә балалы тагын бер гаилә дә бар иде. Тагын самавыр җырлап, кайнап утыра, тустаганнарга өзлексез рәвештә чәй коеп торалар... Бу юлы газ плитәсе дә, камыр ризыгы да юк иде. Ләкин табын төрле-төрле салкын камыр ризыклары белән тулы иде.

Ут кабызмыйча гына Җаһидә тәрәзә янына урнашты. Агачларга асылган электр лампасының көчле яктылыгында табын корган гаиләне ул тагын җай гына күзәтә башлады. Ни өчендер бу гаиләнең яшәеше Җаһидәне үзенә тарта иде. Җаһидә аларның үзара сөйләшкән сүзләрендә үзе өчен, тормышы өчен гаять кыйммәтле-кирәкле бер серне ачарга теләгәндәй, карашын, игътибарын шул нарат агачы астыннан алалмый иде. Әйтерсең лә, Җаһидәдән бер сер яшергән кебек, алар да кысык тавыш белән сөйләшә. Ул арада тустаганнары да бушап, янә тула иде.

Шул арада бер ир бала өйдән гитара алып чыгып, атасына бирде. Ата кеше Җаһидә һич ишетмәгән бер көй уйный башлады. Көйне кабатлаганда кунак ханым да төрек җырына да, француз көенә дә охшамаган бер җыр башлады. Сүзләрен ишетер өчен Җаһидә бөтен дикъкате белән тыңласа да, бозык төрек сүзләреннән башка берни дә тота алмады. Җырларга хәзер торучы бала-чага да күмәк рәвештә җырның кушымтасын күтәреп алды. Шактый тәртипле генә бер шәй килеп чыкты.

Бәй-ата икенче көйгә күчте. Ханымнар да шул җырны җырлый башлады.

Көй тагын алмашынды. Ике кыз белән ике углан биергә хәзерләнде. Олылар кул чабып, үзара «Бас, кызым Әпипә» дип такмак әйтә башладылар. Гитара тизрәк уйнарга тотынды. Җырчылар да аңа иярде. Балалар бию хәрәкәтләрен өзлексез үзгәртеп, җитезлек берлә бииләр.

Җаһидә җырның кайбер сүзләрен, көйнең бер-ике өлешен отып алды алуын, ләкин шуннан да ары китә алмады. Аннан соң кечкенә ир бала бер шигырь сөйләде.

Олыларның барысы да кул чабып:

— Машаллаһ, — диделәр.

Бераздан соң бөтен балалар, хорга тезелгән кебек, бер җыр башкардылар. Ниһаять, мөһәндис бәй үзе озын, үзе авыр бер җыр башлады. Аның тавышы калтырый һәм бәгыре елый кебек. Ерак- еракларга эндәшкән кебек, анасына, атасына, бөтен иленә ишеттерергә теләгәндәй, илһам берлә җырлый иде ул. Аның тавышы ерактагы Урал тауларыннан, Идел буйларыннан җавап көткән кебек иде, ул бераз тынып торды да, тагын озын көй башлады. Тыңлаучылар тирән дулкынлану эчендә иде.

Бу озын, елата торган көй Җаһидәгә сагышлы тәэсир ясады. Ул да җырның, ичмасам, бер кәлимәсен, ичмасам, бер авазын отарга тели, әмма «Кара урман, кара урман» дигән бер сүздән башка ник бер нота, ник бер сүз ота алсын!

Бүгенге яңалыклардан Җаһидә алҗыды, әмма, кадакланган кебек үзен урыныннан куптара алмый иде, дикъкатен башка тарафка юнәлтеп, ул үзенә бер шөгыль таба алмады.

Ниһаять, кунаклар кузгалды... Балалар йөгереп китте... Лампа сүнде... Бакчаны тирән тынлык чолгап алды.

Җаһидә ятагына керде. Йокыга талды. Талды, әмма төрле-төрле төшләр күрде. Көндез алган тәэссоратлардан котыла алмады. Дәү әнисе, анасы белән балалар, һәрберсе бергә хор булып җырлый. Кайчагында «Кара урман» җырын кабатлыйлар, ә кайвакыт «Әпипә»гә бииләр...

***

Җаһидә иртән иртүк уянды да үзе алдына:

— Бу мөһәндис минем татар атам булмасын тагы?— диде дә өстәп куйды:— Нинди ярашканлык? Бу бик культуралы адәм. Минем атам кара татар, тәрбиясез, әхлаксыз бер бәндәдер...

Ләкин акылына килгән бу фикер бер генә минутка да Җаһидәгә тынгылык бирмәде. Иртәнге аш вакытында мадам Марикадан күрше татар гаиләсенең кемнәр икәнлеге хакында сораштырды да, мадам Марика канәгатьләнерлек төгәл мәгълумат бирмәгәч, кичә кунак булып килгән татар гаиләсе яшәгән өйнең хуҗабикәсе мадам Әләниягә барып, мөһәндис бәйнең кем икәнлеге, хатынының кем икәне һәм ничәнче хатыны икәнлеге хакында мәгълумат тупларга булды. Шулай итеп, ул бу татар гаиләсе ярдәме белән юкка чыккан атасының эзен табачак, бәлки дә үзенең ятимлегенә сәбәп булган анасы белән атасы арасындагы серне дә ачачак иде.

Карт хатын:

— Сиңа ни җитми, җаным? — дисә дә, Җаһидәнең омтылышына каршы тора алмады. Яңа имеш-мимешләр җыярга һәвәсләнеп, мадам Әләния янына китте.

Бүлмәсеннән чыгар алдыннан Җаһидә күрше гаиләне тагын күздән кичерде... Алар иртәнге ашны ашап бетергән, оланнар аталары белән диңгезгә китәргә җыена. Алъяпкычлы кызлар өстәл янына тупланган. Ханым камыр баса, Сөем зур табактагы туралган итне болгата; Гөлчәчәк тә каһвә касәсе белән алдына җәелгән камырдан түгәрәкләр кисә. Бераздан өчесе дә шул кечкенә түгәрәк итеп киселгән юка камыр өстенә Сөем изгән иттән бер чеметем куеп, камырны әллә ничек бөреп, нидер (татар бөрәге— пилмән дип аталган татар ризыгы) эшлиләр һәм аларны ак җәймә капланган бер төпсә өстенә гаскәр кебек рәт-рәт итеп тезә башладылар. Алар үзара салмак кына сөйләшә-сөйләшә көлешеп тә алалар; ара-тирә рәхәтләнеп кычкырып та көләләр. Челтәр пәрдә артына качып,Җаһидә бу гаиләнең бөтен гамәлләрен дикъкать белән күзәтеп торды. Шулай итеп, байтак вакыт узып китте...

Аскы каттан мадам Мариканың:

— Җаһидә! Җаһидә!— дигәне ишетелде.

Җаһидә йөгерә-йөгерә аска төште. Хатын алып килгән хәбәр Җаһидә көткәннән дә артык иде.

Бу — мөһәндиснең икенче хатыны булып, Искешәһәрдәге бер татар докторның кызы имеш. Беренче хатыны исә Истанбул шәһәренеке булган икән дә, заманында иреннән качып

киткән, имеш. Мөһәндиснең исеме Вахит икән... Егерме-егерме ике ел әүвәл Анадолу тирәсендәге бистәләрдә Мүдафаи Миллиядә мөһәндис булып, хәзер Истанбулның хәрби инженерлык корылмалары даирәсенә бәйле булган Тракия фортификацион идарәсе карамагына тәгаенләнгән, ди. Бу атна ялга кайткан, һәр атнаның соңгы бер-ике көнен үз гаиләсе белән бергә уздыра алырлык югары урында эшли икән.

Бу сүзләр Җаһидәнең зиһененә кылыч белән чапкан кеби булды һәм зиһенендәге «Минем атам шушы адәм түгелме?» дигән уен тагын да куәтләндерде. Шушы яңа хәбәрдән соң ул ныклы карарга килде. Тиз генә Истанбулга кайтып, бу хосуста анасыннан аңлату таләп итәргә исәпләде. Төшке ашны да ашамастан, йөгерә-йөгерә пристенгә төште, юл буе анасы белән ничек сөйләшәчәге турында уйлап, баш ватты. Ихтимал, анасы белән ул бик каты бәхәсләшергә мәҗбүр булыр, шул турыда уйлап, моңа мәгъкуль дәлилләр хәзерләде.

Шушы серле мәсьәләне бүген үк тәмам ачыклар өчен ул Коткарылыш урамы белән Касыйм-паша чатындагы йортның капкасыннан катгый карар белән керде. Иске кунакханәләрдән ярым апартамент шикелле итеп үзгәртеп салынган өченче каттагы өч бүлмәле фатирның кыңгыравына басты. Җавап ишетелмәгәч, букчасыннан ачкычын алып, өйгә узды.

Өйдә бер кем дә юк иде. Кем белсен, әнисе кая киткәндер? Аш бүлмәсендә әзерләнгән ризык-фәлән булмаганлыктан, еракта, шәһәр читендәге бистәдә яшәүче туганнарының берәрсенә көне буена кунакка киткәндер, дип уйлады һәм көтелмәгән бу киртәдән аның кәефе кырылды.

Әүвәл ул туганнары янына, танышларына барып, әнисен эзләп табарга теләде. Бәлки мәсьәләне ачыклауны кичектерергә кирәктер, чөнки туганнарның бу эшкә кирәксезгә килеп катнашуына сәбәп булачак һәм болай да катлаулы хәлне бөтенләй бутап ташлау ихтималы бар иде. Бераз тын алу максаты белән, аш бүлмәсенә кереп, ул бер тустаган су эчте. Фикере туктаусыз кайный, тирә ягын сарып алган бу караңгылыктан котылмак өчен ул өзлексез уйлый да уйлый.

Кинәттән ул моның очына чыкты кебек: урта мәктәптә укыган чакта төннең бер мизгелендә ул уянып китте дә әнисенең иске язу белән язылган кәгазьләрен укып утырганын күрде, уянганын сиздермичә генә күз кырые белән әнисенә дикъкать белән баккан иде, әнисенең күзләреннән туктаусыз яшь акканын күрде. Ул моңа артык игътибар итмәгән иде, шул кәгазьләрнең әнисенең елавына сәбәпче хатлар икәнлеге, аларда үзенең бүгенге хәленә ачыклык кертә торган сер яшерелгәнлеге көн кебек ачык булганын чамалап, хатларны табарга дип, яшереп куелган урыннан ачкычлар алып, әнисенең кәгазь-документлар саклана торган сандыгын ачты.

Мең төрле кәгазьләр арасыннан табып чыгарган хатлар бәйләмен чиште. Дәү әнисенең кызына, Анадолуга язган хаты күзенә чалынды. Аннан соң икенчесен кулына алды. Бу — ир туганнарының Аурупадан язган хатларының берсе булып чыкты.

Бераздан соң ул шактый зур букчаны ачты. Иске хәрефләр белән язылган егерме-утызлап хат. Байтак вакытлар узуы аркасында кәгазьләре бераз саргая төшкән булса да, язулары ачык сакланган, килү тәртибендә хатларга саннар сугылган, «сөеклем», дип башланган хатларның берсенең имзасына бакты, икенчесенә бакты, барысында да бер имза, хатларның бер кулдан язылганы ап-ачык иде. Беренче хатны ул, эссе көндә сусаган инсанның су эчкәне кеби, бер тын белән укып чыкты. Үзенең дә сөелгәненә ышанган бер ир кешенең сөйгән хатынына дусларча язган бер хаты иде ул; хат хатынына рәхәтсезлек килмәсен дигән борчылулар һәм бераз аталарча нәсихәтләр берлән тулган иде.

Атасының бу хаты Җаһидәгә гаилә серенең беренче дәверен ачмый иде әле; киресенчә, ул вакытлардагы бу гаиләдә бер сәгадәт мохите булганлыгын күз алдына китереп бастыра иде. Җаһидә икенче, өченче хатларны да йотлыгып укыды. Ике еллык дәверне үз эченә алган ун бишләп хатта шул ук сүзләрнең кабатлануыннан башка берни дә табылмады.

Бу хатларның азагында шактый мул акча җибәрелгәнлеге турында да языла килә. Гел бертөрле сүзләр берлә язылган бу хатлар Җаһидәнең күңелендә канәгатьсезлек хисе

уята башлады. Җаһидә бу хатларны кат-кат укыды. Язылу вакытларын карады. Барысының да анасы белән атасының бергә яшәгән чорда атасының вазифасы аркасында ары-бире йөргән җирләреннән язылган хатлар, дигән фикергә килде. Тагын укый башлады. Атасы шөбһәле хат яза: туачак бала хакында борчылулар, үзен сакласын өчен хатынына төрле киңәшләр, кирәк булган очракта фәлән докторга мөрәҗәгать ит, кеби нәсихәтләр тулы бер хат...

Хатларның язылу тарихларына бакты, бу сүзләр Җаһидә хакында иде. Билгесез атасының үзенә һәм әнисенә булган мәхәббәте шулкадәр тирән, шулкадәр самими иде ки, Җаһидә хәзер дә атасы тарафыннан сөелгән кебек, татлы бер хыялга батты. Күңелендә шул вакытлардагы атасына тартылу хисе тойды.

Моннан соңгы хатлардагы сүзләрнең бөтенесе дә шул бала турында иде. Дөресе шулдыр ки, ул бала - үсеп җиткән бүгенге Җаһидә иде. Ләкин хатларның берсендә яңалык бар иде. Янар таулар аткан сыман куәтле язылган бу хатта атасы бөтен акылы, фикере берлә бала төшерү мәсьәләсендә яза. Һәм бу эшнең ана кешенең сәламәтлеге өчен зарары турында чын доктор кеби сөйли иде; ниһаять: «Бу синең үз фикерең түгел, черегән мохитнең сине мәҗбүрлеккә ыргытуына бер дәлилдер. Өйләнүнең, гаилә коруның максаты итагатьле бала тәрбияләүдер. Бала гаиләдәге мәнәсәбәтләрнең нигезедер, цементыдыр. Ул— гаиләнең авыр көннәрендә елмаеп-көлеп сөендергән, өметләндергән, табигать биргән бәһасез нигъмәтедер. Җәнаби Хакның бу нигъмәтенә көфран иткән хатыннар һәрвакыт моның җәзасын ала килде һәм алачаклар да. Моны син бик яхшы аңла... Сак бул, шул шайтаннарның вәсвәсәләренә алданып, ялгыш юлга баса күрмә. Мин ирең сыйфатында моны катгый рәвештә тыямын. Сине «фигураңның камиллеге бозылачак, фәләндер-төгәндер», дип котырталар, боларның барысы да ялган... Балалы хатынның йөзендә балкыган нәфислек, һәркемнең хөрмәтен казанган аның мөлаемлыгы зифа буен саклап калган кысыр хатыннарга күчәме икән? Сине сыңар бала белән түгел, бик күп балалар белән уратып алынган гаилә хәяты эчендә, бала мәхәббәте берлә мәш килүеңне күрү минем иң олы теләгемдер.»

«Байтак кына акча күчердем, җитмәсә, тиз генә хат яз. Әгәр берәр хәл була калса, шундук доктор (М)гә мөрәҗәгать ит. Мин аның үзенә дә хат яздым. Үзем дә тизрәк барыр өчен тырышам, диде». Һәм иң аста: «Эмиль Золяның «Бәрәкәт» исемле китабын кичекмәстән укы, монда табалмадым», дигән сүзләр өстәп язылган.

Җаһидә урыныннан торды. Атасы илә анасы арасындагы бетмәс- төкәнмәс бәхәснең сәбәбе бала икәнлеген аңлаган кебек булды.

Фәкать, һич уйламастан, бу эштә ул атасын хаклы саный иде шикелле. Узган кичтәге мәҗлестә атасының бөтен бала-чагасы арасында бәхетле икәнлеген күреп, үз кәефсезлегенең сәбәпчесе ялгызлыктан икәнен сизде. Әнисенең кысыр тормышы илә атасына дүрт бала багышлаган бу сәламәт хатынның тормышын чагыштырып, бу хатынның алдагы тормышы тагын да яхшы, һичшиксез бәхетле булачагын тулысы белән аңлады.

Моннан соңгы хатлар да һаман шул бала хакында иде.Атасы баланың исән-сау тууын теләгән хатында хатынына рәхмәт сүзләрен куаныч берлә менә болай белдергән:

«Син яхшы күңелле хатынсың, ләкин мохитең черек. Шөкер, Анадолуга килдең, Истанбулда калган булсаң, алар сиңа, белмәм, ни кылган булыр иде. Бала тапмак өчен Истанбулга бар. Бу хосуста әниеңнең фикеренә кушыламын. Аның янында яхшырак булыр. Мин дә бала тапкан вакытларыңда синең янда булыр өчен бөтен чараларны күрәчәкмен. Әгәр мөмкин булмаса, теге бәбәй табу йортына кереп ятарсың, башкасына ятма, бәясенә бакма, иң кыйммәтле шәй - ул синең һәм баланың сәламәтлегедер. Бу бала хакында синең мохитең берлә байтак кына сүз көрәштердек. Гаиләбезгә бер истәлек булыр өчен, баланың исемен ир олан булса—Җаһид, кыз булса — Җаһидә куярбыз», дигән.

Бу хатларны укыгач, Җаһидә бүгенге барлыгының, бүгенге яшәешенең мәгънәсе үз исеменә яшерелгәнен күрде. Һәм ул беразга сәерсенеп калды.

Алты ай буена хатлар килми торган. Моннан соңгы хатлар янә Анадолудан, ләкин бу юлы Истанбулга язылган. Һаман Җаһидә турында өзлексез бәхәс. Үзенең әүвәлдә дә хатыны янына кайтачагына өмет иткәнлеген яза. Хатларның язылу вакыты якыная барган саен, ирнең гаиләсе белән кавышырга зарыкканлыгы, балалары белән бергә яшәү теләгенең гаять куәтләнә барганы күренә. Ниһаять: «Истанбулга рөхсәт белән кыска вакытлы ялга килеп, анда бер ай калып, сине дә бирегә алып китәчәкмен. Конья шәһәрендә бакчалы гүзәл бер өй таптым. Хезмәтче табуы да кулай булыр. Монда тормыш та бик очсыз. Гөрләшеп яшәрбез. Әнине дә кунакка чакырырбыз» - дип ышандыра.

Моннан соңгысы әбисе-карчыкның Истанбулдан Коньядагы кызына язган хаты булып чыкты. Хатның башыннан алып ахырынача әбисе-карчык кызын кияү балакайдан ничек итеп акча каерып алырга котырта. Үзен хаста буларак күрсәтергә тырышып язган хатын ире белән бергә укырга кирәклеген, беренче хатны исә аңа күрсәтмәскә тиешлеген яза. Икенче хатта дәү әнисе кызының үз янында булмаганына көенә, солтан кызы кебек бер кызның Анадолуның шакшысы эчендә никадәр җәфа чиккәнлеген, яхшы шартларда яшәгән асылзат бер кызның Анадолуның тупас мохитендә ничек түзеп яшәячәге, кызының һәрвакыт авырыуыннан зәгыйфьләнүе - боларның барысы да ана кешене бик борчый, аның нервысына тия, имеш..

Кызын кияүгә бирергә ризалашкан вакытта Истанбулдан беркая да җибәрмәячәге хакында кияүдән сүз алмаганлыгы өчен үзен гаепле тоеп, вөҗданы газапланганын, бу кадәр бала-чага үстереп тә, хасталыгын дәвалау өчен Бурса шәһәренә китәргә мөмкинлеге булмаганлыгын җаны чыгардай булып исбатларга тырыша иде.

Моннан соңгы хатта дәү әнисеннән: Аң бул! Йөккә уза күрмә! Мин сине ел саен бала табар өчен үстердеммени? Җибәргән акчагыз җитмәде. Сине яратса, миңа тагын да акча салдырт. Ана кешене шушылай итеп мохтаҗлыкта калдыралармыни? Бу бер дә килешә торган нәрсә түгел. Анадолуда тупас ирең белән яши торгач, тупас бер хатыны булып китүеңнән куркамын. Ничек кылсаң кыл, Истанбулга кире күчеп кайтырга тырыш. Авырыйм-фәлән диген, төгән диген... Бергә булсак, минем тормышым да рәтләнер иде, син дә рәхәткә чыгар идең. Шул ук вакытта акча мәсьәлсе дә хәл ителер...

Башка хат тагын атасыннан иде. (М) бистәсеннән яза:

«Синең кәефсезлегеңә борчылдым, ни булды? Син нидән риза түгелсең? Әниеңнеме сагындың? Шулайдыр, әмма хәзер син үзең ана. Җаһидә дә яныңда. Мин дә еш-еш кайтам. Истанбулда ни кылачаксың син? Баланы бу озын юлга алып чыгу дөрес булырмы? Бераз үссен, соңыннан кайтырсың. Бик теләсәң, анаң килсен. Юлына акча сал. Мин дә ай ахырында кайтачакмын. Бәлки Аллаһ ярдәме белән Җаһидәгә бер энекәш алып кайтырсың? Шулаймы? Бер угылыбыз да булса, ничек гүзәл булыр иде, шулай түгелме? Үзеңне яхшы кара, күбрәк җиләк- җимеш аша... »

Хатлар арасында тагын өзеклек. Тагын Анадолудан Истанбулга:

«Җаһидә ничек? Сөйләшә башладымы әле? Ниләр сөйли? Сак бул, бик җылы киемнәргә ияләштермәгез. Истанбулда кайбер гаиләләрнең балаларына калын, җонлы бишмәтләр кидерә торган гадәт бар. Без хәтта Төньякның карлы-бозлы кышында да калын кием киюне белми идек. Истанбулның һавасы балалар өчен яхшы түгел, Коньяда бик яхшы, саф һава. Истанбулда яшәүче, заманасы узган аксөякләр арасындагы мохиттә баланы бозмасыннар, дип куркамын. Сак бул! Сиңа ни булды? Тагын нидән зарланасың. Анаң - яныңда, балаң - яныңда, бөтен нәрсәгез җитеш. Башыма төшкәч, мин авыл кешесенең тузанлы өендә, күп вакыт атналар буе мунча күрмәенчә, күлмәк алыштырырга да мөмкин булмаудан михнәт чигәмен. Атналар буе кайнар аш күрмим. Дәүләт һәм милләт яхшы күперләргә тиенәчәк, дигән куаныч белән эшлим. Шуңа күрә, һичбер зарым юк. Синең зарлануларыңның төбен аңламыймын. Анадолуда чагында болай зарланмый идең. Димәк, Истанбул мохите сиңа ятышмый... Агаңның яман кылмышлары турында укып бик борчылдым. Әмма ул ялкау, җаваплылык хисе булмаган, коры аксөяклек горурлыгыннан башка бернәрсәсе дә булмаган бу бәндәләр белән ни кылаек? Төркиядә эшләгән кешегә

мәйдан бар. Эшләгәннәр тапсын, яшәсен. Әрәм-тамак булып, типтереп яшәү дөньяны танырга, үзеңне белергә комачаулый».

Берничә ай узганнан соң тагын Истанбулга яза:

«Соңгы атна эчендә сиңа хат язалмадым. Бизгәк тота башлады. Бәрәкәт булсын, тәнем бик каты көрәште. Хәзер савыга башладым инде... Әйтергә кирәк, чирем китте хәтта. Синең хәлең ничек? Сине Истанбулда калдырып киткәнемә бик үкенәм-борчылам. Коньяда булсаң, һәр атна, йә булмаса, ике атнага бер тапкыр өйгә кайтып килү берни дә тормаган булыр иде.

Яңа килгән көрт эшчеләре бик тә пычрак, барысы да бетле. Вазифам буенча мин болар белән янәшә эшләү мәҗбүрендәмен. Өсләрендә тормасаң, һичбер нәрсә эшләргә теләмиләр. Ихтимал, бизгәк авыруын да мин шулардан йоктырдым шикелле. Һич югында, ике атнага бер өйгә кайтып, чистарынып килү минем өчен авыр булмас иде. Гомумән, тормышның ләззәте дә бергә яшәүдәдер, шулаймы? Беребезнең Истанбулда, икенчебезнең әллә кайдагы Капалыдәрәдә яшәве, һичшиксез, табигый хәл түгел. Мин бу фидакарьлекне синең күңелең булсын өчен эшлимен, әмма үзем дә бу эшнең дөрес икәненә ышанып бетмим.

Соңгы тапкыр синең Истанбулда калуыңа разалык бирүемнең сәбәбе бары тик йөкле булуың аркасында гына иде, доктордарның да, даруларның да анда күп булганы өчен иде. Бу бала да Җаһидә кебек сау-сәламәт дөньяга килсен иде дә, аеры-чөере яшәвебезгә, ниһаять, чик куяр идек. Бәлки миңа да бераз комфортлы тормыш корырга мөмкин булган берәр җиргә күченергә форсат чыгып куяр. Тау башында, үзән җирләрдә,кыялар арасында сигез ел буе эшлим бит инде.

Үзеңне яхшы кара. Берәр нәрсә була калса, мин өйгә китергән доктор Назми бәйгә бар. Ул кушканча гамәл кыл. Ул ни дисә, шулай эшлә. Гайбәт сөйләшү мәҗлесләрендә азакка кадәр утырып калма. Иртә ят. Шуны яхшы белеп тор ки, син бары тик үзең өчен генә түгел, карыныңдагы балабыз өчен дә яшисең. Кайнананың ул әрмәни докторына катгыян якын барма. Мин аны һич тә ошатмадым. Ул хатыннарны алдаучы бер шарлатанга охшашган. Бала мәсьәләсендә ихтыяҗың булса, кирәге кадәр банкадан акча ал. Булачак балабызны зарыгып көтәмен. Олан булса, бигрәк тә мәмнүн булачакмын, әмма кыз булса да оябызны ул тагын да чәчәкләргә күмәчәк, шулаймы? Мин ялымны син бәбәй алып кайтасы көннәргә туры китерергә тырышачакмын, әмма әле аңа чаклы байтак вакыт бар. Дөресен генә әйткәндә, мин бу аерым яшәүдән гарык булдым.»

Бер ай өзеклектән соң янә Истанбулга:

- «Синең бу хатыңны укыгач, миңа бик кыен булып китте. Дөресен әйткәндә, хәнҗәр белән кинәт кадаган кебек, йөрәгемне чәнечте. Ни сәбәпле син шулай хасталандың? Бөтен дөнья хатыннары өчен йөккә узу табигый хәл, синең өчен генә нигә ул яман булсын? Ни өчен Җаһидәне тапканың фаҗига булмады да (докторларның бөтенесе дә: иң авыры беренче баланы табу, дип әйтә), бу икенче бала синең ни сәбәпле фаҗига булып чыкты? Хактыр ки, бу - мин белмәгән берәр яман тәэсирдән килә булыр. Һич шикләнмичә әйтә алам, син: күп бала тапсаң, фигураң бозылачак, балага батачаксың. Аксөяк хатынга бу килешәме, дигән котыртуларга дучар булгансың. Бу эшкә һаман да мәлгунь доктор Папазян килеп тыкшына... Бала табу сиңа бик тә куркыныч, имеш!

Куркыныч булса, доктор Назми бәй моны әйтмәгән булыр идемени? Зинһар, ышанма. Хатны алуга ук Назми бәй янына бар яки аның үзен өйгә чакырт. Кирәге булса, ул янә берничә тикшерүче доктор алып килсен. Ләкин ул әрмән докторын якын китермә. Тикшерсеннәр, карасыннар. Акча өчен борчылма. Кирәк кадәр тот. Бары тик син сихәтлән дә, бала сау-сәламәт дөньяга килсен. Бу хат шулкадәр вакытсыз, начар заманга туры килде ки, әйтеп бетергесез. Өч көн инде ике сәгатьтән артык йоклый алмыйм... Төнен, көндезен тауларда, калкулык түбәләрендә уздырамын. Чама белми күкрәк кага торган бер күрше мәмләкәтнең, илебезгә каршы утрауларда корган планнарына каршы торыр өчен, хөкүмәтебез бер карар белән бөек маневрлар эшләргә ашыгыч әмер бирде. Гаскәри транспортның күп өлеше һәм төп йөге минем карамактагы юл вә күперләрдән кичәчәк,

юллар өр-яңа, күперләрнең бөтенесе дә яңа сылынган. Кат-кат сынап карамасаң да була. Кул астымда, минем карамакта, минем җаваплылыка ун ике күпер, берничә туннель бар. Боларның һәммәсен дә даими рәвештә контрольдә тоту мәҗбүриятендәмен. Чөнки минем кул астындагы инженерларның саксызлыгын тәҗрибәмнән чыгып беләмен. Бер күпердәге, бер туннельдәге кечкенә генә бер ялгыш минем шәхесемә зарар китерәчәк булса да, ул кадәр курыкмас идем, әмма мәмләкәтемнең иминлегенә, хәкүмәтемнең, дәүләтемнең мәнфәгатьләренә кагылган булса, бөтен гайрәтем берлә тырышырга, даими рәвештә уяу булырга тиешмен. Шулай алҗыганлыктан бизгәгем яңадан баш калкытты. Бер кесәмдә хинин, бер кесәмдә коньяк, авызым коры, битем чөгендер кеби кызарды, кайчак ат өстендә, кайчак җәяү - дүрт тарафка йөгерәмен, йөгерәчкмен. Хөкүмәтемнең, дәүләтемнең иминлеге өчен булган планнарым буенча, ни булса да булыр, әмма артык мактанчык күршегә хөкүмәтебезнең теләгәне кадәр сугыш әсбапларының, гаскәрләрнең кирәк санга кадәр җиткәнчә туплаганын күрсәтә белү өчен бөтен гайрәтемне сарыф итәчәкмен. Тәнемнең кызышуы бәлки утыз сигез дә биш булыр, утыз тугыз да бардыр, бәлки кырык булуы да бик ихтимал. Ләкин мин вазифамны ташламаячакмын.

Иманым камил ки, мактанчык күрше безнең юл эшчеләребезнең саксызлыгына, юлларыбызның төзек булмавына өмет итеп, басып алу планнары кора торгандыр.

Аларның бу өметен буш хыял гына иттереп калдыру - без-юл инженерларының бурычы һәм минем тормышымдагы иң мөһим вазифаларымның берседер.

Шушылардан чыгып әйтәмен ки, берничә айга синең кәефең китеп торуы минем өчен бик вак һәм чит-ят нәрсә кебек тоела. Мин Төркиянең милли иминлиген боздырмас өчен тырышамын. Әниеңә шушы хатны укыт. Шул мәлгунь әрмән докторын балам өчен закон аша җавапка тарттырачакмын. Доктор Назмигә телеграмма бирдем, үзем моннан китә алмыймын, бер эшчемне җибәрәм, телеграмманы ул тапшырыр... Бу хатны тау башына утырып, кургашын каләм белән язам. Кырык эшем кырылай көтеп ята. Аллага тапшырдык. Син дә, балам да сәламәт булыгыз...»

Берничә көн соңрак язылган хат:

«Кичә иң соңгы состав минем кишәрлектән исән-аман гына узып китте, сигез көн, сигез төн йокысыз калуым, бөтен тырышлыгым үз нәтиҗәсен бирде. Барча гаскәрләребез һәм корал төягән олауларыбыз хөкүмәт планлаганнан унике сәгатькә алда, тиешле урыннарына барып җитте.

Мин башкарган вазифамнан тулысынча канәгать булып, тынычланып калдым. Әмма шулкадәр арыдым ки, көчкә-көчкә генә аягымда басып торамын. Почтага өлгертер өчен, шушы хатны сызгалыймын.

Әгәр соңгы хатың алып килгән шик-шөбһәләр булмаса, күптән инде урынга яткан була идем. Басып торырлык тәкатем калмады. Ниләр булды? Минем хатым вакытында барып ирештеме? Сәламәтлегең ничек? Теге мәлгунь докторны кудыгызмы? Тизрәк хәбәр

бир. Синнән сөенечле хәбәр алсам, үземне бик тә бәхетле дип санар идем. Ватан алдындагы вазифаларымны башкарганыма, башкара алуыма бик канәгатьмен, шулай да, бераз эчем поша... Килергә теләсә, дошман килсен, бил алышып карарбыз... Балабыз да сау-сәламәт дөньяга килсен иде. Сиңа хат язганда градусник куйдым. Мәлгунь, янә утыз тугызга җиткән... Теләсә, кырыка менсен... Гаскәрләребез инде әллә кайчан тиешле урынга барып җитеп, тиешле вазифасын башкара...»

«Бөтен тәнем ут яна, күзем камаша. Аллаһка тапшырдык. Сөенечле хатыңны көтәмен. Минем исемнән Җаһидәне үп.»

Җаһидә бу хатны укыганнан соң үзендә бер горурлык хисе тойды. Гүя атасының ватанга булган бу хезмәтендә аның да өлеше бар иде. Әмма вакыйгаларның агышы гаилә серенең чишелүенә таба алып барганлыктан, ул үзенең бу хиссиятен җентекләп тикшерергә вакыт табалмады. Ул чираттагы хатны кулына алды. Бу - Анкара хастаханәсенең рәсми кәгазенә кургашын каләм белән бер атна соңрак язылган хат, дөресрәге, бер рәсми язу гына иде:

«Соңгы хатымнан бирле сигез көн узды. Мин Анкара хастаханәсендә аңыма килдем. Маневрлар уңышлы узгач, генерал безгә - юл төзүче мөһәндисләргә аерым-аерым рәхмәт әйткән, аркадашларым арасында мине күрмәгәч, минем турыда сораштырган. Мин ул вакытта тау башындагы чатырда, кул астымдагы эшчем янында һушсыз ятканмын. Бөтен докторлар гаскәрләр белән бергә маневрда булганлыктан, эшчем берни эшли алмаган, бары тик ул телефон аша мәркәзгә хәбәр иткән. Генералга хаста икәнемне, бизгәкле килеш эшләгәнемне сөйләгәннәр. Ул мине чатырымнан алып, үз вагоны белән Анкара хастаханәсенә алып киткән, шулай итеп, ул мине коткарып калган. Хәзер бераз күзем ачылды инде, әмма хәлем юк, аяк өсте торалмыйм. Һәр көн дару кадыйлар. Тагын бер атна-ун көн хастаханәдә калырга туры килер. Моннан соң ял алып, һава алыштырыр өчен, Истанбулга кайтырмын, дип торам.

Алдагы хатыма синнән җавап көтәмен. Сәламәтлегең ничек? Баланың хәле ничек? Докторлар чакырттыңмы? Артык язалмыймын. Арылды, гафу ит, җавабыңны көтәмен....»

Җавабыңны мөһәндис Вахит кына түгел, җавапны Җаһидә дә көтә. Атасының хатын укып бетерер-бетермәс ул чираттагы хатны алды, әбисенең кулын танып, дулкынланып укый башлады.

Карчык иске ысулда, искечә нәзакәтләр белән башлаган хатында әче-зәһәрле сүзләр белән гарәпчә-фарсыча артык купшы язган ки, Җаһидә башта берни дә аңламады кебек. Соңыннан мәсьәләнең асылына төшенә башлап, фикер агышын тотып алды һәм хатны укып бетергәндә зур бер яманлык кылган бала кебек кызарып чыкты. Бу эше өчен ул атасыннан оялсынмы? Атасын дәвалаган доктордanmы? Атасының тормышы илә бу кадәр кызыксынган олылардanmы оялсын? Аның күңеле тулды. Каны катып калды кебек, башы эшләмәс булды, бары тик җан газабы гына торып калды. Хатның тормыш теле белән язылган мәгънәсе гаять ачык вә кыска иде:

«Авыру хатыныңны һич кирәксезгә битәрләүләрең, үгетләрең белән туйдырып бетерер өчен артык тупас, тәрбиясез булу кирәк. Мин синең шундый икәнеңне белә идем инде, әмма кешеләргә сөйләмәдем. Анадолуның бер почмагындагы үзәннәр белән таулар кебек кирәксез җирләрдән, йөкле чагында нервылары тузып беткән хаста хатынга шулай әйтәләрмени? Бәрәкәт бирсен доктор Папазянга, кызымны ул коткарды, чистартты. Хәзер кызым хастаханәдә. Кызымны коткарып калыр өчен, миңа фидакарьләрчә бик нык мәшәкатьләнергә туры килде. Бар булган асылташларыбыз ломбардта, залогта калды... Хатыныңның сихәтләнүен теләсәң, акча сал... » кебек сүзләр язылган иде.

Моның янында доктор Назминың рәсми кәягазьгә язган бер хаты да бар иде. Ул:

«Хатыныңны күрер өчен өч тапкыр бардым. Кайнанаң төрле сылтаулар белән хатыныңны миңа күрсәтмәде. Минемчә, бөтен нәрсә нормаль гына булырга тиеш иде. Элек күргәнемдә шикләнерлек берни дә юк иде. Иншалла, минем ярдәмемнән башка да узар әле», дигән.

Атасына язылган бу хатлар ничек итеп анасы кулына төшкән? Җаһидә моңа җавап табалмады. Бәлки болар атасына җибәрелмәгәндер, бәлки аннан ничек булса да алынган яки урлангандыр? Бу сорауларга җавап эзләгән арада ул чираттагы хатны кулына алды.

Әнисенең әтисенә җибәргән бу хаты дәү-әнисенең хаты белән бер тирәдә язылган иде. Хатның язылу рәвеше бик тә кыюсыз, нидер яшерер өчен язылган кебек, фәкать ихтыяр зәгыйфьлегеннән генә ул үз җинаятен таный кебек тәэсир калдыра:

«Әнием икенче баламны табуыма катгыян риза булмады... Доктор Папазян да һәр килүендә: «Тормышың куркыныч астында. Сиңа бала табарга ярамый дип ышандырды. Мин синең сүзне тыңлап, моңа каршы тордым, әмма, әниемнең катгыян кушуы аркасында мин Папазян биргән ул даруларны эчәргә мәҗбүр идем һәм чынлап та хастага әвереледем. Мине бер яһүд докторның өенә алып бардылар, анда мине йоклатып, операция ясадылар. Операция бик катлаулы, авыр узды, балага җан кергән булган. Шәфкать туташы: «Ир бала» диде. Миңа күрсәтмәделәр... Нишләмәк кирәк, язмыш шулайдыр инде... Хәзер мин бик алҗыган, зәгыйфь сурәттә. Йокым начар, докторга бик күп акча китте... Син бүләк иткән алмазны, алкаларны саттык... Банкалардагы акчаларга да күз тиде. Агам Фикрәт Фәһим

бәйләрнең покер уйный торган, карта өстәле янында бик күп акча оттырган. Түлисе акчасы булмагач, түләр өчен шартнамә язган. Уенда оттырган акчаны түләмәү затсызлык санала икән дә, шуңа күрә, әниемнең мәҗбүр итүе аркасында, гаиләбезнең шәрәфен саклап калыр өчен, мең биш йөз лираны банкадан алып бирдем. Кирәге чыккан саен мин ул акчадан йөз- ике йөз лира алып тора идем. Шунлыктан, докторга биререгә дә акчасыз калдым. Докторның өзлексез сорап торуы аркасында, алкаларымны да сатарга мәҗбүр булдым. Бик тиз акча күчер, ихтыяҗым бик зур... »

Җаһидә бу хатны укыганнан соң шашып калды. Хатта атасының сәламәтлеге турында кызыксыну юк, атасының ватан өчен башкарган авыр вазифаларына, аның фидакарәлегенә ник рәхмәт укысыннар да, ник аны юатсыннар.

Иренең хастаханәдә ятуы, озак дәвалануы, ватан өчен башкарган фидакарьлекләре, гаскәр хезмәтенең шәрәфе дә, кыйммәте дә - барысы да әһәмиятсез нәрсәләрдер кебек. Бары тик покер янындагы шәрәф белән үз горурлыгы-аксөяклеге генә кыйммәт, имеш.

«Бу нинди тәрбия, бу нинди караш... Истанбулның уртасында яшәп тә, бу нинди чит-ят рухлы әхлак!..»

Атасының югары дәрәҗәдәге ватанпәрвәрлеге, фидакарьлеге белән черегән әхлак арасында бер упкын булганлыгын Җаһидә үз күзләре белән күргән кебек булды. Атасының фидакарьлек белән төзегән күперләре, дәү әнисенең һәм ул Истанбул тәрбиясе алган агаларының тырышлыгы аркасында таркалырга мәхкүм булган гаиләнең серенә төшенде. Әмма кызыксынуы һич тә кимемичә, чираттагы кәгазьне кулына алды. Бу атасының: «Иртәгә кайтып җитәрмен», дигән телеграммасы булып чыкты.

Җаһидә хастаханәдән вакытыннан әүвәл чыгарга мәҗбүр булган атасының бу хаксыз, рәхмәтсез могамәлә аркасында нинди җәфалар күргәнен аңлады, ихтыярсыз, зәгыйфь рухлы анасының ике төрле тормыш тәрбиясенең каршылыгында ничек итеп корбан булганын хис иткән кебек булды. Дулкынланып, ашыгып чираттагы хатны кулына алды. Бу алты айдан соң янә анасына атап язылган хат иде.

Бу хат ике арада булып узган вакыйгаларны, көннәрне, айларны Җаһидәнең күз алдыннан уздырды. Хат бик борчулы сүзләр, зар белән башланып китә...

Иренең сүзенә итагать итмәенчә, анасы янында калганы һәм гаилә тормышын бозганы өчен ул хатынын гаепли иде:

«Нишләмәк кирәк, буласылар булды инде. Минем авырлык белән казанган, бала-чагам тәрбиясе өчен туплаган меңнәрчә сум акчаны Истанбулның шул купшы әрәм-тамак абыйларының типтерүләренә- сиптерүләренә туздырып бетергәнеңне оныттым, күз алмам кеби көткән улымны череп беткән, таркалган мохитнең ялган идеяләре белән үтергәнеңне дә гафу иттем. Әмма, моннан соң боларның һичберен кабат эшләмәскә сүз биреп, һичшиксез Эрзиҗанга, минем янга киләчәксең.

Шартымны кабул итү - синең ихтыярыңда, итмәсәң - мин дә үз башыма, үз җаемны карармын. Катгый карарга килгәнче Җаһидәнең йә анадан, йә атадан ятим калып үсәчәген дә исеңдә тот...»

Бу хатны укыганнан соң, куркыныч төш күргән кебек, Җаһидәнең кул-аягы җегәрсез бер хәлдә калды, ул фикерли алмас дәрәҗәгә килде. Аның эчендә нидер өзелгән кебек булды, күзеннән яшь ага башлады...Ул үксеп-үксеп елый иде. Күз яшьләре аның күңелендәге авыр хисләрне бераз гына җиңеләйткәндәй булды. Янә үзен кулга алып, эшне тәмам аңлап бетерер өчен, ул башка хатны алды. Монысы суд карары язылган кәгазь иде. Бу карарда мөһәндис Вахит белән анасының таләпләрен канәгатьләндереп, аерылышулары, ике ут арасында калган Җаһидәнең әнисе янынада булырга тиешлеге һәм атасының теләгән чакта кызын күрә алачагы, шулай ук аның ай саен билгеле күләмдә алимент түләп торырга тиешлеге язылган иде.

***

Моннан соңгы кәгазьләр атасының почта аша акча җибәргәнлеге турындагы квитанцияләр иде. Боларның барысы да Анадолуның төрле шәһәрләреннән һәр айның беренче көнендә юлланган, арка якларында Җаһидәнең сәламәтлеге турында сорап язган язулар белән тулган квитанцияләрдән гыйбарәт иде. Квитанцияләрнең барысы да бер үк суммага булып чыкты. Язын да, көзен дә кызына күлмәк-фәлән алыр өчен дип квитанцияләрдәге сумма арта барган, кызының туган көненә атап, «бүләк алырсың» дигән аерым квитанцияләр дә килеп чыкты.

Кайбер квитанцияләрнең артына: «Әгәр бала хасталанса, балалар докторына, фәлән докторга, атасы хисабына карат», дип язылган. Бу квитанцияләр ике ел дәвамында җибәрелеп торганнан соң, озын язылган бер хат килеп төшкән.

Бу хатта махсус рәвештә баласын күрер өчен атасының Истанбулга килгәнлеге, ләкин төрле сылтаулар белән кызын күрсәтмәүләре турында зарланып язылган, әгәр шулай дәвам итәчәк булса, ул судка мөрәҗәгать итәчәген дә белдерә.

Бу хаттан соң яңадан квитанцияләр, бүләк алыр өчен акча кәгазьләре берсе артыннан икенчесе килеп торган. Бу ике ел узып киткәннән соң, судның икенче карары Җаһидәнең атасы белән атнага бер-ике тапкыр каршылыксыз күрешергә тиешлеге, әгәр моңа каршылык булса, балага акча җибәрү туктатылачагын белдерә.

Янә квитанцияләр һәм тагын бер хат: атасы бу хатта да баласын күрсәтмәгәнлекләре турында зарлана. Җаһидәне фәлән интернатка ата хисабына укырга бирергә кирәклеге турында яза. Әгәр бу тәкъдим дә кабул ителмәсә, закон биргән хокуклардан катгыян файдаланарак, кабат акча җибәрмәячәге турында кисәтә.

Бу хаттан тыш тагын берничә квитанция килгән һәм кабат акча җибәрелмәячәге хакындагы хәбәрдән соң язышу тәмам туктаган.

Кәгазьләр арасында анасы белән атасының туй күлмәге киеп төшкән бер рәсеме белән Җаһидә ике яшьлек чагында өчесе бергә төшкән тагын бер рәсем бар иде.

Җаһидә икенче рәсемне алып, сумкасына салып куйды. Хатлар арасыннан да бер-икесен алыргамы-юкмы, дигәндәй икеләнеп калды. Әбисе белән әнисе тарафыннан язылганнарын аерып бер кырыйга алып куйды. Боларын яңадан укырга булды. Ләкин бу хатларның бөтен сүзләре, җөмләләре Җаһидәнең күңелендә яра эзләре калдырырлык нык тәэсир иткәнлектән, ул бу уеннан ваз кичте. Кәгазьләрне җыеп, урынына куйды, сандыкны бикләде. Өйгә кайтканлыгы беленерлек бернинди дә эз калдырмыйча, ишектән чыкты. Атасы белән күрешмәк өчен, аннан гафу сорамак карары берлә пристенгә таба йөгерде...

Көймә кузгалып китеп, аның янына урнашкан хатын каһвә эчә башлагач кына ул үзенең ачыкканлыгын тойды. Мәкле криндил белән чәй эчте. Көймә пристенгә килеп туктар-туктамас, ул эрҗиңкә туп кебек, ярга сикерде һәм мадам Мариканың өенә таба йөгерде.

Ямау белән мәшгуль мадам Марика Җаһидәгә аптырап карады.

Җаһидә мадамның сәер, шикле карашын күреп шашып калды.

— Ни булды, мадам Марика?- диде дә кызарды. Мадам да:

— Берни дә юк, әмма йөзең үзгәргән кебек күренде. Ни булды? Әниең сәламәттер бит? Бер-бер яман хәбәр алдыңмы әллә соң?- дип сорады.

Җаһидә хатынны кирәкмәгән шиккә төшермәс өчен:

— Берни дә булмады, әмма мин бик талчыктым. Беләсең бит, мин университетка керергә телим. Ләкин әнием рөхсәт итми. Әнидән яшереп кенә мин университетка бардым да, ахшамга чаклы сынауга теркәлү эшләре белән мәшгуль булдым. Тамак ялгарга да вакытым булмады. Әниемне эзләргә дә вакытым булмады. Син боларны әниемә сөйләмә, мадам Марика.., - диде дә, - Бик ачыктым, бик арыдым...- дип бүлмәсенә менеп китте, Мадам да:

— Мин хәзер ашарга әзерлим, -дип кычкырып калды. Бүлмәсенә керер-кермәстән Җаһидә көзге алдына басты. Үзенең йөзенә сынап карады. Чыннан да, авыр чирдән котылган кебек йөзе сулган, күзләрнең нуры качкан... Елмаерга гына торган күзләрендәге көлемсерәү чаткылары юкка чыккан... Яңакларындагы алсулык беткән, маңгаенда инде

бала тапкан хатыннарныкы кебек сызыклар да пәйда булган. Йөзендәге, күзендәге сабыйлык самимилеге юкка чыккан, аның чыраенда олыгайган хатын җитдилеге күренә, башы да авырайган, гүя, кинәттән генә ул ун яшькә олгайган кебек бер халәт алган. Аның рухы алмашынган кебек иде...

— Ни булды? Рухымны җенме, пәриме - икесенең берсе шулай алмаштырдымы? Хәзер мин кичәге Җаһидә түгелмен, тәмам башка бер кыз: бәлки Җаһидә дә түгелмендер әле мин... Бәлки кыз да түгелмендер... Бәлки шулай гөнаһсыз сабый чагында әрмән докторы тарафыннан үтерелгән энемнең җанын йөртәмдер мин тәнемдә? Нинди тилергән уйлар! Ләкин барысы да тилергән түгел, җан күчеп йөри дигән бер фәлсәфи агым бар бит... Алар сүзенә ышансаң, үлгән инсаннарның рухы яңа туган балаларга күчә икән... Әйтик, Бура мәзһәбе дә шуңа корылган түгелме? Юк... Юк!

Хатлардан укып белүенчә, атасының озак еллар михнәт чиккәннәре, анасының үзен үзе саклап калырлык кодрәте булмаган ихтыярсызлыгыннан килгән мескенлеге Җаһидә өстенә иңде, аны изде һәм сыгылган лимон хәленә төшерде.

Башкаларның хокукын танымаган әбисенең наданлыгы, мин- минлеге, еллар дәвамында үз мәнфәгатен генә кайгырткан анасының ачынып, үкенеп яшәве һәм аны бүгенге мескен хәлгә төшергән сызлануларын берничә сәгатьтә Җаһидә үз башыннан кичерде һәм ул шул мохиттә яшәп карады. Шуның аркасында ул бер көндә берничә яшькә картайды, сабыйлык шатлыгыннан мәхрүм калды, җитешкән бала, олыгайган бер инсан булды...

Дөрес булмаган тәрбия аша кергән атасына карата булган нәфрәте олы хөрмәт вә мәхәббәткә әверелде дә куйды, анасына булган хөрмәт урынына олы үпкә пәйда булды һәм аның күңелендә фәкать аз- маз шәфкать хисе кенә торып калды.

Мадам Марика таба чыҗылдаткан арада ул ятагына сузылып ятты. Чуалган фикерләрен бер ноктага җыеп, аларны тәсбих кебек итеп, бер җепкә тезәргә тырышты. Шул максат белән тәсбихнең бисмилласын да табарга тели иде.

Шуларга җавап тапмаенча гаҗиз булып, ул бер-берсенә капма - каршы фикерләр, бер-берсен юкка чыгара торган хисләрнең ургылып ташуы арасында асылынып кала, акылдан язарлык хәлгә килә һәм бу гаугалы фикер ташкынынннан бертөрле дә котылу юлын табалмый иде. Мадам Мариканың:

— Җаһидә, ашарга әзер, - дип кычкырганы аның бөтен уйларын таратып ташлады. Һәм ул җәһәт кенә аш бүлмәсенә төшеп китте.

Кайнар шулпаны тын алмаенча ашап бетерде. Бәрәңге белән итне дә шулай ук йотлыгып ашады. Чират яшелчәгә килеп терәлгәч кенә ул бер чокыр су эчеп куйды да:

— Мадам, чыннан да мин бик нык үзгәргәнменме? - дип сорады.

— Шулай булган очракта да моның ни әһәмияте бар? Менә, ашадың, эчтең. Янә әүвәлге Җаһидә булдың. Яшьлектә барысы да җил кебек уза да китә, әмма картая башладыңмы, болар, кандала кебек, бер тарафта бетсә, башка тарафтан чыга тора, - диде мадам.

Чыннан да, Җаһидәгә баягы сабырлыгы кире кайтты кебек тоелды, әмма ул чын мәгънәсендә һушына килә алмый иде әле.

— Мадам Марика, үтенеп сорыймын, каһвәне олы бер чокырга яса әле,- диде. Үзен үзе белештермәстән, ул җимеш ашый башлады.

Тагын бер-берсенә капма-каршы хисләр ташкыны... Бер-берсен юкка чыгара торган фикерләр ташкыны аны үзенә алып кереп китте. Яңадан Җаһидәне ул тарафка, бу тарафка бәргәли башладылар.

Каһвәнең хуш исе Җаһидәне Истанбул балаларының барысына да хас зәвыкъка - идарәсез калган көймәне суырган кебек, буш хыял диңгезенә - кәеф-сафага, азгынлыкка таба суыра башлады, әмма җилкәсендәге авыр йөге аны шундук айнытып җибәрде.

Кәнәфигә кырын ятып, ул каһвә эчә-эчә фикерләрен бер тәртипкә китерде: иң әүвәл залим атасы, мокыт татар аны ятим калдырып киткән, бары тик анасының фидакарьлеге

аркасында гына тәрбия алган, үскән шул Җаһидәнең Җаһидәлеге бүген бөтенләй юкка чыкты.

Елларча боргычлап кертелгән тәрбия нәтиҗәсенең бер мизгел эчендә юкка чыгуы Җаһидәгә авыр булды. Әмма ул аны күңеленнән мәңгегә чыгарып ташлады. Һәм ул анасының хата тәрбиясеннән аерылды. Бераздан соң ул үзен чын хөррият мохитендә калгандай хис итте.

Бу - аның өчен олы бер җиңү иде. Ләкин югалтулары белән бергә ул анасын да югалтты. Ана кешенең кечкенә баласын укытыр өчен, аңа тәрбия бирер өчен гомерен багышлап, фидакарьлекләр кылган каһарманлык сыйфатлары бүген очып китте. Шуңа күрә, анасына булган хөрмәтнең зур бер өлеше кимеде, аның урынында сәер хис кенә торып калды.

Бу хис тә «ни өчен мине атасыз калдырдың» дигән үпкә илә сызлана-борчыла, бу әче үпкәнең сызлавы аның әнисенә булган шәфкатен, мәрхәмәт хисләрен басып китә иде.

Ул анасын яклап калыр өчен, бу гөнаһларны әбисенә сылтап, дәү- әнисен гөнаһлы санарга тырыша иде, әмма анасын да бөтенләй үк гаепсез санамый иде.

Моннан соң анасы белән мөнәсәбәтенең ничек булачагы турында ул бик озак уйлады. Ләкин бер карарга килә алмады. Шөкер, хатларны укыганнан соң, анасын очратмаганына сөенеп, ул хисләре суынсын өчен, бераз вакыт көтәргә булды. Мөнәсәбәтләр элеккеге кебек булмас, һичшиксез, була да алмаячак иде.

Шуңа күрә, Җаһидәнең бүгенге хиссият җәһәте шактый тузган- искергән тәрбия-акыл мәйданына чыкмыш хәлдә иде. Анасына, аның бичара хәлдә калуына, мескенлегенә, ихтыярсызлыгына ачуы чыга, анасының үз дәрәҗәсен, үз язмышын һәм бәхетен үз аягы белән таптаганына ачына һәм анасынын ни өчен рәхәт тормышын ташлап, ни өчен мул хәятен фида иткәнен һәм нинди шикле гыйбадәт йортында үзен корбанга чалганын аңлый алмады.

Бөтен бу вакыйгалардан соң ул, ниһаять, атасын тапты. Бу хатлардан ул атасы аны сөячәгенә, үзенә чын мәгънәсендә ата булачагына аның күңелендә тузан хәтле дә шөбһә калмады. Фәкать, һәрнәрсәдән алда ул атасының кулын үбәргә теләде.

Якташлары, туганнары һәм көймәдә күргән кызкайларның барысы да самими, гөнаһсыз балалар иде. Монда да аның шиге юк иде. Анасының урынын алган, шул балаларның анасы, атасының тормыш аркадашы булган сәламәт хатын... Өйнең, гаиләнең нигез ташы - ул... Кызык, ул Җаһидәне ничек каршылар икән?

Ни булса да булыр, Җаһидә атасын һәм аның гаиләсен тапты. Моннан соң ул үзе дә үз гаиләсе уртасында булачак. Ул шуңа охшаш нәрсәләр турында уйлый иде. Тиз генә барып, атасын очратырга кирәк иде...

Бүлмәсенә керде...

Күршеләрнең бакчасы буп-буш иде, беркем дә күренми. Бәлки, алар киткәндер.Чынлыкта, Анадолуда эшләүче дәрәҗәле һәр кешенең хәле шундый инде аның, бүген монда, иртәгә башка җирдә. Агачларга эленгән су коену киемнәре Җаһидәгә өмет өсти иде. Ләкин атасы белән күрешү алдыннан булган куркусы һаман кимеми.

Кич булды. Бакчада һичбер хәят әсәре күренми. Җаһидә ятагына керсә дә, берничек тә йокыга китә алмады. Әйтерсең лә, ул нидер көтә. Соңгы көймәнең килер вакыты да җитте. «Гаҗәп, шәһәрдә куна калдылармы икән?» дип уйлавы булды, бакчада тавышлар ишетелә башлады. Лампаны кабыздылар... Җаһидә бөтен гаиләнең чәй табыны янына утырганын күргәннән соң, иртәгә нәрсә эшләячәген рәткә салып, рәхәтләнеп йокыга китте...

***

Сабый чактагы бәйрәм көннәрендәге кебек, Җаһидә куаныч белән ятагыннан торды да юынмыйча, бизәнмичә, купальнигын киеп, туп-туры диңгезгә таба йөгерде. Аның хәзерге хәяте, киләчәк хәятеннән чагыштырмаслык дәрәҗәдә аермалы булачак иде. Ул яңа хәятенә рухан пакьлек белән кергәне кебек, җисмән дә сафлану максаты беләнме,

җисемендәге һәм рухындагы керләрне соңгы тапкыр диңгезнең тозлы суында юып җибәрер өченме диңгезгә бара? Ул турыда уйламыйча кыз диңгезгә таба йөгерде һәм иртәнге саф сәгатьләрдә яр буенда беркем дә булмаган чакта суга чумды, озак йөзде, коенды. Диңгезнең салкынча суында аның күңеле тынычланды. Зиһене ачылды, ашыйсы килде. Йөгерә-чаба өенә кайтты да, йотлыгып иртәнге ашны ашады һәм бүлмәсенә кереп, атасы белән очрашырга хәзерләнә башлады. Чәчен тарады. Күлмәген алыштырды. Соңгы тапкыр көзгегә бакты, атасы белән ни турыда сөйләшә башлаячагын кабатлап алды.

Йортның хуҗабикәсе очраса, аның белән ничек итеп сүз башлаячагын, балаларга ничек мөрәҗәгать итәчәген артистларча кабатлап, башыннан кичерде.

Ишектән чыктым дигәндә генә аның карашы күрше бакчасына төште. Ата белән балалар йөзү әсбаплары тотып, капкадан чыгарга бара иде, ул кызларның купальникларын, тастымалларын букчага тутыру белән мәшгуль булганнарын күреп алды. Хәзер чыкса да ул өлгермәячәк иде... Артларыннан куып җитеп, урамда үзен тәкъдим итсә, мәгънәсезлек булыр иде. Шулай итеп, аларның диңгездән әйләнеп кайтуларын көтәргә туры киләчәк иде...

Китабын алды, укый башлады. Ләкин китап аның игътибарын үзенә җәлеп итә алмады. Аның эче поша башлады, бакчага чыкты. Урам капкасы янында ул аларны бераз көтеп торды. Ниһаять, өйлә вакыты килеп җитте. Ашарга кайтканнарын көтәргә кирәк иде. Күзләрен юлдан алмаенча һаман көтә калды...

Тормышының иң мөһим борылыш ноктасын тәшкил итәчәк тарихи мизгелләрне көтә иде ул. Ниһаять, алар күренде... Атасы ир оланнары белән - алдан, бераз арттан ханым белән кызлары кайта иде. Җаһидә атасы белән өй каршындагы капка турысында очрашырлык итеп, авыр адымнар белән каршы таба китте. Атасы оланнарына нидер аңлата иде. Шул мәлдә ул каршыга килүче яшь бер кызны шәйләп алды. Җаһидә атасының юлы өстенә басты, атасы килеп җитәр-җитмәстә:

— Бәй атам, мин синең кызың Җаһидә буламын,- диде.

Шул ук мизгелдә ул аптырап калган мөһәндиснең кул аркаларын үбәргә тотынды. Дулкынлануыннан калтырый башлады. Күзеннән аккан яшьләр атасының кулларын чылатты.

Мөһәндис Вахит ни әйтергә дә белми иде.

— Кызым!.. Җаһидә... Синме бу?.. Машалла!.. Ничек үскәнсең син! - диде ул тотлыга-тотлыга. Ул кызны кочаклап алды, маңгаеннан, күзләреннән үбәргә тотынды:

— Сөекле кызым, балам... - дип Җаһидәсенең башын күкрәгенә кысып, күзеннән яшьләр агызып, бушана иде.

Балалар аталарының яшь кенә бер кызны кочаклап үпкәненә аптырап карап тора иде.

Каушавыннан тиз генә арына алмаган мөһәндис нидер әйтергә тели иде.

— Ханым, баксана, кызыбыз Җаһидә, - диде. Ханым тиз генә якын килеп, самими мәгънә белән:

— Хуш килдең, кызым,- диде дә кызны маңгаеннан үпте. Аларны уратып алган балаларга аталары әйтте:

— Бу сезнең апагыз, Җаһидә... - диде.

Икесенең дә дымлы керфекләре арасына сыймаган сөенеч һәм бәхет күзләреннән мөлдерәмә тулып ташый иде.

Кызлар Җаһидәне әйләндереп алдылар да икесе ике кулына ябышты. Сөем:

— Һи!.. Сез безнең апабыз икән лә, нигә бу турыда көймәдә чакта әйтмәдегез?- диде.

Җаһидә елмаеп:

— Шикәрем, ул вакытта мин үзем дә белми идем әле, - диде дә, чәчләрен сыйпап, кызларны сөйде. Ул арада ханым-әфәнде:

— Урамда басып тормыйк. Өйгә керик, - диде.

Җаһидә атасы җитәкләгән хәлдә, гаилә әгъзалары уртасында, үз оясына беренче адымын атлап керде.

Бакчадагы өстәл янына урнаштылар. Хәл-әхвәл сорашылды. Мөһәндис Вахит ишелеп килгән бу бәхетнең ташкыныннан һаман әле сөйләр сүз таба алмый иде. Ханым:

— Атаң сине бик тә сагына иде. Килүең бик яхшы булды. Машалла, син атаңа бик тә охшагансың, - диде.

Җаһидә кызарды. Чыннан да, атасы белән кызы шулкадәр бер- берсенә охшаган иде ки, Җаһидәнең мөһәндис Вахитның кызы икәнлегенә исбатның кирәге-хаҗәте юк иде.

Кызлар да:

— Сез нигә моннан элек тә килмәдегез?- дип балаларча самими сораулар биреп, Җаһидәне мөшкел хәлгә куялар иде. Аналары:

— Апагызны ардырмагыз! Менә, килде бит инде!- диде. Хәлбуки, Җаһидә балаларны ризалату максаты илә:

— Мин атамның исән икәнлеген дә белми идем. Кечкенә чагымда миңа атамның үз иленә кайтып киткәнлеге һәм шунда үлгәнлеге турында сөйләделәр. Атамны, сезне кичә генә таптым, менә килдем, - диде. Ханым белән Җаһидәнең күзләре очрашты. Ханымның карашы Җаһидәне хуплый иде. Ул арада Сөем урыннан торып китте.

Аның артыннан Гөлчәчәк тә торды. Мөһәндис:

— Укуың ничек, кызым? - дип сүз башлады. Җаһидә:

— Лицей тәмамладым да өлгергәнлеккә имтиханнар тапшырып бетердем. Югары уку йортына керергә телим, ләкин кайбер каршылыклар килеп чыкты,- диде.

Ата белән кыз бу хосуста сөйләшкән арада Сөем каһвә китерде. Гөлчәчәк тә кулына шикәр савытлары тотып килеп җитте, әүвәл атасын, соңыннан анасын, аннан Җаһидәне кыстый башлады. Беренче танышу шулай яхшы гына узды.

Җаһидәне өйлә ашына чакырдылар. Ханым аны атасы янына утыртты һәм гаять самими мөгамәләдә булды. Әмма Җаһидә кыенсынып утырды.

Балалар аталарына «әти» дип мөрәҗәгать иткәндә, Җаһидә «Бәй атам» ди иде... Ханымга ни дип эндәшергә дә төгәл генә белми иде. Шулай итеп, гаилә тәртипләренең бозылуына сәбәп алып килгән кеше кебек, ул үзен кыен хәлдә хис итә иде. Ләкин моны аның үзеннән башка берәү дә тоймый иде, һәркем шатлыклы, куанычлы әңгәмәне дәвам итә иде.

Ниһаять, Җаһидә ханымга «әнием» дип эндәшергә булды һәм шулай кылды да. Ханым:

— Кызым, һәркемнең атасы, анасы бары тик бер генә була. Синеке дә шулайдыр. Миңа бары тик «апа» яки «тутам» дип дәшәрсең. Син бу гаиләнең олы баласы, чын хокуклы бер әгъзасыдыр... Мин дә синең бу кардәшләреңнең анасы буламын.

Мәктәптә укыганда укытучысына ялгыш җавап биргән укучы кебек, Җаһидә кып-кызыл булды да:

— Ярар, тутам,- диде.

Ризыклар Җаһидәгә ят иде. Шулпа, аннан соң тавык, камыр белән төрелгән итле бәрәңге - кайнар ризык. Җаһидә гомерендә беренче тапкыр татып караган бу ризыкларны бик яратып ашады. Болардан соң китерелгән ашамлыклар Истанбулча хәзерләнгән иде.

Җаһидә табын янындагы әңгәмәләр вакытында мохиткә ияләшә барды, әкренләп ул гадәти хәленә кайтты.

Аштан соң ханым балалары белән табын яныннан китеп барды. Җаһидә атасы белән бергә - бер утырып калды. Бераз бакчада йөргәннән соң, бакчадагы бер кәнәфигә утырып, сөйләшә башладылар.

Ата кеше белән кыз арасында бик тиз... атасына сәйләп бирде. Атасы бик җитди рәвештә тыңлады һәм ара-тирә сораштыргалады. Ләкин Җаһидә атасының анасы турында сораштырырга базмаганын аңлап, анасы турында озак сөйләмәде.

Шулай итеп, сәгатьләр узып китте. Ата белән кыз елларны тоташтырган кайгыларын, фикерләрен бер-берләренә аңлатты. Ниһаять, мөһәндис сәгатенә бакты. Чәй вакыты килеп җиткән иде.

Җаһидә:

— Бәй атакаем, синең ниндидер эшең бар, ахрысы? - диде. Мөһәндис:

— Чәйгә соңга калдыкмы әллә, дип уйлап куйдым,- диде.

Мин сорап килимме? - диде кыз, атасының «ярый» мәгънәсендә баш какканын күргәч, өйгә кереп китте.

Зур бүлмәдә озын гына өстәл янында, ике кыз белән олы углан аналары белән бергә утырып дәрес хәзерли иде. Җаһидә моны күреп аптырап калды.

Ханым:

— Атаңның чәй эчәсе килә торгандыр... Шулаймы, Җаһидә? Мин дә балалар белән дәрес хәзерләп, чәйне онытканмын,- диде.

Җаһидә:

— Аларга ни укытасыз, тутам?- дип сорады. Ханым:

— Беләсезме, без һаман мәмләкәтебезгә кайтып китү уе белән янабыз. Анда кайтсак, онытмасыннар дип, үз телебездә тарих, әдәбият, дин дәресләрен кабатлыйбыз, - диде.

Җаһидә:

— Тутам, рөхсәт итсәгез, мин дә бу дәресләрдә катнашыр идем,-

Ханым:

— Син бит кунак кеше, соңыннан карарбыз, - диде дә, дәресне йомгаклап, кызларга чәй хәзерләргә кушты.

***

Чәй эчү озакка сузылды. Чәй янына бер камыр ризыгы куелган иде. Җаһидә беренче тапкыр өч чынаяк чәй эчте, камыр ризыгын ашады...

Җаһидәнең көне шулай узып китте. Ул үзен шушы гаиләнең әгъзасы кебек хис итә башлады.

Ятар вакыт килеп җитте. Ханым:

— Җаһидә, сиңа кыз туганнарың белән бер бүлмәдә урын хәзерләттем,- диде дә кызларына да: - Сез апагызны артык алҗытмагыз, иртәгә тагын сөйләшерсез, - диде.

Җаһидә:

— Тутам, мин өемә китсәм? Хуҗа хатын мине эзли чыгар, инде пошамандадыр. Көн буена кайтмадым. Рөхсәт итегез дә, мин өемә китим,- диде.

Кызлар беравыздан:

— Китмә, апа, бергә ятарбыз, - диде. Арадан берсе:

— Мин сиңа көмеш бармаклы, алтын тырнаклы Хан угылы хикәясен сөйләрмен,- диде.

Ханым:

— Димәк, синең монда өең бар?.. Ул вакытта мәсьәлә башка,- диде.

Атасы:

— Апагыз иртәгә иртәнге ашка килер, сез иртәрәк торырсыз да Казан пәрәмәче (ачык пәрәмәч) пешерерсез,- диде.

Олылар үзара пышылдап, бәләкәйләрдән яшереп, ни турындадыр сөйләшеп алдылар да хәерле кичләр теләп, аерылдылар.

Кызлар апаларын капка төбенә чаклы озата чыктылар.

***

Мадам Марика Җаһидәне көтеп утыра иде. Ул Җаһидәнең төшке ашка кайтмаганына борчылып, бер арада аның күрше бакчасында татар гаиләсендә көлә-көлә чәй эчеп утырганын күргәч, борчылырдай куркыныч югып күреп, тынычланган иде. Ләкин төннең яртысына кадәр алар янында утыра калганлыгына кызыксынып, авыраеп беткән күз кабакларын йомдырмаска тырышып, Җаһидәне көтә иде.

Яңа чәчәк аткан гөл кебек, тирә-ягына гүзәллек сирпеп ишектән килеп кергән Җаһидәгә мадам Марика:

— Кызый, сиңа ни булды ул? Мине куркыттың бит. Ни бар? - диде. Җаһидә:

— Бер ни дә булмады... Мин атамны гаиләсе белән бергә таптым, мадам Марика. Көнемне алар янында уздырдым. Белсәң, атам никадәр сөйкемле кеше... Кыз кардәшләрем фәрештә кебек... Ханым да бик тәрбияле, акыллы хатын ки, эчемдәге бөтен фикерләремне укып белә кебек... Бик, бик мәмнүн булдым, мадам Марика,- диде.

Мадам Марика:

— Табигый ки, атасын тапсын да сөенмәсен, имеш, шул мөмкин эшме? Хәзер әниеңә дә хәбәр бир, ул да сөенсен,- диде.

Җаһидәнең йөзеннән кара шәүлә узып китте :

— Юк, мадам, әнием белмәсен. Анам этием белән аерылышкан. Миңа кечкенә чагымнан бирле «атаң үлде», дип сөйләделәр.. Гәрчә атам сау-сәламәт, кардәшләрем дә бар икән, һәм да алар никадәр игелекле кешеләр. Аң бул, анам белмәсен... Башкаларга да бу турыда сөйләмә,- диде.

Мадам Марика:

— Әгәр син теләмисең икән, сөйләмәм,- диде. Әмма эченнән генә:

— Иртәгә иртәнге аштан соң күршем Җәмиләгә сөйләргә татлы яңалык темасы булды,- дип сөенеченнән аның йокысы качты.

Җаһидә җырлый-җырлый бүлмәсенә менде. Күрше бакчага тагын бер кат күз ташлады. Анасы белән атасының бергә төшкән рәсемен букчасыннан алып, бераз вакыт карап торды. Бәхетле рәвештә рәхәт ятагына чумды.

***

Кызчыклар апалары хакында озаклап сөйләште. Аның бу вакытка кадәр өйләренә ни сәбәпле килмәгәнлегенең серен белергә тырыштылар. Балаларча күп төрле фаразлар корып, йокыга талдылар.

Мөһәндис белән Хәдичә ханым да Җаһидә турысында сәйләште. Атасы кызыннан бик тә канәгать иде. Ханым да кызны бик тәрбияле, бозылмаган, саф дип тапты. Хәзер кызны өйгә ияләштерергә, гаиләгә тартырга кирәк иде.

Ханым иренә:

— Әллә, минәйтәм, аны монда әнисе җибәрдеме икән? - дип сорады.

— Юк, юк! Анасы хәзергә берни дә белми. Моның бер очраклы гына эш булганын ул үзе миңа ачык итеп аңлатты. Кызыбыз анасы хакында бик борчуда, әмма мин ул мәсьәләгә артык якынаймадым. Күлмәкләре, фәләннәре, табигый ки, җитешмидер...

Ханым:

— Әлбәттә, иртәгә синең белән Истанбулга төшеп, кайбер нәрсәләр алырга кирәк. Ләкин кызыңның ниләргә мохтаҗлыгы турында белмибез. Мин үзем алтын кул сәгате алырмын, дип уйлыйм.

Мөһәндис:

— Мин ни алсам яхшы булыр иде икән ул? - диде. Ханым:

— Кыз кеше бит һәм дә, сөбханалла, кәләш булырлык бер кыз бала. Син дә берәр затлы нәрсә алсаң. Без атабыздан шундый нәрсәдәр көтә идек. Мәсәлән, бер йөзек, пар алка...

Мөһәндис:

— Әлбәттә, әлбәттә, шулай итәрбез. Әмма күлмәк, җәйге пәлтә- фәлән нәрсәләргә дә ихтыяҗы бардыр.

Хәдичә ханым:

— Минемчә, ул алачак нәрсәләр бездән бүләк булыр. Теләсәң, берничә кат ефәк эчке күлмәк алсак та була. Күлмәк мәсьәләсен монда катнаштырмыйк. Күренеп тора, кызның киемнәре, эчке күлмәкләре бик һәйбәт түгел...

Ир-хатын, иртәгесе көн өйләдән соң Истанбулга барып, бүләкләр алырга карар итте. Кызы турында озак уйлап, мөһәндиснең йокысы качты. Ул бары тик таң алдыннан, әтәчләр кычкыра башлагач кына йоклап китте...

***

Иртәнге кояшның нурлары көзгедә уйный башлагач, Җаһидә күзен ачты. Таң атканчыга кадәр ул тирән йокыга талган иде. Зиһене чиста, тәне сәламәт, күңеле күтәренке иде. Өлгергәнлеккә имтихан тапшырган кичтәге кебек рәхәт йоклады ул. Ләкин ул көндәгедән дә татлырак өметләр белән уянды. Ятагында киерелде. Авызындагы татлы тәмне бетермәс өчен, ашый торган баллы мәмиен йотмыйча торган сабый кебек, Җаһидә дә ләззәтле манзаралар алдында тора иде...

Атасы белән сөйләшәчәк күп сүзләре, аңлатып бирәчәк кайгылары бар аның; «Берни турында да сөйләмәдеме. Юкса, сөйләргә оныттымы?» Ул бүгенниләр турында сөйләшәчәгенең планнарын кора башлады. Ләкин вакыты җитүгә үк ул планнар юкка чыкты. Һичшиксез ул университетка керәчәге турында, тешләре черек Лотфи бәй хакында бүген атасының фикерен сораячак. Соңыннан анасы... Аңа бу вакыйганы ничек итеп аңлатып бирер ул? Ул бу эшләргә ничек багачак...

Борчулы да, татлы да фикерләр уйлап ятканда, аста шапылдаган тавыш ишетелде. Җаһидә «ни булды икән?» дип уйлап та өлгермәде, ачык ишектән бер-бер артлы ике кыз килеп керде, Җаһидәне яткан урынында кочаклап алдылар да үбә башладылар, тиз-тиз:

— Әйдә, апа, тор... Чәй әзер, әннәбез сиңа Казан пәрәмәче пешерде...

Җаһидә кызларны назлап сыйпады:

— Ярый, үскәнем, ярый, шикәрем, юыныйм да хәзер килермен, тутам көтеп тормасын, сез китегез. Әти тордымы әле?

Җаһидәнең «әти» кәлимәсен беренче тапкыр әйтүе иде. Бу сүз аңа бик самими, бик мәгънәле булып тоелды. Кызлар:

— Тор, апа, тор!- дип берсе йомшак башмакларын, икенчесе йорт халатын китереп бирде. Янә дә яшен кебек ялтырап чыгып та киттеләр.

Самавыр өстәл уртасына килеп утырган вакытта гына Җаһидә чәйгә килеп өлгерде. Гәлчәчәк атасы белән әнисенә, аннан соң Җаһидә алдына чәй китереп куйды. Сөем дә табада чыжлап торган ачык авызлы пәрәмәчләрне шул ук тәртиптә Җаһидәнең тәлинкәсенә салды. Җаһидә гомерендә беренче тапкыр күргән, табада чыжлап торган ашамлыкка хәйран калып карап торган арада Хәдичә ханым:

— Бу атабызның иртән ашый торган, иң яраткан ризыгы, ләкин сак бул, ул бик тә кайнар. Теләсәң, бераз серкә сал, яки катык белән аша, теләмәсәң, шулай гына аша. Ләкин берьюлы авызга кабарга ярамас, - диде.

Җаһидә кайнар чәйгә карады. Атасы:

— Барысы да кайнар. Бәлки син каһвә эчәргә телисеңдер? Теләсәң - эч. Әмма ул бу ризыкка ятышмас. Әйдәгез, балалар.

«Бисмилла»,- диде дә катыклы пәрәмәчнең берсен авызына аткарды.

Ханым да аның артыннан серкәле пәрәмәч капты... Ир олан серкәсез, катыксыз пәрәмәч кабып, пешәләнә-пешәләнә өченче пәрәмәчен йотты. Җаһидә пәрәмәч өстенә катык салды. Авызын пешерде бугай. Әмма катык, Истанбул янгынчылары кеби, вакытында килеп өлгерде. Пәрәмәч энҗе кебек тешләр арасында эри бирде. Никадәр тәмле ризык... Җаһидә икенчесен, өченчесен катык белән, байтагын серкәсез, катыксыз килеш ашап бетерде. Атасы кебек ара-тирә чәй эчкәләп куя иде...

Сөйләшү башланды. Һичбер тартынусыз, Җаһидә берсеннән дә калышмыйча пәрәмәчләрне ашады. Өсте өстенә берничә тустаган чәй эчте. Тирләмәде дә, авырлык та тоймады... Бер-ике тустаган эчкәннән соң Сөемгә:

— Әйдә, кил, син утыр, пәрәмәчләрне мин пешерермен,- диде. Ханым:

— Юк!.. Син бит кунак кеше. Вакыты килеп җиткәч, син дә пешерерсең. Йә, ничек, ошаттыңмы? - диде.

— Бик тә тәмле, чок гүзәл... - дип җавапланды. Гөлчәчәк:

— Апам, пәрәмәчне беренче тапкыр ашап багасыңмы? - диде. Җаһидә:

— Ие, Гөлчәчәк...

Гөлчәчәк апасына: «Никадәр бичара икәнсең», дигәндәй карады да:

— Бәйрәмнәрдә дә пешермиләрмени? - дип сорады. Ханым:

— Апаң Истанбулда үскән. Истанбулда мондый камыр ризыкларын пешерә белмиләр, ул безнекеләрнең ризыгы...

Ата кеше:

— Бездә Аллаһның һәр бирмеш көнендә иртәнге чәйгә нинди дә булса камыр ашы бирелә. Бигрәк тә кышын, бае да, фәкыйре дә шунсыз иртәнге аш җыймас.

Җаһидә:

— Бәй ата, сезнең илегез кайда соң? Ир углан:

— Син белмисеңмени? Мин беләмен. Казан шәһәрен беләсеңме? Теләсәң мин аны сиңа харитада күрсәтермен, - дип урыныннан торды. Ата:

— Харитадагы Казанны хәтерлисеңме? Җаһидә:

— Аз-маз шунда...

Ир углан иске хәрефләр белән язылган бер харита алып килде.

Хаританы Җаһидәнең алдына җәеп салды да:

— Менә Идел елгасы, Әстерхан, менә Казан. Бак, бу Казан елгасы булыр. Безнең авылыбыз менә бирედә, шулаймы, эти?

Ата кеше:

— Шулай, угылым, шулай ... дикъкать белән бакты:

— Анда бик суыкмы, эти?

— Әлбәттә, әмма өйләр бик күркәм, пичләр анда мондагы фырын кебек, бик зур, киемнәр тиредән тегелгән, суыктан интегерлек түгел.

Чәй эчеш тәмам булды. Барысы да урыннарыннан торды.

Хәдичә ханым мөһәндискә:

— Теләсәгез, сез Җаһидә белән йөреп керегез. Безнең эшебез бар.

Җаһидәнең сөйләячәк сүзләре әле бетмәгәндер, дип уйлыймын,- диде.

Мөһәндис:

— Кичә көн буе сөйләштек. Бүген иртән әйтерсең лә берни турында да сәйләшелмәгән кебек...

Җаһидә:

— Миңа да шулай тоела, бәй баба.

Хәдичә ханым:

— Атаңа бик зур югалту идең син, ул сине бик юксына иде, барыгыз йөрегез, сәгать ярымнан артык йөрмәгез.

Ир малай:

— Мин дә сезнең белән бергә барыйммы? Атасы:

— Әйдә, углым.

Бала велосипедын алды:

— Син велосипедта йөри беләсеңме, апа? Җаһидә:

— Юк...

— Мин йөри беләм. Мин йөреп килим. Мин Истанбулда да йөри алам. Әмма эти рөхсәт итми.

Җаһидә:

— Соң әлбәттә. Трамвайны күрми калып, астына бәреп керсәң, ни кылырсың? Бу – гомереңә аксак калу яки үлү дигән сүз бит.

Шулай сөйләшә-сөйләшә киттеләр. Юлның яртысында Җаһидә:

— Бәй атам, мин анамның рөхсәте булмаса да университетка гариза бирдем. Сез ничек уйлыйсыз? Дөресме, ялгыш эшләдемме: шуны белергә телимен.

Мөһәндис:

— Анаң ни өчен моңа каршы төшә? Җаһидә:

— Белмим... Ул мине кияүгә бирергә тели!.. Йөзе кызарып чыкты.

— Шундый бер фикерме, юкса... Җаһидә:

— Бар, безнең бер ерак туганыбыз, арадашчы Әсад бәйнең угылы, имеш!..

Мөһәндис:

— Эше нинди аның?

— Дөнья сугышы вакытында Франциядә укыган икән, тәэминат эшләре белән мәшгуль, акчасы күп диләр... Без бик тә кысан тормышта яшибез, шуңа күрә, анамның күзе байлык тарафында...

Мөһәндис:

— Байлыкны кем яратмый икән, кызым! Ләкин гаилә кору мәсьәләсендә ул беренче нигез булмас. Акча тормыштагы беренче максат түгел, бары тик теләгәнеңне эшләргә ярдәм итү өчен бер шәй генә, син ничек уйлыйсың?

Җаһидә:

— Бәй атам, мин укуымны дәвам итәргә телимен. Мөһәндис:

— Ни өчен, кызым, нинди максат белән? Җаһидә:

— Беренчедән, бөтен аркадашларым укырга керде. Мин алардан ким укымадым. Һәм начар укымам да, ни дип әйтим, болай, укымыйча калу горурлыгыма тия. Бу бәлки бала-чагалыктыр...

Мөһәндис:

— Бала-чагалык түгел! Сәләмәт бәдәнле, акылы җитеш булган һәр яшь кешенең күңелендә артта калмас өчен ярыш хисе бар һәм булырга да тиеш! Бу хис тормыш өчен көрәшнең беренче шарты...

Җаһидә:

— Икенче сәбәп: һәр яшь кеше үз тормышына ярарлык бер эш, бер шөгыль табарга тели. Минем дә кулымда берәр һөнәр булса, начар булмас иде, дип уйлыймын.

— Болай уйлавың дөрестер. Хатыннарның тормышындагы беренче эше, вазифасы, һөнәре - балалар тәрбия кылудыр, яхшы хуҗабикә була белүдер, гаилә учагындагы җылыны өзлексез тота белү, бала- чагасын җылыта белүдер. Ләкин хәзерге тормыш шартлары бик нык авырлашканлыктан, өй хуҗабикәсе булырга теләгәннәр өчен бер шөгыль, бер һөнәргә өйрәнү киләчәкнең гарантиясedер. Мин сине югары белемле буларак күрсәм: «Барәм системасы канунынннан файда күрәчәкмен» дип әйтерсең дип куркам!

Яшьләрнең матди байлык туплау уйлары безне - Көнбатышның идеалист балаларын - түземлелек кысаларыннан чыгара. Машаллаһ, син матдиятчелектә мондый гади уйларга кереп батмаган кебек күренәсең! Тагын бер нәрсә бар: югары белем алган хатыннар үз гаиләсенең, шул хисаптан җәмәгатебезнең, безнең биредәге тәгъбирчә «югары катлауның», мәгънәви - әхлаки күтәрелешенә хезмәт итә. Бу нәрсәләр дөрестер. Фәкать гаилә башлыгының һәм хатынының да эшләве, күпчелек фикеренчә, бала-чаганың игътибарсыз калуына сәбәп була. Табигый ки, мондый гаиләләрдә бала-чаганың тәрбиясе түбән була... Анаң ни өчен каршы килде, дисең?

Җаһидә:

— Белмим! Анам, беләсең инде, бәй ата, мондый мантыйкый фикер йөртеп, мәсьәләләрне үзе хәл итәрдәй шәхес түгел. Ул үзен урап алган мохитнең агышна буйсынган кеше. Шул агымга каршы торырга аның теләге дә юктыр, андый куәте дә юк... Ул өзлексез агым уңаена ияреп бара торган хатын. Безнең мохитебез сүнгән мохит, хәрәкәтсез, куркак бер мохиттер. Аннан соң акча мәсьәләсе дә бәлки роль уйный торгандыр...

Мөһәндис:

— Бу эштә акчаның әһәмияте юк, сине укытырлык хәлебез бар, белем алырга мөмкинлек бирербез. Урта белем алганда сиңа ярдәм итә алмаган булсам, аның сәбәпләре

дә юк түгел! Югары белем алуыңа ярдәм итәчәкмен. Мин моны сөенә-сөенә башкарачакмын....Фәкать, кызым, инде нечкә мәсьәләләргә тотынырга тырышып карыйк; сине бу заманга чаклы укыткан, белем биргән, тәрбия иткән, үстергән кеше - анаңдыр. Анаңның хокукы атаң хакыннан күпкә өстендер... Тагын да тугрысы шулдыр ки, минем сиңа карата аталык хокукым бары тик чагыштырмача гына. Бу мәсьәләдә анаңның фикере белән гамәл кылуың кирәктер... Әгәр бу мәгъкуль булмаса, сөйләшеп, уйлап багарбыз... Икенче мәсьәләгә килгәндә: бу эш гаять мөһимдер. Бу киләчәгеңнең соңгы юнәлешен, соңгы маҗарасын сайлаячаксың яки бу ялгыш юл, яки дөрес юл булачактыр. Биредә ата-ананың вазифасы баланың язмышын бергә ачыклаудан гыйбарәттер; бары тик соңгы карарны бала үзе чыгарырга тиештер. Пәйгамбәребез моның кебек мәсьәләләр өчен: «истәфти калбәкә вә ин әфтәкел мүфтун», (Сиңа дәлаләт иткәннәр сине никадәр үзләренә тартырга теләсәләр, син соңгы карарны үзеңнең кальбеңнән алырга тиеш) дигән. Әгәр күңел теләсә, сөйләнгән дә мәгъкуль күрелсә, эш башкача булыр...

— Хәер, бәй ата, катгыян мондый эшкә (анама буйсынырга) теләгем юктыр. Ул шәхескә карата миндә читләшү хисе бар.

Мөһәндис:

— Ул чакта бу бәхәс темасы булмас!.. Җаһидә:

— Анам шулай эшли... Үҗәт рәвештә шулай эшли. Мөһәндис:

— Син миннән бу мәсьәләдә ярдәм итүемне көтәсеңме? Җаһидә:

— Мин япа-ялгызым, бәй ата... Әлбәттә, сездән акыл, нәсихәт, ярдәм телимен.

Мөһәндис:

— Кызым, бу мәсьәләдә анаң үз хокукын явыз ният белән кулланырга тели... Табигый ки, аның үз уе бардыр, ләкин ул монда да ялгыша. Бәлки чарасызлык, тормыш авырлыгы аны мәҗбүр итә торгандыр. Моны син яхшырак беләсең. Шулай булгач, аның өстеннән бу хәят йөгенең авырлыгын алып ташларга кирәк. Бүгеннән соң анаңа йөк булмас өчен, синең бөтен чыгымнарны капларбыз, аннан соң бу минем аталык бурычымдыр. Фәкать бу эшне анаңны рәнҗетә торган рәвештә эшләмәскә кирәк. Беләмен, кызым, анаңның яшәеш мәгънәсе бары тик синдәдер. Аның терәген-таянычын кулыннан тартып алырдай хәлгә керә барасың. Син бу турыда ныклап уйла. Мин дә уйлармын. Аннан соң анаң белән безнең гаилә арасында бер modus viventi булдырырга тиешбез.

Жаһидә:

— Әлбәттә, бәй ата! Мөһәндис:

— Син бу гаиләнең тулы хокуклы баласыдыр, тулы хокуклы әгъзасыдыр... Теләгән вакытыңда өйгә кайтып керә аласың, күченеп килә аласың, ишекләребез, кесәләребез дә сиңа ачыктыр. Фәкать моны анаң минем тарафтан үзенә китереп сугу дип аңламасын иде, аңламасын гына түгел, анаң безнең мөнәсәбәтләргә үз каланчасыннан гына торып карамасын иде. Аңлата белдемме, кызым? Тормышы авыр булуга карамастан, сине ул яхшы тәрбияләгән. Аңа каршы көферлек булмасын иде.

Хәзергә һәрнәрсә шулай дәвам итсен. Соңра тормыш үзе юлын табар. Ләкин тагын кабатлап әйтәмен ки, кызым, син яшьлеген белән анаңа каршы: « Мин хәзер атамны таптым, сиңа ихтыяҗым юк» дип тәкәбберлек белән кизәнмә... Ул бу мәсьәләдә бик тәэсирле халәттә калачак. Аның фикерен, тойгыларын хөрмәт ит, аңа куркыныч янамаганлыгын әкрен-әкрен генә аңлата башла...

Җаһидә:

— Әмма бу бик авыр булачак, этием. Анам мин аңлаган мантыйк буенча гамәл кылмый...

Мөһәндис:

— Шулайдыр, кызым. Син хәзер аны үзгәртә алмассың. Шуңа күрә, ничек булса , аны шулай кабул итәргә һәм үзенә каршы һичбер тарафтан, һичбер төрле мәкерле эш булмаячагын исбат итәргә тырышырга кирәктер. Бу назик эш, теләсәң дә, теләмәсәң дә сиңа вазифа буларак, тормыш тарафыннан йөкләнгән эштер...

Велосипеды белән бер аска төшеп, бер югарыга менеп йөрүче Тимер янә килде:

— Әти, апамның тамагы кипкәндер. Әнә шул татлыханәдәге туңдырма бик тә тәмле.

Җаһидә Тимернең балаларча, дипломатларча сүзенә көлемсерәде:

— Белмим? Синең тамагың кипкәндер, ахрысы. Тимер:

— Ничек сусамыйсың инде? Мин белмимме инде? Мөһәндис:

— Ярый, ярый, угылым! Мин дә сусадым. Син тиз генә барып, урын алып куй... Без дә килеп җитәрбез,- диде: - Син берәр чит тел беләсеңме, кызым?-диде.

Җаһидә:

— Французчам ярыйсы гына, бәй атам. Сөйләшү тәҗрибәм бик яхшы булмаса да, уку-язу кыен түгел. Башлангыч мәкәптә өч ел иске язу белән укыдым. Ул да эшкә ярап куйды. Әдәбият, тарих дәресләрендә иске китаплардан файдаландым...

Мөһәндис:

— Университетның кайсы факультетына керергә телисең?

— Хәзергә катгый карарым юк! Тарих яки әдәбият уңай килер кебек, атам, әмма тыйп факультеты булса, тормышта тагын да кулайрак түгелме?

— Гаризаң йөри торсын. Факультет сайларга әле вакыт бар.

Сәгать унике тулып килә! Әкрен-әкрен өйгә таба киттеләр.

Сатучыдан җиләк-җимеш алып, өйлә ашына кайтып җитештеләр.

Хәдичә ханым Җаһидә өчен бүген пилмән пешергән икән. Җаһидә моңа чаклы татып карамаган бу ризыкны үзенә табак тутырып биргәч, курка калса да, башлагач, берсен дә калдырмыйча ашап бетерде.

Атасы икенче тәлинкәсен, Хәдичә ханым да үзенә тагын ярты тәлинкә салып алган вакытта Җаһидә үзенә тәкъдим ителгән өлештән баш тармады, «миңа да ярты тәлинкә салыгыз», диде. Моннан соң килгән ризыклар да Җаһидәгә таныш түгел иде. Боларын да ул бик яратып ашады.

Хадичә ханым:

— Җаһидә, ашаганнан соң без атаң белән шәһәргә китәчәкбез.. Өйдә син иң олы кеше буларак калырсың. Кардәшләрең сиңа амәнәт булыр. Безгә кунаклар бик күп киләчәк. Без киткәч килер булсалар, ачык йөз белән каршы алырсың. Туганнарың таныш-белешләребезнең барысын да белә. Гаилә беләнме, әллә бары тик ир белән хатын гына киләме - барысын да кабул итәрсең... Атабыз өйдә юк, ир кунак кабул итмибез, дигән кебек кыланмагыз. Безгә килгән ир кунаклар арасында тәрбиясезе юктыр. Чәй әзерләрсез... Сөем бу эшне бик яхшы белә. Син әңгәмәләр корырсың.

Җаһидә:

— Тутам, мин андый кабул итүләргә ияләнмәгән, булдыра алмам кебек тоела.

Хәдичә ханым:

— Нишләп булдыра алмассың икән? Моның бернинди дә катлаулылыгы юк? «Хуш килдегез, яхшы килдегезме, боерыгыз, утырыгыз»лардан гыйбарәттер инде ул...Аннан соң кунагына күрә әңгәмә башларсың. Куркырдай берни дә юк! Әгәр диңгезгә барсагыз, утларны тоташтырып калдырмагыз. Бу хезмәтче хатынга ышанмагыз. Сез китәр-китмәс йокыга талыр. Баш астындагы мендәрен тартып алсалар да сизмәс. Без өлгерсәк, җидедәге көймә белән, йә булмаса, сигездәгесе белән кайтырбыз. Акшам ашы бераз соңлаячак, әмма зарар юк. Тимер, син апаңны яхшы тыңла, улым! Ул минем урынга кала..,- диде дә тиз генә җыенып, алар көймәгә йөгерде. Балалар аулак калганнарына бик куандылар. Җаһидә балалар белән идарә итә алырмынмы, юкмы, дип бик борчыла иде. Ишек-капкаларны бикләде, барысын да бакчага алып чыкты.

Балалар белән сөйләшеп, дәресләрен хәзерләтә башлады. Һәрберсеннән ни укыганнары турында аерым-аерым сораштырды, китапларын карады. Кайбер яңа мәсьәләләр бирде. Аларның күңеленә ятардай сүзләр сөйләде. Ләкин һәр җае чыккан саен, форсаттан файдаланып, ярамаган эшләр эшләүче Тимерне игә китерү шактый кыенга туры килде. Ниһаять, Җаһидә:

— Син мине тыңламыйсың, Тимер. Мин синең апаң түгелме? Болай кылансаң, үпкәләрмен дә, - дигәннән соң олан тәртипкә керде.

Ләкин Тимернең сәламәт организмы өзлексез хәрәкәт таләп итәчәген уйлап, Җаһидә:

— Тимер, син ир бала бит, бак, сукмакта никадәр чүп бар: шуларны, сынып төшкән ботакларны җый да, сукмакны чистарт...- диде.

Тимер:

— Мин бакчачы булдым, мин бакчачы булдым, - дип эшкә тотынды. Ара-тирә: - Бак, апам, яхшы булдымы? - дип сорый.

Җаһидә аның янына килеп:

— Биредә яхшы, әмма биредә бераз чүп калган. Бу ботакны да алып ат, күзгә төртелерлек булып тора. Менә монысының очларын кис,- дип оланга яңа йомышлар куша торды. Ниһаять, Тимер арыды, кызларның әңгәмәсе дә ахырына килеп җитте. Барысы бердән:

— Апа, чәй эчәр вакыт җитте, - диде.

Җаһидә сәгате-сәгатендә эчелә торган, зилзилә булса да чәйдән баш тартмый торган изге гадәткә һаман ияләшеп бетә алмый иде. Бу мәсьәләдә ул боларның абруйлы йоласына буйсынырга мәҗбүр иде. Зур бер җитдилек белән ул чәй хәзерли башлады. Йокыдагы хезмәтче хатынны да торгыздылар. Тимер олан самавыр куйды. Кызлар чәй табыны корды, Сөем камыр ризыклары, кайнатмалар белән өстәлне тутырды. Кәттә вәкарьлек илә табын янына утырдылар, ләкин һичкем чәйгә үрелмәде. Балалар нидер көтә иде. Җаһидә тирә-ягына караштырып алды:

— Ни көтәсез? - диде.

Йортның гадәт-йоласы таләбенчә чәй эчә башладылар. Балалар да Җаһидәгә ияреп, сүзсез генә беренче тустаганны эчтеләр. Өченче тустаганны эчкәндә тагын сөйләшә башладылар. Дүрт-биш тустаган эчкәннән соң, сөйләшә-сөйләшә ничә тустаган чәй эчкәннәрен дә оныттылар.

Җаһидә дә үзе эчкән тустаганнар санына шаккатты. Чәйдән соң диңгезгә киттеләр. Озын-озак коенып, өйгә кайттылар. Көне буе йоклаган хезмәтчене уяттылар. Аңа Хәдичә ханым әйткән ризыкларны хәзерләргә куштылар. Көймә килергә бераз вакыт булса да, барысы да бергә көймә каршыларга чыкты. Ата-аналарын көткәндә балалар күңелендә туган дулкынлану Җаһидәгә дә күчте. Ул да Истанбулдан килә торган көймәнең вакытыннан әүвәл килмәсен белсә дә, балалар кебек йөгерә башлады...

Көймәдән аталары чыкмагач, ул да балалар белән бергә эчтән генә борчыла башлады. Ниһаять, көймәнең күперчегендә аталары күренде. Балалар белән бергә Җаһидә дә кульяулыгын изи башлады. Һәм балалар белән бергә атасының, тутасының кулыннан капларын алды. Сабый кеби сөенә-сөенә ул да ашыгып атлап китте.

Каплар зур булганлыктан машина тоттылар. Кечкенә сабыйлар шундук машинаны басып алды. Кызлар да машинага утырырга теләде. Хадичә ханым, Җаһидәгә урын калмасын уйлап, ир оланнарга:

— Сез ишәккә атланыгыз, - диде.

Улы сөенә-сөенә ишәк эзли китте. Калганнары машинага кереп тулды. Арттан ике ишәкле, алда бала-чага төягән машина кәрван булып, юлга чыкты. Оланнарның кычкыруы һәм машина тулы кыз сабыйлары арасында мөһәндис Вахит бәхетле хәлдә өенә кайтып җитте...

Акшам ашы хәзер иде, әмма мөһәндис:

— Мин бүген чәй эчмәдем, чәй эчмәенчә ашамам,- дип әйтүгә үк кайнаган самавыр килде. Мөһәндис чәй эчә башлагач, Хадичә ханым да:

— Мин дә эчәр идем! Шул татлыханәләрнең чәе күңелемә һич тә хуш килмәде, - диде.

Ир белән хатын ашка чаклы өч-дүрт тустаган чәй эчеп, ләззәт алгач, ризыкка тотынды.

Ашау арасында Хәдичә ханым Җаһидәдән ничек итеп балалар караганы турында сораштырды. Җаваплардан канәгать булганы турында әйтеп:

— Менә шулай... Өлкәннәр кечеләргә үз тәҗрибәләренән чыгып, фидакарьлек кылсалар, эшләр өзлексез яхшыга таба китәчәк. Фәкать гаилә тәртибен беренче булып үзеңә бозмаска, аннан соң башкаларга да боздырмаска тырышу шарттыр.

Мөһәндис Вахит бәй:

— Кызым, Җаһидә, безнең гаиләдә балаларның туган көнен котлап, бер бәйрәм ясау гадәте бар. Синең туган көнеңә байтак вакыт бар әле, шуңа күрә, гаиләң белән кавышкан, гаиләңнең дә синең белән кавышкан көне буларак, карар кылдык та, гадәтебезчә, гаилә әгъзалары  - һәммәбез бәхетле яшәвеңне теләп, истәлек буларак, берәр кечкенә һәдия хәзерләдек. Менә минем сиңа һәдиям! Рәхәтләнеп тагып-киеп йөр һәм бәхетле бул, кызым, - диде дә, тартмасы белән алмаз ташлы пар алка белән йөзек бирде.

Җаһидә кызарып чыкты, бүләкләрне алды, ул сабыйларча шат иде.

Хадичә ханым:

— Алкаларыңны так, кызым,- диде.

Җаһидә алкаларын такты, йөзеген бармагына киеп куйды...

— Тәшәккүр, рәхмәт,  атам, сез мине бик узындырасыз...

Атасының кул аркасын үпте. Хәдичә ханым бу арада Җаһидәнең кулына беләзекле алтын сәгать тагып куйды.

— Бу минем һәдиям.

Җаһидә хәйран калып, Хәдичә ханымның кулын үпте. Ул урынына утыргач, Сөем:

— Апа, менә минем һәдиям,- дип бер букча сузды. Ачтылар, анда ефәктән, япунча тегелгән бер кимоно иде. Аны күргәч, Җаһидә:

— Нинди гүзәл, ничек гүзәл!.. - дип, Сөемне үпте.

Гөлчәчәк бизәнү әйберләре бүләк итте. Тимер бер кул сумкасы, төпчек туганы Батыр да бер тартма иннек-кершән бирде.

Җаһидә боларны күреп шаккатты, сөенде. Туганнарын аерым- аерым үбеп чыкты, аларны кочаклап сөйде: аның күзеннән яшь ага иде, күз яшьләре аша ул бәхетле елмая иде.

— Тормышымда күрмәгән бәйрәмне, тутам, сез күрсәттегез. Белсәгез икән, мин сезгә ничек рәхмәтле икәнемне. Бурычымны ничек итеп кайтарырмын?

Хәдичә ханым:

— Биредә бурыч-фәлән юк! Барча балаларыбызга да шулай эшлибез. Бу гаиләнең баласы булганыңа күрә, сине дә шулай бүләклибез. Бу синең хакың. Бу һәдияләрне синең үз кардәшләрең, үз теләкләренә күрә, үз акчаларына сатып алды. Вакыты  җиткәч, син  дә аларга бүләк алырсың, - диде.

Җаһидә кыенсынып калды:

— Минем акчам юк шул...- диде. Сөем:

— Дәфтәрең бар бит, шуңа алырсың. Безнең барыбызның да дәфтәре бар...

Җаһидә:

— Минем дәфтәрем юк, шикәрем... Хәдичә ханым:

— Нигә булмасын? Син дә атаңның баласы түгелме? Табигый ки, синең дә «Әманәт сандыгы» дигән дәфтәрең бар, әмма синең әле аннан файдаланганың гына юк,- диде.

Җаһидә:

— Ул ни нәрсә? Мөһәндис:

— Без һәр баланың исеменә һәр ай саен «Әманәт сандыгы»на бераз акча салабыз. Ул дәфтәр аналарында саклана. Балалар шул акчадан үзләренә вак-төяк ихтыяҗларына акча алалар. Кызым, синең дә шундый дәфтәрең бар. Бары тик син бүгенгә чаклы, еракта торганыңа күрә, бу акчаларны алып, файдалана алмадың. Моннан соң теләгәнеңчә файдалана аласың.

Угылына иелеп өстәл тартмасыннан акча букчасын алып килергә кушты. Тимер букчаны алып килде: мөһәндис букчадан бер саклык кенәгәсе тартып чыгарды да Җаһидәгә сузды. Кенәгәне ачкач, Җаһидә күрде ки, беренче булып Җаһидәнең өч-дүрт яшьлек вакытында төшкән фоторәсеме килеп чыкты, ул шаккатты. Рәсем артына язылган тарихына карады:

— Димәк, шул көннәрдән бирле син мине онытмадың, атам? Хәдичә ханым:

— Ата-ана баласын онытырмы?

Җаһидә дәфтәрне актара башлады. Һәр битнең артына йомгак саннары язылып куелган иде. Бу саннар алга таба арта барган. Саннар йөзгә җиткән, йөзләр мең булган. Узган елның нәтиҗәсенә бакты, берничә мең лира акча тупланган иде.

Җаһидә атасына:

— Бу минем акчаммы? Болар кайдан шулай җыелган, әтием?

Минем акча салганым юк.

Хәдичә ханым:

— Бу балаларга кайдан килсә, сиңа да шуннан, атаңнан... Ләкин болар кайбер шартлар белән салынган. Балалар балигълыкка ирешкәнче атасының имзасыннан башка бу акчаны ала алмый. Синеке дә шулай салынган, әмма син хәзер балигълыкта, теләгән чагыңда син теләгән кадәр акча ала аласың...

Җаһидә дәфтәрне атасына бирде.. Мөһәндис:

— Теләсәң, синдә калсын, кызым, бәлки ихтыяҗың килеп чыгар,-

Җаһидә:

— Юк, бәй ата, рөхсәт итсәгез, бары тик карап кына алыймчы.

— Ал, ал,- диде ата кеше.

Бәйрәм бүләкләре, сөйдәшүләр белән көн узды, ятар вакыт җитте. Һәркем үз бүлмәсенә кереп китте.

***

Җаһидә мадам Марикага бөтен бүләкләрен күрсәтте, ниләр булганын сөйләп бирде. Бүлмәсенә кереп китте, урынга ятканда саклык кенәгәсен ачып, тикшерә башлады. Кенәгә анасы белән атасының аерылышырга йөргән вакытларда ачылган булырга тиеш. Шул вакыттан бирле һәр ай саен аз гына күләмдә акча салына барган. Фәкать алга таба гына сумма арта барган, кай чакларда елына берничә йөз лира җыелган. Җаһидә хатларда атасының «акча салмаячакмын» дигәнен хәтерләде. Димәк ки, атасы аның укуы-тәрбиясе өчен анасына акча җибәрмәсә дә, банкага сала барган, шул сәбәпле шулкадәр акча тупланган. Димәк, атасы һәрвакыт аның турында уйлаган. Бу хакыйкать аңа бер горурлык, куаныч бирә иде. Шулай куанычлы хәлдә ул йокыга талды.

***

Иртәнге ашны ашап бетерер-бетермәс мөһәндис Вахит Җаһидәне бер кырга дәшеп:

— Кызым, синең кием-күлмәк мәсьәләсе ни хәлдә? Нинди мохтаҗлыгың бар? Вакытыбыз булса, моның белән мәшгуль булырбыз. Уйлап кара әле, сиңа ниләр кирәк?

Җаһидә:

— Атам, үземә күрә бөтен нәрсәм дә бар кебек, кирәге чыкканда, анам ала иде. Ләкин артык нәрсәм юк,- диде.

Мөһәндис:

— Җәйге өскиемең, манто-фәләнең бармы? Җаһидә:

— Бер демисезоным бар. Аны һәр сезонда киеп йөрим, ул миңа ара-тирә хезмәт итә.

Мөһәндис Хәдичә ханымга ым какты. Хатыны килгәч:

— Җаһидәнең күлмәге, эчке киемнәре хакында сөйләшегез дә...

Сез - хатыннар Җаһидәгә ниләр кирәклеген яхшырак аңлыйсыз.

Хәдичә ханым:

— Табигый ки, бу хәлдә нәрсәсе бар - бу киемнәр мәктәп укучысы өчен ярый торгандыр. Бүгеннән соң Җаһидәгә башка төрле күлмәкләр кирәк булачак: ел фасылы саен кия торган пәлтәләр, мех якалы кышлык манто, фасылга ярый торган рәеш киемнәре, эчке күлмәкләр... Шулай түгелме?

Җаһидә:

— Мине баштанаяк яңадан киендермәк буласызмыни? Аннан соң мине беркем дә танымас бит.

Хәдичә ханым:

— Әлбәттә, шулай итәчәкбез! Синнән кечкенә туганнарыңның бөтен нәрсәләре бар. Синең үги кыз шикелле ятим калуыңны атаң да теләми, мин дә аңа разый булмам. Бөтен нәрсәне алачакбыз.

Мөһәндис:

— Бу эшне озакка сузмаенча, бүген үк Истанбулга китәрсез дә, хәл итәрсез. Мин хатыннар белән әйбер алуны сөймим, аннан соң хатыннар ирләре белән кибеткә керсә, сатучылар артык бәя сорый. Шулар өстенә без-ирләрнең мондый эшләргә эчебез поша башлый. Сез икегез барыгыз... Төсләрне, килешләрен сайлаганда Җаһидә теләгәнчә эшләгез, сыйфатын бәһасен син карарсың. Иске әйберләр алмаска тырышыгыз.

Хәдичә ханым:

— Ярар, алайса, без хәзер үк китик. Син балалар белән өйдә калырсың. Яныңда бераз акчаң бармы?

Мөһәндис:

— Бар, бар. Әзерләнә торыгыз: хәзер бирәм. Хәдичә ханым балаларга:

— Без апагыз белән Истанбулга китәбез. Сез атагыз белән каласыз. Өйне яхшы багыгыз.

Кызлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә:

— Әни, мине дә алып бар, мин дә Истанбулга барам. Мине дә ал.

— Син теге көнне бардың, -дип сатулаша башладылар. Хәдичә ханым:

— Атагызны ялгыз калдырачаксызмыни? Атагызны кем карар? Аны сөймисезме әллә? - диде.

Кызлар шым булды. (Җаһидә Хәдичә ханымның бу хәлдән ничек чыгачагын күзәтеп тора иде.)

— Ярый, берегезне алам, берегез өйдә олы кыз булып калачак. Атагыз янына кунак килсә, кем табын әзерләячәк? Туганнарыгызны кем карар? Җәгез, шобага салыгыз. Ләкин кемгә Истанбул чыга, башкаларыгыз тавыш чыгармый, разыймы сез?

Кызлар эчтән генә:

— Аһ, миңа чыкса, - дип дога укый башладылар. Хәдичә ханым:

— Жирәбә чыкканыгыз - Истанбулга. Башлагыз...

Кызлар шобага тота башлады. Истанбул Гөлчәчәккә чыкты. Хәдичә ханым:

— Сөем, кара, шобага синең олы кыз икәнлегеңнераслады. Атаңны яхшы кара..,- диде дә җәһәт кенә җыенып, көймәгә йөгерделәр.

Көймәгә утыргач, Хәдичә ханым Җаһидәне салонга алып керде. Каһвәчегә бер тустаган каһвә китерергә кушты да кесәсеннән бер кәгазъ чыгарды:

— Хәзер үк ниләр алачагыбызны язып куйыйк. Әйдә, сөйлә. Җаһидә:

— Тутам, валлаһи, мин белмимен, бөтен нәрсәм бар кебек. Хәдичә ханым:

— Ярый, ни телисең? Җаһидә:

— Көзлек бер пәлтә булса инде... Хәдичә ханым:

— Ярый, яздым, аннан соң? Җаһидә:

— Белмимен. Хәдичә ханым:

— Нигә белмисең? Демисезонлык бер манто. Җаһидә:

— Бар, тутам. Хәдичә ханым:

— Кайчан тегелгән ул, кызым? Җаһидә:

— Ике ел әүвәл. Әле тузмаган. Хәдичә ханым:

— Анысын яңгырлы көнне киярсең. Кунакка-фәләнгә кияргә бер яхшы пәлтә кирәк булыр. Кышкы киемең бармы?

Җаһидә:

— Минем бервакытта да кышлык өчен аерым мантом булмады...

Суык көннәрдә эчтән свитер кия идем.

Хәдичә ханым:

— Мөһәндис Вахитның кызына бу килешмәс, кызым. Кышлык пәлтә алырбыз. Ничә матур күлмәгең бар? Ничә данә эчке күлмәгең?

Җаһидә:

— Ике-өч кат бардыр. Хәдичә ханым:

— Ярый,ярый. Минемчә, барысын да яңа баштан алырга кирәк.

Аннан соң елдан-елга яңарту уңай булыр.

***

Хәдичә ханым Галатадагы әйберләр ала торган кибеткә кермичә, машина яллап, Җаһидәне туп-туры Солтан-һамамы янындагы элеккеге кәрвансарайга урнашкан конторага алып китте, мөдир бүлмәсенә керделәр.

Хәдичә ханым мөдиргә:

— Кызыбыз өчен бераз күлмәклек кирәк иде. Безгә яңа өлгеләрне күрсәтсәгез иде, Җәлал бәй.

Мөдир Җәлал бәй каһвә белән чәй китерергә кушты. Мөһәндиснең хәлен сораштырды да, күлмәклек, мантолык комач үрнәкләрен китертте.

Хәдичә ханым Җаһидәгә:

— Шулардан сайла, - диде.

Җаһидә Гөлчәчәк белән бергәләшеп:

— Бусы яхшы. Бусы да гүзәл, бу да матур,- дип һичберсенә туктый алмадылар.

Хәдичә ханым мөдиргә:

— Кызыбызга иң әүвәл демисезонлык пәлтә кирәк. Аннан соң кыш кия торган манто, ләкин беренче сыйфатлы комачлардан булсын, - диде.

Мөдир өлгеләрне алды, берничәсен аерып куйды. Җаһидә сайлаган бер үрнәкне күрсәтеп:

— Бусы бик арзан малдыр. Сезгә ярамас. Менә шушылардан ошатып сайласагыз...

Берничәсен җәеп салды. Хәдичә ханым да сайлашырга килеп катнашты. Берсенең төсен ошатмады. Икенчесе бик юка булды. Берсен затсызга чыгарды. Мең мәшәкать белән ике мантолык һәм берничә яхшы күлмәклек комач сайлап алдылар. Хисапны өзеп кайтып киткәндә бер кибетенә кереп, астарлыклар алдылар. Бу эшләрдән соң эчке күлмәкләр сата торган зур гына бер кибетенә керделәр. Хәдичә ханым алты кат эчке күлмәк китерергә кушты. Аннан соң оек кибетенә кереп, алты пар оек алдылар. Аяк киеме сата торган кибеткә керделәр дә, ике пар түфлә китерергә куштылар.

Тамаклары ачты. Бер шашлыкчыга кереп, тамак туйдырдылар. Соңыннан Бәйугылы тарафына чыктылар. Җаһидәнең мантолыгын, пәлтәлеген тегүче остага бирделәр.

Хәдичә ханым Җаһидәгә:

— Хәзер әйтеп бир инде, син яңгырлык ябынчаны, ягъни плащны кайда күрдең? - диде.

Аны да табып алдылар. Каплар күбәйде, күтәреп йөри алмаслык хәлгә килде. Барысы да арып бетте. Бер татлыханәгә керделәр. Хәдичә ханым кәгазенә бакты: бөтен нәрсәләр алынган кебек. Җаһидәдән:

— Берәр нәрсә алырга онытмадыкмы икән? - дип сорады. Җаһидә:

— Барысын да алып бетердек,- диде.

Берничә тустаган чәй эчкәннн соң, Хәдичә ханым:

— Җаһидә, әниеңне күрмәгәнеңә күпме булды? Атаңны тапканыңнан аның хәбәре бармы? Юктыр. Шулаймы? Анаңны бер күрсәң, начар булмас иде. Ул сине югалтмасын.

Җаһидә борчулы уйга калды:

— Мин анам белән ничек сөйләшәчәгемне белмим,тутам, һәм куркамын.

Хәдичә ханым:

— Шулаен шулай, әмма аны борчуга салу дөрес булмас. Һич булмаса, бер битлек хат яз.

Җаһидә:

«Мин сау-сәламәт килеш ял итәмен. Бер-ике көннән соң сине күрергә кайтачакмын», -дип хат язды.

Такси белән көймәгә килеп өлгерделәр. Җаһидә әйберләр алу сөенеченнән төннең яртысына кадәр йоклый алмады. Бары тик таң алдыннан гына йокыга китте.

Иртәнчәк чәй эчеп, бик тиз урыннарыннан тордылар. Кулына гәзит тоткан килеш, мөһәндис кече угылы белән өстәл янында ялгыз калды. Хәдичә ханым кызларны аш пешерә торган бүлмәгә алып чыкты. Җаһидәгә алъяпкыч бирделәр. Җаһидә киң бүлмәгә кергәч, манзараны күреп хәйран калды. Зур-зур ит кисәкләре, табаклар тулы помидор. Баклажаннар. Тау кебек өелеп торган бәрәңге көшеле. Зур табакларда дөге. Берничә тәлинкәдә атлан май. Төрле-төрле җиләк-җимеш... Әйтерсең лә, бер яу гаскәренә ашарга хәзерлиләр.

Җаһидә:

— Сөбханалла, тутам, боларның барысын да пешерәчәкмесез? Кунаклар күп киләчәкмени?

Хәдичә ханым:

— Киләчәкбез дип ике гаилә телеграмма суккан, бүген иртән китерделәр. Шуңа күрә, вакытым аз калды. Бала-чагалары белән тагын, чама белән, унлап кунак киләчәк. Үзебез җиде кеше. Бәлки тагын берәр кунак килә калса, егерме кеше була, дигән сүз. Безнекеләр ашарга ярата. Табын мул булсын.

Һәрнәрсәне почмактагы ашамлыклар кибетеннән йөз-йөз илле граммлап алырга күнеккән, ике йөз илле грамм ит белән ике көнлек ризыкны беръюлы пешерә торган анасының аш бүлмәсе белән мондагы аш бүлмәсе арасындагы аерма Җаһидәне хәйран калдырды.

Хәдичә ханым кызларның берсенә бәрәңне әрчергә, яшелчәләрне чистартырга кушып, икенче кызына дөге араларга боерды. Җаһидәгә дә зур гына кисәк куй ите турарга бирде:

— Боларны чыпчык башы чаклы итеп тура, зур сөякләрен аерып куй. Вакларын шул килеш калдыр. Менә болай итеп,- диде.

Җаһидә:

— Бу - урманда, учакта пешерә торган шашлык булачакмы?

— Юк. Пылау өчен. Пылау булмаса, шулкадәр кунакларның тамагын туйдыру кыен булачак. Безнең Казан пылауы итле, кишерле була. Күрәсеңме! - Итнең майсыз кисәкләрен Тимергә бирде... Аңа да: - Боларны ит тарткычтан чыгар, туралган булсын! - диде.

Үзе ике капчыктан берәр микъдар ике төрле он алып, шуларны сөт, катык, йомырка катнаштырып болгата башлады. Зур гына бер төпсәгә куйды, киң такта алып, кашык белән бутап, сыра чүпрәсе кушты. Яхшылап изгәннән соң, кояш нурлары төшә торган җылы урынга куйды. Хәдичә ханым берочтан кызларының яхшы, чиста эшләгәннәренә дикъкать итә.

— Бәрәңгедә бозык урын калдырма... Дөге арасында таш калмасын..,- кебек әмерләр бирә тора.

— Җаһидә, ит кисәкләрең бик вак булмасын. Менә шулай яхшы.

Итнең яхшы кисәкләрен генә тура...

Хезмәтче хатын табак-савыт юа, су җылыта. Ашханә фабрика кебек эшли иде. Хәдичә ханым өченче бер капчыкан ап-ак он алды. Бер йомырка сытты. Камыр итеп болгата башлады.

Җаһидә:

— Бу ни була, тутам? - диде.

— Шулпага бераз пилмән салачакбыз. Пилмән пешерәбез,- диде. Җаһидәнең пилмән ашап караганы бар, ул аның тәмен белә.

Әмма ничек пешерелгәнен белми иде. Дикъкать белән Хәдичә ханым эшләгәнне карап тора. Хәдичә ханым ит турап куйган улына:

— Хәзер, угылым, синең эшең беткән булса, атаңнан сәгать ничә икәнне сора да, вакыты килеп җиткәч, пристенгә төш. Ярдәмгә Фатиха ханымны чакырган идем. Өебезне бәлки табалмас, - диде. - Фатиха ханым килсә, җиңелрәк булыр. Ул аш-суга бик оста. Ватанында бер бай гаиләнең кызы, икенче байның килене иде. Әмма биредә бөтен байлыкларын югалтып бетерделәр. Хәзер бик кысан яшиләр. Ярым ярдәмче, ярым кунак буларак гел аны чакырабыз. Кичтән әйткән булсак, иртәнге көймә белән килгән булыр иде... Без телефон чылтыраткан вакытта сәгать сигезенче ярты иде. Белмим инде. Кайсы көймә белән килеп җитәр, -диде.

Эшен бетергән Җаһидәгә:

— Хәзер син шул сөякләрне салкын су белән ю. Каны калмасын.

Аннан соң менә шушы казанга су сал да, утка куй, чама белән тоз сал.

Җаһидә суны утка утыртырга маташканда:

— Бу кадәр суда ни пешәчәк? - дип сорады.

— Шулпа дидем түгелме? Ит шулпасы... Кайный-кайный кими ул. Аннан соң онытма, егерме кеше булачакбыз. Берәр савыттан да - егерме савыт. Безнекеләр пилмән ярата. Кайсылары икешәр савыт ашап бетерә. Хисап утыз була түгелме? Бездә: «Күп булса - бәрәкәт» диләр. «Күп» ни дигән сүз, беләсеңме? «Чок» дигән сүз. Хәзер син, Җаһидә, дөгене ташлардан чистартырга ярдәм ит...

Хезмәтче ханымга:

— Син суган әрче, - диде.

Үзе камыр басуын дәвам итте. Җаһидәгә:

— Күрәсеңме. Бу камыр сузылмый, йомшак түгел бу камыр. Пилмән өчен камыр сузылмалы булырга тиеш. Юкса, ул эчендәге итне тотып тора алмас, тишелер, аннан соң бернигә дә ярамас,- диде.

Озак кына камыр басканнан соң, Хәдичә ханым уклау алды, камыр җәя башлады. Шулкадәр тиз, шулкадәр оста эшли ки, Җаһидә түзеп тора алмады:

— Тутам, сез камырны шулкадәр оста җәясез, гүя моның остасы буларак еллар буе шулай эшләгәнсез.

Хәдичә ханым:

— Бездә һәр кыз ризык әзерли белергә тиеш, бигрәк тә камыр ашларын... Мин боларны бик яшьли өйрәндем. Атаң белән никахлашканыбызга уналты ел тула. Бу уналты елда бер шәһәрдә ике- өч елдан артык яши алмадык. Атаңны беләсең. Анда күпер, монда туннель сала. Әмма ул вакытларда мин мөгаллимә булып эшли идем... Эшемне ташларга теләмәдем. Бер елда бер төбәкнең мәктәбе булса, икенче елда башка бер төбәкнең һөнәр мәктәбендә, соңгы елларда - бер вилаять лисәсендә. Нинди генә фән укытмадым мин? Мин математик идем. Мәктәпкә киләм: «Аман, Хәдичә ханым, тарих, җәгърафия мөгаллимнәребез килмәде. Уку елының яртысы узып бара. Аман, шул дәресләрне дә сез алмассызмы икән?», диләр. Алам! Берничә айдан соң бер мөгаллим китеп бара: «Аман, Хәдичә ханым, санитария дәресен дә укытырга алыгыз инде». Алам! Нишләмәк кирәк, Анадолуда унике ел мөгаллимлек кылдым. Һичбер җирдә кадрлары тулы мәктәпне очратмадым. Хәтта бер ел дәвамында французча укытырга да мәҗбүр булдым.

Җаһидә:

— Һәр яшәгән урыныгызда ничек итеп шулай мөгаллимлек кылдыгыз?

Хәдичә ханым:

— Булдыра алганча укыттым инде. Ул вакытларда Истанбул балалары Анадолуга бик китмиләр иде. Шуңа күрә, Андолуның бөтен вилаятьләре, бистәләре ярым-йорты кадрлар яки булыр-булмас җирле мөгаллимнәр тарафыннан идарә ителә иде. Озак еллар укытырга дип берәр мөгаллим килдеме, аны дүрт кул белән каршылыйлар иде. Әмма мин - атаңа, ул да эшенә бәйле булганга күрә, атаңның эшенә якын башка берәр бистәгә укытырга китә идем. Янә башка бер мәктәптә могаллим булып эшли идем. Мәктәп татилгә

чыктымы, атаңның эш урынына китеп, татилне анда уздыра идем. Беренче елларда авылларда кала торган идем, әмма... Нинди генә михнәтләр чикмәдем. Авыл дигәннәре сезнең мәктәптәге җәгърафия дәресләрендә укый торган, сез күргән рәсемнәрдәге кебек матур авыллар түгел; чын мәгънәсе белән хәрабә хәлендәге авыллар иде... Пычраклык. Кандаланың хисабы юк! Килеп керүгә үк өйне чыстартып чыгарам, бар җирен юам, кандалаларны себереп чыгарам... Бераз тынычлап, рәхәтләнеп калган кебек булам. Озак та узмый, анда бет, монда бет... Яңадан чистарта башлыймын. Тагын бет үрчи! Күршеләрем кердеме, һичшиксез, бет калдырып чыгып китә. Күршене өйгә кертмәү килешми!.. Беренче угылым ике яшендә иде, үсеп килә торган чагы, сөйләшә дә башлаган иде. Күрше балаларыннан тиф йоктырды. Ике атна эчендә күз алдымда балавыз кеби сызды-китте. Бу авыр югалту миңа бик нык тәэсир итте. Каты авырый башладым. Атаң да бик авыр хәсрәт эчендә иде. Көндезен эшкә китә, кайчак ашарга кайта, кайчакларда кайтмый кала. Шуңа күрә, мин япа-ялгыз кала торган идем. Ул вакытта рәхмәтле анам сау-сәламәт иде әле, Искешәһәрдә яши иде. Атаң: «Искешәһәргә, анаң янына кайт. Бераз ял ит, шулай итеп, баланы да онытырсың, күңелең бераз тынычланыр», дип Искешәһәргә китүемне теләде. Мин дә «һәр мизгелдә угылымны искә төшереп торучы өйдә нигә яшим?», дип уйладым, әмма күңелемнән: « Ирем нишләр? Ул көне буе эшләп, арып кайта, өйгә кайткач, аны кем каршылар? Ул ничек ял итәр?» ди идем. Аннан соң анам да мине ачуланып каршылаячак иде: «Ireңне ташлап рәхәтләнеп ял итәргә кайттыңмыни? Сиңа авыр булганны, аңа авыр түгелмени?» дип әйтәчәк иде. Һичшиксез, шулай диячәк иде.

Беркөнне атаң бик үҗәт рәвештә: «Ябыктың, сулдың, бәлки авыл һавасы сиңа ярамый торгандыр, бар, кит инде,» дип кыстады. - Бераздан соң мин сине үзем барып алырмын», диде. Шуннан соң мин разый булдым. Ул мине бистәдәге ыстансага хәтле озата барачак иде. Бер авыл агае ат җигеп килде. Әйберләремне җыйдым, әмма авылдан китәргә һич күңелем тартмый иде.

Сүз арасында Хәдичә ханым җәелгән камырны бүлгәли башлады, кызлар да пилмән ясарга дип аның янына җыелды.

— Юлга чыктык. Бистәгә килеп җиттек. Анда юл салучыларның поезды тора иде,. Мин шуңа утырырга тиеш тә ике сәгатьтән соң төшеп, икенче поездга күчәргә тиеш идем. Атаң мине йөк вагонына урнаштырды. Тимерләр өстенә юрганымны җәеп, урын җайлады. Поездның кайчан китәсе билгеле түгел иде.

Атаң «эшем кала» дип бик борчыла иде. Мин дә: «Булмаса, син кит, көтеп торма» дидем. Китәргә булды, олаучыны эзли башлады. Юата-юата минем белән күреште. Шул мәлдә безнең поезд сигнал бирде, кузгалып киткән кебек, тартылды. Атаң да арбага утырыргамы, мине озата барыргамы, дигәндәй икеләнеп калды. Кинәттән поезд кузгалды. Башыма: ireң белән кабат күрешә алмаячаксың, дигән уй килде, нәрсәм бар, нәрсәм юк дигәндәй - барысын да алдым да, вагоннан сикердем, йөгерә-чаба арба янына килдем. Поезд инде китеп бара иде... «Мин китмим. Китмәячәкмен» дип, аның муенына сарылдым. Атагыз да: «Син тилергәнсең, ахры. Анаң янына киткәннән ни зыян?» диде. Арбага утырып, кәефсез генә кайтып киттек. Иртәгесе көнне атаң бизгәк

белән авырып, өйгә кайтты. Эшенә баралмады. Тәне кызышканнан-кызыша барды. Аңын җуйды. Шулкадәр курыктым ки, шул пычрак авылда ирсез дә калачамын икән, дип котым очты. Йокым качты. Улымның үлемен дә онытттым. Бөтен куәтемне атагызны коткарып калырга сарыф иттем. Бернинди дә даруым юк,

докторда юк. Белгәнемчә дәвалыйм. Өзлексез юкә чәчәге кайнатып торамын. Аны эчерәм. Инженерларны, осталарны дару эзләргә җибәрәм. Өч көн тырыша торгач, бистәдән көчкә бер доктор китерттем. Килде. Ничек дәвалаганымны сорады. Сөйләдем. «Без дә шуннан артыгын эшли алмаган булыр идек. Яңа чыккан Америка даруы бар, әмма бездә иньекция дә юк, даруы да юк» диде. Хинин бирде. Киңәш иткән булды. «Инде куркыныч үтеп киткән. Кызышуы кими бара. Әгәр сез булмасагыз, шик юк ки, ул үлгән булыр иде.» диде. Димәк, күңелем шуны сизенгән. Атагыз әйбәтләнә башлады. Шул сөенеч белән угылымның үлем хәсрәте арткарак күчте. Шуннан соң атагыз бер чатыр сатып алды.

Җәй артыннан җәйләрне шул чатырда уздырдык (пилмән бөреләә тора). Бу балаларымның һәр берсе аеры-аеры бистәләрдә туды. Халыклары төрле-төрле бистәләрдә.

Җаһидәгә карап:

— Тормыш кинода күрсәтелгән кебек матур-уңай түгел ул,- диде.

Ул арада аш бүлмәсенең ишегеннән Фатима ханым белән Тимер килеп керде:

— Әни, без кайттык,- диде. Хәдичә ханым:

— Бик яхшы булган (пилмән инде бөрелеп бетте). Боерыгыз, Фатима ханым, боерыгыз,- диде.

Фатима ханым аш бүлмәсендәге кайнашка карап:

— -Сез ризыкларны инде хәзерләп тә бетергәнсез... Хәдичә ханым:

— -Юк, юк, Фатима ханым. Байтак эш бар әле. Хезмәтче хатынга:

— Зур җәзвә белән каһвә пешер, - диде.

Фатима ханым белән хәл-әхвәл сораштылар. Җаһидә бу хикәя сөрешендә пилмән бөрергә дә бераз өйрәнә башлады. Фатима ханым:

— Бу туташ кем, Хәдичә бикә? - диде.

Җаһидә «туташ», «бикә» кәлимәләренең ни мәгънәдә икәнен аңламаганга күрә, кызыксынып, Хәдичә ханымның җавабын көтә иде. Кызлар:

— -Бу безнең апабыз. Хәдичә ханым:

— -Безнең олы кызыбыз Җаһидә бу. Интернатта укыды. Быел тәмамлады,- диде дә Җаһидәгә, кызларга бакты. ( Бу тема күршегә сөйләнәчәк рәсми риваять булачак ) Җаһидәгә:

— Фатима ханым ватаныбыз гадәтләрен һич онытмый. Бездә кияүдәге хатыннарга «бикә» диләр. Бәйнең хатыны. Кызларга «туташ» дибез, Истанбулча «кечкенә ханым» мәгънәсендә.

Фатима ханым:

— Аллаһ кичерсен. Машаллаһ, атасына бик тә охшаган икән. Аталарына охшаган кызлар бәхетле була ул. Иншаллаһ, туташ та бәхетле булыр.

Хәдичә ханым:

— Ситдика, каһвә булдымы?.. Шикәре таман гына булсын. Фатима ханым, иртән ашадыңмы?

Фатима ханым:

— Ашадым, ашадым. Шулай да берәр чокыр каһвә булса, начар булмас.

Хәдичә ханым кызларга:

— Тустаганнарны китерегез,- диде.

Тустаганнарга каһвә койдылар. Өлкәннәр аягөсте генә каһвә эчте.

Фатима ханым Хәдичә ханым баскан камырны ачты. Бармагы белән төртеп карады.

— Ничә йомырка сыттың, бикә? - диде. Хәдичә ханым:

— Алтыны,- дигәч:

— Катырак, сөтең бармы? Тагын бер йомырка сытарга кирәк булыр...- диде.

Пилмәннәрне күздән кичерде, әче-төче кабымлыкларга бакты.

— Пылау ничә сагатьтә дәмләнеп бетәчәк?-дип сорады. Хәдичә ханым:

— Кунаклар беренче яртыдагы көймә белән киләчәк. Табынны сәгать бердә әзер итәрбез.

Фатима ханым:

— Доктор килер булса, әче-төче кабымлыксыз булмас. Бераз салырга ярата. Бик яхшы адәм, юкса. Ходай аны ким итмәсен, бөтен хаста якташларына ярдәмгә ашкынып тора. Мөгаллим Салих та башкалардан калышмас. Пылау сәгать ике тулганда биреләчәк, димәк?

Хәдичә ханым:

— Фатима ханым, сез бу эшне яхшырак беләсез. Кызларга:

— Хәзер сез бүлмәгезгә керегез. Юыныгыз, киенегез. Мондагы эшегез бетте. Киенеп алгач, табын хәзерләгез. Фатима ханым казан янында эшсез чуалганнарны сөйми..,-

Җаһидәгә,- Син иң яхшы күлмәгеңне ки. Күлмәкләрегезнең якаларын үтүкләгез. Мин дә бераздан килермен.

Җаһидә кайсы күлмәген кисен икән? Кызганыч ки, күлмәкләре әле тегелеп өлгермәгән. Җаһидәнең үз янындагы күлмәкләре бик яхшылардан түгел шул, шулай да ул өеннән сумкасын алып килде. Юындылар, чәч тарадылар. Күлмәкләрен кия башладылар. Бүлмәгә Хәдичә ханым килеп керде, кызларны күздән кичерде дә, канәгать калды. Җаһидәгә бакты:

— Башка җиңелчәрәк күлмәгең юкмы? Кичә белгән булсам, әзер күлмәк алган булыр идек.... Бирегә кил...- дип үзенең йокы бүлмәсенә алып китте. Гардеробны ачты:

— Теләгәнеңне кия аласың, әмма сиңа таман булмас кебек. Торып тор! Килен булып төшкән чагымнан калган бер күлмәгем бар минем. Бәлки сиңа шул таман булыр. - Кирпеч төсендәге чәчәкле бер күлмәк тартып чыгарды.- Бу бәлки сиңа таман булыр, ул чакларда мин бик чәндер идем. Таман булса, үтүкләп киярсең...

Җаһидә күлмәкне киде, көзгегә бакты. Хәдичә ханым:

— Үзеңә таманлап теккән кебек. Синең күлмәкләрең рәешкә, ягъни кешелеккә кияргә ярамас. Иртәгә тегүчегә барып, күлмәкләреңне үлчәтеп карарсың, берәрсен алып кайтырга кирәк. Тагын түфләләреңне, оекларыңны ки, бизәнгечләреңне так. Хатыннар бар җирдә дә гайбәт сөйләргә ярата, сине ошатсыннар,- диде.

Җаһилә декольтесен бераз тарайтты. Җиңнәрен әзрәк кыскартты. Якасын үтүкләде. Мөкәммәл бер күлмәк килеп чыкты. Хәдичә ханым да чайканып чыкты, күлмәген алыштырды, чәчен тарады:

— Кил, Җаһидә.., -диде,- Җаһидә якын килде, як-ягына каранып алды.- Гүзәл булган, рәхәтләнеп ки. Ул синеке булсын, - диде,- Чәчеңә бик туры килми килүен, берәр җаен табарбыз...

Җаһидә:

— Шулай, әлбәттә, шулай... Башкачарак итеп тегәргә кирәк булыр.

Бу фасонны мин дә ошатып бетермим.

Хәдичә ханым ачылган хушбуй шешәсенә ымлап:

— Бераз сип, ләкин артык булмасын. Сөем дә, Гөлчәчәк тә:

— Әни, миңа да бераз сипче, - диделәр.

— Әле сез ул яшькә җитмәгән. Апагыз кебек сез дә лисәне тәмамлагыз, сезгә дә берәр шешә бирермен,- диде.

Җаһидә көзгегә бакты: чәчәк кеби күлмәге, ялтырап торган алкалары. Беләгендәге беләзекләре, алтын сәгате, бармакларындагы йөзекләре белән ул тәмам башка бер кызга әверелде. Үзен танымаган кебек булды.

Хәдичә ханым:

— Киләсе хатыннарның берсе докторның хәләл җефете. Бала- чагасы күп, әмма һәр хатын кебек җыен юк-бар сөйләргә ярата. Ихтимал, гайбәт сатар өчен синнән «анаңа ни булды-фәлән» дип сораштырачак, сак бул, Җаһидә. Мөгалимнең хатыны гади генә бер хатын. Анадолуда яши-яши вакытыннан алда таушалып беткән. Иренә бик ачулы-үпкәчән .угылы турында дөньяның иң бөек адәме булачак, дип уйлый. Яшьләр сезнең кеби уку яшендә генә. Ләкин алар элеккеге ватаннарына баглы булганнарын онытмыйлар. Ирләрнең атаң белән сөйләшүенә дикъкать ит. Бөтен акыл-фикерләре шунда булыр... Монда утыз ел яшиләр инде. Әмма кунакхандә яшәгән кебек яшиләр. Алар атаңның яшьлек дуслары, бер-берсен бик хөрмәт итәләр. Ихтимал, алар синең анаңны да танып-белә торганнардыр. Алар белән әдәпле бул.

Җаһидә:

— Мин бу киемдә үземне уңайсыз хис итәм,тутам. Атама болай күренергә оялам мин..

Хәдичә ханым:

— Бу күлмәкнең ни уңайсызлыгы бар? Син Сөем кебек мәктәп формасы киеп йөрмәссең бит инде. Һәр дәвернең үз гадәте, үз модасы бар. Һәр дәвернең үз модасын уйлап

чыгара тора. Тормыш - шуларга буйсыну дигән сүз... Шул чикләрнең эчендә булып, файда итмәк, мохиткә буйсынмак лаземдер. Син артык буянгансын. Иреннәреңне бераз гына кызарт ... оялыр идем. Бөтен җирең җитеш. Әйдә, барыгыз, аска төшегез, табын хәзерләгез, мин хәзер киләм.

Көлешә-көлешә, кошлар кебек чыркылдашып, кызлар табын әзерли башладылар. Егерме кешелек озын өстәлгә тәлинкәләр, пычаклар, чәнечкеләр, тустаганнар тезелде. Хәдичә ханым төрле-төрле салатлар, кабымлыклар белән табын бизи, чиләктәге бозлы суга утыртылган шәраб шешәләрен алып ул ире утырачак җиргә өстәл астына урнаштырды. Тимер дә зур самавырны кайнату белән мәшгуль. Кунакларны каршыламак өчен кечкенә баласын ияртеп, аталары пристингә төшеп киткән иде. Табын әзер булгач, кызлар да ... Җаһидә яңа күлмәген, асылташларын тагып, пристенга хәтле барып кайтуны бик шатланып кабул иткән иде дә. Хәдичә ханым:

— Син аларны әлегә танымыйсың, сиңа артык илтифат итәрләр.

Син биредә каршыларсың,- диде, Кызлар китте...

Хәдичә ханым:

— Кара, Җаһидә, бирегә атаң утырачак, аның янына - доктор. Бу тарафта мөгаллим Салих бәй. Башка тагын бер-ике кунак та килеп чыгуы ихтимал. Аларны дәрәҗәсенә күрә утыртырга кирәк булыр. Аларны син түгел, мин утыртырмын. Хатыннар үз чиратлары белән каршы тарафка утырыр. Соңра кунакларның балалары ... Калганнары безнең балалар янына утырыр. Син докторның кызы, могаллимнең угылы белән мәшгуль булырсың. Әмма атаң белән олы кунакларның ашау-эчүләрен дә кайгыртып торырсың. Берәр нәрсә җитешмиме, җитешәме дикъкать итәрсең... Үзләре онытса, тустаганнарына шәрапмы, ни телиләр, шуны сал. Мин бөтен кунакларны карармын. Соңыннан чәй ясау да синең өскә төшәчәк, әмма кыз кардәшләреңә дә ярдәм ит.!

Фатима ханым да өстәл янына килде, һәр нәрсәне күздән кичереп:

— Хәдичә бикә, бар нәрсәм җитеш булды. Пылауны дәмләмәдем, хәзер дәмләячәкмен. Пилмәнне кунак килгәч салырбыз, яме?

Хәдичә ханым:

— Шулай, Фатима ханым, шулай...

Тышта тавышлар ишетелә башлады.. Бер төркем кунак бакча капкасыннан эчкәре керде. Хәдичә ханым Җаһидәне ияртеп, капкага таба китте...

— Боерыгыз доктор бәй, боерыгыз, Әсма ханым. Бу безнең олы кызыбыз Җаһидә... Боерың, Салих бәй, боерыгыз. Мәфтуха ханым, боерыгыз. Балалар, саумысез? Сезне таныштырыйммы! Бу безнең олы кызыбыз Җаһидә...

Җаһидә дә һәммәсенең кулын кысты... Доктор:

— Машаллаһ, нинди зур кыз булгансың! Синең үскән чакта дәү әниең күрсәтмәгәнне күрсәткән иде. Алла рәхмәт әйләсен, шул кадәр дә кире хатын иде. Ике кат йон куфайкы кидерә иде. Бала эсседән чөгендер кебек була, ул һаман үзенекен итә торган иде... Хәзер дә сез ике кат йон куфайкы киясезме соң?

Җаһидә кызарды:

— Юк, доктор бәй! Салих бәй:

— Истанбулда ул вакытларда гадәт шундый иде. Хәзер бала тәрбияләү үзгәрде. Боерыгыз, урыннарыгызга утырыгыз...

Утырдылар, Хәдичә ханым:

— Доктор бәй, тәгамнан алда берәр тустаган чәй эчәрсезме? Тәгамыбыз да хәзер.

Доктор:

— Салих, син ни диярсең?

— Валлаһи, Хәдичә ханым, юлдан килгәч, бер тустаган чәй зарар итмәстер.

Хәдичә ханым самавыр янындагы чәй тартмасыннан алып кечкенә чәйнеккә бер-бер артлы берәр кашык чәй салды. Җаһидәгә:

— Зур тармадан ике кашык, уртача тартмадан бер кашык, бәләкәй тартмадан ярты кашык... Кунаклар килгәч, чәй катнашмасы һәрвакыт шушы микъдарда булыр. Самавыр өстенә чәйнекне куй, карап тор, чәйнек кайнап чыкмасын...

Тустаганнарга чәй койдылар. Зур төпсә белән Җаһидә кунакларга чәй өләшеп чыкты, кыстый башлады. Өлкәннәр бик теләп, берәр тустаган чәй эчте. Җаһидә тустаганнарны икенче тапкыр тутырырга алынды, баш тарттылар.

Хәдичә ханым өстәл астындагы чиләктән шәраб шешәләрен чыгарды, ханымнарның кадехләрен тутырып салды. Мөһәндис бер шешәне алды:

— Доктор, ризыктан алда берәрне атабызмы? - диде. Доктор:

— Кунак хуҗаның колыдыр, теләгәнеңчә эшлә,- диде.

Мөгаллим Салих та баш тармады. Фәкать мөгаллим бәйнең угылына, докторның кызына, Җаһидәгә, балаларга да шәраб салмады. Җаһидә бер Хәдичә ханымга, бер атасына сораулы караш ташлады. Алар урынына доктор җавап бирде:

— Бу шушындагы кымыздан башка нәрсә түгел. Хәер, син кымызның ни икәнен белмисеңдер. Бик яхшы эчемлек.

«Шәрәфегезгә» дип кадехен күтәрде. Кабымлыкларны ашап бетерделәр. Пилмән килде. Җаһидә ирләрне сыйлаудан туктамады: йә шулпа тәкъдим итә, йә - пылау... Яки тустаганнарга эчемлек сала. Хатыннарны да туктаусыз сыйлавында булды.

Мәҗлес кыза башлады. Ирләр ватаннарындагы вакыйгаларны сөйләргә тотынды. Хатыннар балаларының ничек үскәннәре һәм төрекчәгә тәрҗемә ителгән китаплар хакында... Җаһидә кулыннан килгәнчә, барысына да катнашырга тырышты. Хәдичә ханым аңа карашы белән ымлап, ишарә итеп торды. Җаһидәне бу сөйләшүләргә катнаштырырга теләде. Атасы да:

— Кызым, аны бир, моны бир, - дип аңа йомыш куша торды һәм мәҗлесне алып баручы вазифасын үз өстенә алды кебек. Доктор шатлыгыннан өзлексез сөйли, темадан темага күчә. Сабый чагында үз илендә ничек итеп алма бакчаларын басканнарын, ничек итеп бер көн бакча иясе Шәриф бабаның үзен якалап, шәрә калдырганын, ничек итеп шәрә килеш бакчалар арыннан өенә кайтканлыгын шундый кызык итеп сәйләде ки, барысы да егылганчы, эчләре катып көлде.

Мөгаллим Салих бәй һәр сүздән сабыйларча көлә. Хәдичә ханым каһвәдән соң йөреп керергә тәкъдим итте.

Бөтен табынны хуҗабикә белән хезмәтче хатынга калдырып, наратлык сукмагына чыктылар. Хатыннар үзләре аерым төркем булды. Балалар Тимернең велосипеды янына тупланды. Сөем белән Гөлчәчәк яшьтәшләре белән аерым бер төркем булды.

Ирләр салмак кына сөйләшә-өйләшә алар артыннан китте. Җаһидә мөгаллимнең угылы, докторның кызы белән бергә иде. Әдәбияттан, фәлсәфәдән бәхәс ачтылар. Өчесе дә боларның элеккеге тормышларын бик аз белгәнгә күрә, бөек әдәбиятчылар кебек сөйләшә һәм үзләренең хаталы фикерләрендә каты тора иде. Бәхәс кыза барды. Диңгезгә чыгып торган бер аулак борын ярында ирләр туктады, манзараны күзәтә башладылар.

Доктор:

— Бак шушы диңгезгә, каршыдагы атауның түбәсенә карагыз. Казанда Идел ярыннан күренеп торган Ослан тавына охшыймы? Вахит, карале!

Вахит:

— Әлбәттә, әлбәттә, бераз тырышсаң - охшый. Мөгаллим Салих:

— Юк, юк, бу тач Уфаның биек тавы башыннан караганда, Дим елгасының Агыйделгә кушылган җире кебек. Шул атауның киң болыны... Мин шунда куй көтүе йөргәнен күрәмен... Карачы, карагыз, нинди хушис килә. Бу да кылган, кымыз үләненең исе түгелме?

Доктор:

— Әлбәттә, әлбәттә... Кымыз исе килә. Әсма ханым:

— Минем кымыз исенә ул кадәр исем китми, әмма Казаныбызның кызыл алмасының исе - бөтен дөньяда андый ис юктыр.

Икенче ханым:

— Ул алманың тәме... Аның таты... Нидән икән ул, биредә шулкадр күп җиләк-җимеш бар, әмма тәме юк? Бездә туфрак бәрәкәтле!..

Мөһәндис Вахит:

— Алма гынамы соң, Әсма ханым? Валлаһи, ул шалканы, шалканы дисеңме? Аның нинди тәме, ә? Без яшьтәшләр шалкан урларга еракларга, күрше авылларга бара торган идек.

Мәфтуха ханым:

— Ватаныбызда яшелчә юк дәрәҗәсендә аз, әмма кыярыннан, кабагыннан бал тәмнәре килә. Көзен һәр өйдә пешкән кабак бәлешенең исе... Кышның салкын көннәрендә балан бәлеше. Нинди нигъмәтләр!

Мөгаллим Салих:

— Кош итләре! Ниндиләре генә юк, казлары, үрдәкләре... Бездә кар яугач, каз өмәсен бәйрәм итәләр иде, бергәләшеп каз йолкыйлар.... Бөтен кызлар каз өмәсенә чакырыла. Башаяк бәлеше пешерелә. Хәзер дә авызымнан сулар килә. Вахит, хәтерлимсең, Рамазан аенда сәхәр өчен пешерелгән он талканын? Мин аны биредә гомерем буе эзләдем, табалмадым, Адана шәһәрендә онын тапкан идем. Әмма тәме башка иде...

Мәфтуха ханым:

— Ул безнең илдәге ак бал, исегездәме? Юкә чәчәгенең балы нинди хуш исле...

Яшьләр бу буынның ватан сагыну хисләренең никадәр тирән икәнен белгертүче хатирәләрен тыңлаганнан соң, картлар яңадан да сөйләшү темаларын әзерләп торганда, өч-дүрт ишәктән торган кәрванчык башында, Тимер килде:

— Әти, без монда бераз сатулаштык, сәгате ун куруштан, ни әйтерсез?- диде.

Мөһәндис:

— Сезнең барыгызны да алырмы соң?

— Калганыбызга велосипед бар. Мөһәндис ишәкчегә:

— Бер сәгать узса, узсын, өйгә кадәр алып кайтырсың. Һәйдәгез, балалар, - диде.

Бу вакыйга фикер агышын туктатты. Алдыннан татлы-тәмле ризыгын тартып алган бала кебек, доктор аптырап, алга таба атлап китте. Кәрванчык тагын кузгалды. Җаһидә бу юлы атасына кушылды. Бераз йөргәннән соң Хәдичә ханым Җаһидәне чакырды:

— Син нигә яшьтәшләреңнән аерылдың? -диде.

Җаһидә:

— Атам белән бәйләрнең сәйләшүләре кызыклырак, аларның сөйләшүе бик мәгънәле. Яшьтәшләрем нәкъ минем шикелле сөйләшә, минем кебек уйлый. Һичбер яңалык юк. Ни алардан миңа файда, ни миннән - аларга... Бәйләрдән яңа нәрсәләр өйрәнәм. Нинди симпатик адәмнәр. Тәкәббер түгел, тәкәллефле түгел, самими рәвештә сөйләшәләр.

Хәдичә ханым елмайды:

— Шулай, әмма Җаһидә, (яшьләр тарафына күрсәтеп) алар синең яшьтәшләрең. Син биредә яшәячәксең, алар белән уртак тел табарга тырыш. Өлкәннәрнең акылларына, тәҗрибәләренә мәфтүн буларак, яшьлегеңнең зарафәтен корбан итмә.

Җаһидә:

— Ни зарафәт, ни хәрарәт. Артык гади уйлыйлар. Хәдичә ханым:

— Син мәгънәле сүзгә сусагансың. Сиңа өлкәннәрнең мәҗлесе ошый. Хәзергә шулай, теләгәнеңчә эшлә, аннан соң син өй хуҗасы икәнеңне дә онытма. Кунакларны сыйлаганың кебек берәр эш чыкмасын, әйдә,- диде.

Җаһидә «бу вакыт эчендә никадәр мәгънәле сүзләрдән мәхрүм калдым», дип хафаланып, атасының төркеменә килеп кушылды да җаен туры китереп, ояла-тарсына:

— Доктор бәй, сез ватаныгызны шулкадәр сөясез, шулкадәр сагынасыз, алайса, ни өчен кайтып китмәдегез, монда калдыгыз? - диде дә, әллә дөрес эшләмәдемме? дигәндәй, атасына карады.

Доктор:

— Бик яхшы, кызым, бик яхшы сору бирдең. Нәкъ Истанбулча сорау булды бу!

Кулы белән ул артта калганнарны чакырды, тегеләре килеп җитте. Аларга да сорауны аңлатып бирде, аннан соң алар бер җирдә туктадылар...

— Хәзер кара, кызым, бу сорау бары тик синең соравың гына түгел, биредәге яшь буынның, бөтен төрекләрнең дә соравыдыр. Зур дәүләтләре булган хәлдә, ни өчен безнең җирдә яшәп калганнар һәм кайберләренең әйтүенчә, « безнең икмәгебезне ашап яталар?» диләр. Хәзер тыңла. Безнең сезнеке кебек яшь булган дәверебез халкыбызның бөек уянышы дәверенә туры килде. Урыс-Япун сугышы безнең Идел буенда яшәүчеләргә бер зилзилә кебек тәэсир итте. Һәркем йокысыннан уянды. «Безгә дә япуннар кебек куәтле булыр өчен, Аурупа мәдәниятен өйрәнергә кирәк» дигән уй-хыял барлык акыллы башларга да берьюлы кереп урнашты. Моның өчен мөмкинлеге булган һәркем бала-чагасын укырга бирде. Берничә ел эчендә меңнәрчә мәктәпләр ачылды. Меңнәрчә китап басылып чыкты. Тиешле дәрәҗәдә кадрлар хәзерләү көннең иң әһәмиятле мәсьәләсенә әверелде. Доктор, адвокат кебек мәмәләкәтнең идарәи эшләре илә мәшгуль булачак яшьләрне хәзерләү өчен Русия университетлары җитәрлек. Әмма культура таратучы шәхесләрне ашыгыч рәвештә өлгертерлек мәдрәсәләрбез җитәрлек түгел иде. Аннан соң культура эшләребез Азәрбәйҗанга, Төркиягә, Төркестанга баглы иде. Безнең әһелләребез башы белән түгел, йөрәге белән, күңеле белән төрекләрнең бербөтенлегенә баглыдыр. Син Мәхмәт Чәләбинең «Мөхәммәдия» атлы китабын укыдыңмы?

— Юк!

— Биредәге безнең балаларыбыз да укымады. Әмма без өчебез дә, безем бөтен туганнарыбыз, бабаларыбыз, аналарыбыз бу китап өстенә ни кадәр күз яше түктек. Никадәр татлы мизгелләр уздырдык.

Дәүләт идарәсендә утырганнар кушканга түгел, үз күңеле белән Аурупа ысулында укырга теләгән кешеләрне, ягъни булачак мөгаллимнәрне иске гадәт буенча Төркиядә укытырга җибәрәләр иде. Бу яшьләр аурупа культурасын үзләштерү белән бергә «Төрек берлеге»н саклап калырга да тели иде. Моның өчен Төркиягә илебезнең һәр тарафыннан өметле яшьләр күндерелә иде. Боларның да күбесе дарелмөгаллимингә керә, дәрелфөнүн, тарих, әдәбият, илаһият бүлекләренә языла иде. Шулай итеп, даими буларак, Төркиядә бары тик Идел-Уралдан гына да төрле мәктәпләрдә укыган берничә йөз укучы җыела иде. Боларның барысы да туган илебездән акча ала, мәктәбен бетергәч тә ватанына кайтып, мөгаллим, мөдәррис, мөхәррир булыр өчен хәзерләнә иделәр. Боларның беренче төркеме укуларын тәмамлап мәмләкәткә кайтты, анда урын алды, милләт өчен эш башладылар. Һәм егерме укучы студент кайтса, яңадан кырыгы китә иде. Безнең Идел-Уралдан чыкканнар артыннан казагы, кыргызы, Төркестаннан да китә иделәр. Һәммәсенең максаты - биредә белем алып, мондагы культураны үзләштереп, ватанына кайтып, гомуми культура мәйданында яшьләргә белем бирү, тәрбия итү иде... Мин дә, атаң да, мөгаллим Салих та, безем кеби йөзләрчә яшьләр дә шул фикер белән бирегә килдек... Чәч бөртегебез саен алтын бирсәләр дә биредә калырга разый түгел идек... Барчабызны анда вазифа көтә иде. Безнең биредә мөгаллим булып калуыбыз урманга утын алып бару, дип аңлый идек. Мин Фән факультетының соңгы курсында, атаң Риязиянең ахыргы сыйныфында иде. Беренче бөтен дөнья сугышы башланды. Безнең ил белән бәйләнеш киселде. Аннан килә торган акча да килүдән туктады. Юллар ябылды. Барыбыз да бичара хәлдә калдык. Акчасыз, ярдәмсез калган, дошман дәүләттән килгән бу берничә йөз студент ни кылачак иде? Полис безне (урыс) дип, урыс монахлары, урыс шымчылары белән бергә концентрацион лагерьларга япты. Кайберләребезне полис идарәсенә ябып, шпион дип, сорау алдылар. Кайбер мәктәпләрнең мөдирләре:

«Безнең мәктәбебездә Әхмәт угылы Мәхмәт, Хәсән угылы Хөсәен, Али угылы Госман исемле кайбер урыслар белем ала» дип полиска хәбәр бирде. Шәхсән мине дә, атаңны да полискә чакыртып, төрле мәсхәрәле рәвештә сораулардан соң, күзәтү астына алдылар. Бер тарафтан акчасызлык, икенче тарафтан шулай хаксызга гаепләүләр астында елларча яшәү мөмкин түгел иде. Бөтен студентлар җыйналдык, киңәштек, төрек гаскәренә ирекле рәвештә язылырга карар бирдек. Бу Русиягә ишетелгән тәкъдирдә урыс хөкүмәте

ватанда калган гаиләләребезне, туганнарыбызны кулга алачак иде, белмим, никадәр золым кылырлар, гаиләләребезне таркатачаклар, карт аналарыбызны Себергә сөрәчәкләр иде... Ләкин башка чыгар юлыбыз калмады. Үтенеч белән озын хат яздык. Кырыклап студент «Төрек учаклары» оешмасының арадашчылыгы белән Әнвәр пашага мөрәҗәгать иттек. Ул да үтенечебезне укып, яугирләрен чакырган. Полис идарәсенә бөтен русияле төрки студентларның үз яклавында булганлыгын хәбәр иттерә дә безнең белем алуыбызны дәвам итеп, мәмләкәтебезгә кайтып китүебезнең андагы халык өчен файдалы булганы кадәр безнең өчен дә тагын да яраклы, тагын да файдалы булачагын сөйләгән:

«Мәктәпләрдә укуларын дәвам итсеннәр, бер-ике көндә мәсьәләләре хәл ителәчәк» дигән. Чыннан да мәсьәлә хәл ителде. Һәрхәлдә ризык белән тәэмин итү җәһәтеннән булса кирәк, мине тыйббиятнең өченче сыйныфына, атаңны мөһәндис мәктәбенә, байтагыбызны төрле хәрби промышленность мәктәпләренә урнаштырдылар. Мәктәпне бетереп, сугышның соңында дәүләт хезмәтенә кердек. Сугыш беткәч, өйләребезгә, ватаныбызга кайтырга тиеш идек. Сугыш бетте. Әмма безнең максатлы рәвештә монда алган белемебез Русиядә ярамый, дип игълан ителде. Бары тик безнең кебек Төркиядә белем алган зыялылар гына түгел, хәтта бөтен сугыш буена урыс фронтында сугышканнар да Русиядә атып үтерелде. Кайтып китәргә тагын мөмкинлегебез калмады. Кайбер кыю аркадашлар «Мин үзем дә фәкыйрь баласы! Бу эш - байларга кагыла. Минем аларга, большевикларга каршы көрәшкәнем дә, алар алдында гаебем дә юк. Кайтып китәм» дип ватанга киттеләр.. Киттеләр... Әмма кайтканнарның барысын да атып үтерделәр. Без ике ут арасында калдык. Кайберләребез Финләндия, Польша кебек Русиядән аерылган, элек Русиянең колонияләре булган мәмләкәтләргә китте, мөгаллим, тәрбияче буларак, тормышларын кордылар. Кайсылары Ерак Көнчыгышка, хәтта Америкага кадәр китте. Без: «Кая барыйк?» дип уйлап торганда, (Аурупа илләре басып алу) сәясәте белән (Төркиягә һөҗүм иттеләр), Балкан сугышы башланды. Моңа каршы Истикалял, ягъни бәйсезлек сугышы башланды. Без дә: «Ялгыз калган Төрек ватанының бәйсезлеген яклар өчен, милли вазифабыз дип, Анадолуга чаптык. Истиклял сугышында башыннан ахырына чаклы юксыллык, мәҗбүрият кысаларында катнаштык... Хәлим, Фатих, Мостафа кебек байтак татарлар бу сугышларда шәһит китте. Байтагымыз яраланды. Без бизгәк, тиф кебек хасталыклар йоктырдык. Шулай итеп, янә дә исәннәребез Төркиядә калдык. Безнең Итсиклял сугышында катнашкан яткашларыбызның барысы да югары урыннарга менделәр. Без янә элеккеге кебек, кайда авыр эш булса, шул эшкә атылдык, Истанбулның көяз ирләре-җегетләре барырга теләмәгән авыр эшләргә тәгаен ителә идек. Доктор, мөһәндис, мөгаллим, финанс эшчеләре буларак, шушында калдык. Калдык... Әмма хыялыбыз һәрвакыт үз ватаныбыз ягында иде. Ләкин андагы хәл һич тә яхшырмады, киресенчә, начарая гына барды, шуңа күрә, яңадан-яңа мөһаҗирләр килә башлады. Карыйбыз. Яшь утыздан арткан! Тормыш узып бара, гаилә корырга да соңга калып барабыз... Ватаныбызга кайтып, анда халкыбызга хезмәт итү максаты һаман бетмәгәнгә күрә, кайтып китү җаен карый башладык. Ләкин кайтып китү җае табылмады. Шушында өйләндек... Үз мәмләкәтебездәге тормышыбызның бозылган бер рәвеше кебек булса да, ватаныбызда яшәгән кебек үзебезчә яши алмасак та, яшәп ятабыз шунда. Маңгай тире белән казанган икмәгебезнең бәясен кайтарыр өчен, мөмкин кадәреннән дә артыгы белән өзлексез тырышып эшлибез. Минем мондагы җирле доктор-аркадашларым авыруны бер караганы өчен өч лира алганда, мин бер лира алам. Көнен-төнен дип тормаенча, бушка булса да, шәһәрнең бер башыннан икенчесенә җәяү китәм. Атаңның мөһәндис аркадашлары көнгә ике-өч сәгать эшләгәндә, атаң унике сәгать эшли. Мөгаллим Салих, егерме еллык тәрҗрибәле әдәбият мөгаллиме, Анадолуның иң ерак почмакларында Төрек әдәбияты укыта. Финансистларыбыз, мөлекчеләребез, үз ватаннарында булса, бәһасез могҗизалар булдыра торган инсаннар, урта мәктәп белеме алган кече мәгъмурлар кебек могамәләгә дучар булалар һәм кечкенә бер ялгыш-хата җибәрәләр икән, аларны урыннарыннан алалар.

Мөгаллим Салих:

— Шунысын да әйтеп узарга кирәктер, безнекеләрнең телләре дә артык озын. Тәнкыйть итмәгән һичберни калдырмыйлар.

Доктор:

— Дөрес, әмма алар моны чын күңелдән борчылганлыктан, төреклекнең шәрәфенә җанатканнан ачынып эшли. Шулай түгелме? Аларның тәнкыйте бер румлының, бер әрмәннең, бер яһүднең сөенә- сөенә тәнкыйтьләве түгел, күз яше белән чыккан эче аһ-зардыр. Дөресен сөйләгә караганда монда ялагайлык алда йөри. Боларның барысы да чын күңелдән Төркиягә игелек теләгәнлектән эшләнә. Менә, кызым. Шул сәбәпләр аркасында ватаныбызга кайтып китмәдек!

Җаһидә:

— Гафу итегез, доктор бәй! Мин сезне гаепләү рәвешендә сорамаган идем. Ничек итеп, ватаныгызга мәхәббәтегез була торып, сез биредә яшәп калганлыгыгыз турында гына беләсем килгән иде.

Доктор:

— Дөрес. Ләкин син бары тик Истанбул мохитенең баласы. Шулай да, син башка, әмма аркадашларың синең кебек уйламый.

Башка кунаклар да әңгәмәгә катнашты. Сөйләшү озакка сузылды. Вакыт уза торды. Чәй вакыты, шул мокатдәс чәй вакыты килеп җитте. Барысы да өйгә кайтты...

Самавыр кайнатылды. Табын корылды. Һәркем атауның һавасыннан бераз башы өйләнгнән кебек, бик тә канәгать иде.

Җаһидә:

«Ихтимал, мин ярамаган сүз әйттем, ахрысы, аларның ярасына гамьсез рәвештә кагылдым кебек. Аларны рәнҗеттем шикелле», дип борчылды. Ялгыз гына калгач, Хәдичә ханымга: - Мин ахмак сүз сөйләмәдемме, тутам? - диде.

Хәдичә ханым:

— Юк. Юк, безнекеләрдә андый артык төчелек юк. Киресенчә, синнән бик канәгать калганнар. «Туган ил» мәсьәләсендә көннәр буе бәхәсләшелсә дә, артык кызып-бозылышмыйлар. Күрерсең, доктор синең белән тагын да самими булачак.

Җаһидә белән Сөем чәй агыза башладылар. Җаһидә:

— Доктор бәй, сыекмы, катымы булсын? -дип сорады. Доктор:

— Уртача булсын, кызым... Син хәзер бу тормыш эченә керәсең.

Монда синең өчен барысы да яңа, барысы да ят кебек күренмиме?

Җаһидә:

— Шулай, әмма миңа барысы да ошый... Хатыннарның берсе:

— Җан тартмаса, кан тарта,- диде.

Сөем Җаһидәгә тәрҗемә итте. Җаһидә уйлап куйды:

« Дөрес бит, сүз белән аңлатылмаячак, күз белән күрмәячәк бер җеп берлә үземне шушы җәмгыятькә бәйле буларак хис итәмен. Гореф- гадәтләрен яхшы белмим. Ләкин биредә үскән, яшәгән җирем Истанбул мохитеннән тагын да җылырак, самимият булганлыгын сизәмен,»- диде.

Мөгаллим Салих:

— Син, Җаһидә, французча беләсеңме? Җаһидә:

— Укыйм... Мөгаллим Салих:

— Һәрхәлдә син француз әдәбиятын яхшы белә булырсың? Җаһидә:

— Үземә күрә... Мөгаллим Салих:

— Франциядә соңгы елларда яңа бер әдәби агым барлыкка килде.Моның программасына күрә, «башкаларның тормышын яхшы аңлар өчен, әдипләр, мөхәррирләрнең шул мохиттә яшәп каравы шарттыр», диләр. Бу аурупалылар өчен яңа бер хакыйкать. Әмма Шәрекъ әдәбияты моны әллә кайчан аңлаган, дип санала. Гомумән алганда, бу дөрес. Бер Америка миллионеры, никадәр кодрәтле булса да, Максим Горькийның бер романын да яза алмас иде. Безнең биредәге ирләрнең, хатыннарның - барыбызның да рухы җәрәхәтле. Кайбер төрекләрнең уйлавынча, без тормышта артык

акыллы да, хәйләкәр дә түгелбез. Әмма бик тә хисчән кешеләрбез. Бу хиссият бала-чагабызның канына да күчә килә. Шуңа күрә, без башкаларның хәсрәтенә дә самимилек белән хәсрәтләнәбез. Синең өчен менә болар яңалыктыр, кызым. Иске хәрефләр белән укый аласыңмы?

— Укыйм...

— Алайса, элеккеге «Төрек йорты» журналларын укы, бигрәк тә Дөнья сугышына кадәр булган нөсхәләрен. Алар сиңа Төньяк төрекләренең теләкләрен, максатларын аңлатып бирер. Һәм бөтен мәгънәсе белән сиңа аңлашылыр. Атаңның китапханәсендә бар. Аннан соң син, һичшиксез, Казан әдәбиятын укы. Безнең дәрәҗәдә Казан җирле сөйләмен дә аңларсың. Французчадан күчереп язылган биредәге әдәбият белән чагыштыр: ул йөз проңент миллидер.

Җаһидә:

— Укый башлаячакмын, бик кызыксынам. Салих:

— Кызыксынуың яңа киногa карата булган кызыксыну кебек кысыр калмасын. Аны бер тәртипкә салырга кирәк, көч түгәргә-тырышырга кирәк.

Хәдичә ханым:

— Җаһидә әле кунак сыйфатыннан чыкмаган. Аңа артыгын йөкләмәгез,- диде.

Доктор:

— Бу авыр йөк түгел. Яшьләр өчен уку һава кебек табигый бер ихтыяҗдыр. Алган белемеңне яхшы юлда сарыф итү үзеңә зур байлык казану булыр. Без яшь чагында илебездә кызыксынуыбызны Төрек әдәбиятын өйрәнүгә сарыф итә идек. Йортыбызда госманлы шивәсен, бигрәк тә төрек әдәби телен өйрәндек. Безнең беребез да илебездә чакта госманлыча дәрес алган кешеләр түгел. Җаһидә дә бераз китап укыса, үзеннән үзе Казан шивәсенең белгече булыр. Шул телдә сөйләшсәң, халыкларның күбесенә аңлашыла торган бер шивәдер, һәм дә бик бай шивә. Булачак әдәбиятчы өчен белергә тиешле бер телдер.

Бик озакка китте. Әйләнеп-тулганып йөри торгач, сүз янә ватанга кайтып җитте. Чәй янындагы әңгәмә дәвам иткәндә ханымнарның барысы да «бикә» булды. Җаһидә тулысы белән «туташ»лашты. Сөйләшү теле дә ярым-йорты Казанчага күчте...

Чәйдән соң һәркем үз эше белән мәшгуль булды. Яшьләр диңгезгә китте. Ирләр йөрергә чыкты. Хатыннар мөһаҗирләрнең бергә тупланып яшәгәннәре турында имеш-мимеш сөйли башладылар. Атау кунакчыллыгы үз эзенә төште.

Яшьләр диңгездән кайткан вакытта бөтен бикәләрне аш бүлмәсендә күрделәр. Зур өстәл янында әчетелгән камырдан нindидер ризык әзерлиләр иде.

Җаһидә:

— Бусы ни булачак, тутам? -диде.

Ханымнарның берсе:

— Бу - сумса, илебезнең иң мәшһүр ризыгы. Һичбер хөрмәтле кунакны сумса белән сыйламыйча җибәрмиләр. Һичбер туй, бәйрәм сумсасыз булмас.

Җаһидә:

— Илегездә камыр ризыкларын бик күп ашыйлар икән. Ханым:

— Бик күп. Бездә яшелчә бик аз. Ризыкларыбызның күбесе ит белән камырдан ясала. Кышын һавалар бик суык булганга күрә, мичләр иртән иртүк ягыла. Мич дигәнем һәр өйдә мондагы фырынчы миче кадәр зур була.... Шуннан файдаланып иртәнге ашка кайнар камыр ризыгы пешерәләр. Кышын һәр көн кайнар камыр ризыгы була?

Җаһидә:

— Өзлексез камыр ризыгы ашау симертмиме? Ханым:

— Юк, камыр ашлары бик күп төрле була... Җаһидә:

— Ниндиләр? Ханым:

— Коймак, төчегә коймак, әчегә коймак, кара бодай коймагы, белен, тары белене, кара бодай белене, солы белене, борчак белене, пәрәмәч, төчегә пәрәмәч, ачы пәрәмәч, Казан пәрәмәче, мишәр пәрәмәче, кыстыбый, төрле эремчекле май күмәче, ул кара бодай

күмәче, бодай күмәче, сумса, ит сумсасы, эчәк сумсасы, как сумсасы. Аларның исәбе-хисабы юк инде. Аннан соң бәлешләр-фәләннәр кебек...

Җаһидә:

— Минем бәлеш ашап караганым бар. Ханым:

— Син бер төрлесен генә ашагансыңдыр. Бәлешнең бик күп төрләре бар. Безнең ашларыбыз бик бай һәм һәркайсысы бик тә үзгәдер.

Ахшам ашына атауда яшәгән якташларыннан акча эшләре хезмәткәре Хәмит бәй хатынын, балаларын ияртеп килеп керде. Мәҗлес зурайды. Табынга салкын тел, тозлы кыяр, салатлар килде, озак итеп сөйләшсәләр дә, боларга берәү дә йогынмады. Барысы да хатыннар пешергән, майда кыздырылган сумсага ябырылды. Кызган майда кабарып пешкән һәм ашыйсы килүне тагын да арттыра торган сумса иде бу. Хәдичә ханым:

— Әллә нәрсә эшли алмадык инде, - диде аклангандай,- сумсаның бусы итле, бу сумса йомырка белән, бусы баллы булыр.

Җаһидә барысыннан да берәр данә алып ашады, француз күмәченнән бәләкәйрәк булсалар да, мамык кеби йомшак булгангамы, һичбер авырлык тоймыйча, башкалар кеби дүртенчесен, бишенчесен ашый башлады. Доктор  як-ягына каранып алды.

Хәдичә ханым:

— Доктор бәй, чәй кирәкме?

Бөтен ирләргә дә чәй бирелде. Соңра хатыннар да чәй эчәргә теләк белдерде.Яшьләр дә  чәй эчәргә килде...

Чәй берсе артыннан икенчесе эчелә торды. Сумсалар җиңелде, макталды, мәҗлес шулай дәвам итте.

Доктор:

— Хәзер, сез-яшьләр, һөнәрегезне күрсәтегез. Вахит, синең гитараң бар бугай? Бар әле, алып кил. Гармуның бармы?

Акча эшләре хезмәткәре Хәмит:

— Бездә бар иде, алып килмәдек шул. Һәйдә, улым, бар , алып кил. Мөглалимнең угылы эскрипкәсе белән уртага чыкты. Кечкенә бер оркестр барлыкка килде. Яшьләр күмәк рәвештә «Казан көе»н җырлый башладылар. Ханымнар да икенче җырга кушылды. Өченче җыр бик тә озын булды, ирләр дә кушылды. Җаһидә бу җырларны белмәсә дә, аларга иярергә тырышты. Мәфтуха ханым шактый матур тавышы белән бер көй җырлады. Ирләр:

— Яшьлек җырыбыз,- дип... (төшмәгән, кырыгынчы бит, өченче багана) «Агыйдел буйлары»н җырладылар. Күмәк җырлау тора-бара төзекләнә-яраша барды, озын җырлар да, кыскалары да бер-бер артлы җырлана торды. Тик җырлардагы кайгылы аһәң тора-бара шатлыклы аһәңне басып китте.

Җаһидәгә ни өчендер, олуг бер кайгы  аркасында  мәҗлес елый кебек тоелды. Берсе «Туган илкәем»не җырлый башлады. Җаһидә Сөемнән бу җырның мәгънәсен сорады. Җылата торган хәсрәтле бу көйгә катнашмаган кеше булмады. Ирләр, хатыннар, яшьләр - барысы да бер авыздан җырлый,  кайбер  урыннарда  тавышлары  елагандагы кебек калтырый, «Туган илкәем» сүзен гел кабатлап торалар.

Өлкәннәр чын мәгънәсендә хисләнгән  иде.  Җаһидә  атасына бакты. Аның ике күзеннән ике тамчы яшь әкрен генә ике яңагыннан аска таба тәгәри иде. Докторга карады, ул да шул хәлдә иде. Мөгаллим Салихның йөзе дә күз яшенә чыланган иде. Акча эшләре хезмәтчесе елап җибәрмәскә бар көче белән тырыша иде. Аның керфекләре дә чылана башлады... Хатыннарга бакты... Барысы да елый иде. Җаһидә яшьтәшләренә карый алмады... Бу вакыйга Җаһидәнең  бәгырен бөтенләй астын өскә китереп ташлады.

Шундый да күңелле-шат мәҗлестә бу кадәр җитди инсаннарның елап утыруы һәм дә шул көй кебек озын-ерак араларда калган «Туган ил» өчен күз яше түгү һәм сәер, һәм әче ләззәт тә бирә иде кебек. Җаһидәнең дә күңеле тулды, тик ул күз яшьләрен тыеп калды. Сөем белән күзгә күз очраштылар. Озын көй җырлаганда кызчыкның да күзеннән яшь ага иде.

Җаһидә бу юлы түзалмады, керфекләреннән ике бәллүр бөртеге чыгып яңаклары буйлый аска таба тәгәрәде. Ниһаять, ул яшь кунакларга карады. Алар да шул ук хәлдә иде.

Озын көй бетте. Музыка да өзелде. Тирән тынлык урнашты. Һәркем ерактагы «Туган ил»нең хатирәсе хөрмәтенә берничә мизгеллек тынлыкка ихтыяри чумган иде.

Тынлыкны доктор бозды:

— Бу көй бигрәк тә моңлы-авыр булды. Һәйдәгез, яшьләр, бер шаян көй җырлагыз.

«Галиябану»ны уйный башладылар. Башка җырлар да җырланды. Күз яшьләре кипте, күңелләр ачылды. Соңгы көймә китәр вакыт җиткәнгә чаклы мәҗлес дәвам итте. Кунаклар кузгалды, Җаһидә боларның барысын да күптәннән белә кебек хис итте. Әйтерсең лә, ул бик авыр көннәрне, шатлыклы вакытларны алар белән бергә кичергән. «Туган ил» өчен мул түгелгән күз яшьләре Истанбул тәрбиясе алган, аларга ят кеше булып үскән Җаһидә белән алар арасындагы аерманы тәмамән юк итте. Аларның барысы да аңа үз мәктәптәшләре сыман самими могамәләдә булды.

***

Җаһидә иртән зур шатлыгы бар кебек уянып китте. Иртәнге аш янында атасыннан мөгаллим Салих бәй тәкъдим иткән китапны сорап алды.

Хәдичә ханым:

— Китапларның күбесе сандыкларда, әмма кайберләрен укый аласың. Атаңның китап киштәсендә байтак әсәрләр бар. Аларны караштыр, мин дә ярдәм итәрмен, тик бүген өйләдән соң күлмәгеңне үлчәтеп карарга Истанбулга тегүче янына барырга кирәк. Бүген якалысын тегеп бетерергә тиешләр иде. Иртәгә төшке ашка доктор бәйләргә, Әрәнкөй бистәсенә барачакбыз. Син Сөем белән барырсыңмы?

Җаһидә икеләнеп калды:

— Белмим инде, тутам, мин ул тегүче хатын белән сөйләшә алырмынмы соң? Алар «нә гүзәл, нә гүзәл» дип, мине алдамасламы? Бергә барсак, яхшырак булмасмы?

Хәдичә ханым:

— Юк, син инде бала түгелсең, әкрен-әкрен генә үзбашка эш кыла башла, Җаһидә. Кием караганда Сөем карап торыр, үзең дә көзгедән багарсың. Ул тегүче безгә бик күп күлмәкләр тегеп бирде, тагын да тегәр. Шуңа күрә, безне алдамас. Әзер булса, күлмәгеңне алып кайтырсың. Әзер булмаса, иртәгә иртән беренче көймә белән барып алырсың,- диде.

Җаһидә атасының китап тулы киштәләренә бакты. Сөем белән Гөлчәчәк йөгерешеп килде. Том-том китаплар, төпләнгән гәзитләр, һәр шүрлектә йөзләрчә китап. Иске хәрефләр белән басылган бу китапларның хәрефләре дә, кәгазе да, формасы да, төпләнешләре дә бөтенләй башкача иде. Китапларның исемнәре гадәти төрекчә иде. Кычкырып торган атамалар, күзгә кереп торган гыйшык яки маҗара хикәяләре юк иде.

Сөем:

— Бу Габдулла Тукай, бу Мәҗит Гафури, бу Сәгыйт Рәми,- дип берәм-берәм таныштырып чыкты.

Җаһидә китапларны берәм-берәм актарып карый, шигырьләрнең исемнәрен укый, кайберләрен аңлый, кайберләрен Сөемнән сорый. Ул

«Туган тел» шигыренә тап булды.

— Казан шивәсендә бу «Туган» сүзе бик еш очрый. Сөем:

— «Туган»дигән сүз төрекчә «доган» мәгънәсендә килә. Истанбул шивәсендәге «д» бездә «т» шәкелендә әйтелә. Доган-туган. Дуран - торган, кебек...

— И туган тел, и матур тел...

— «Матур» ни дигән сүз?

— «Гүзәл» - димәк. Укыды...

— Никадәр дә гади-самими сүзләр, никадәр мәгънәле, никадәр гүзәл фикерләр язылган монда.

— Һәйдә, тагын бераз укы. Гөлчәчәк:

— Бу балалар маршы кебек, аны һәр бала белә. Җаһидә:

— Әйдә, мин дә өйрәним.

Бер кат укып чыкты. Күзен йомды, ятларга тырышты. Ятлый алмады. Кызлар ярдәм итте.

Сөем:

— Моның үз көе дә бар. Әйдә, җырлыйбыз, син бик тиз өйрәнерсең.

Өч кыз «Туган тел» җырын көйли башладылар. Өч-дүрт тапкыр кабатлаганнан соң, Җаһидә шигырьне дә, көйне дә отып алды.

Шул җырны көйли-көйли китаплар каравын дәвам итте. Сөем Тукайның Истанбул шивәсенә якын шигырьләрен күрсәтте. Җаһидә берничә кәлимәдән башка барысын да аңлады. Бу төрле шигырьләр аңа зур куаныч китерде. Берсе артыннан икенчесен укыды. Кызлар ялгыш әйтелешләрне төзәтә. Җаһидә әкренләп китап эченә керә барды

Сөем:

— Бак, апам, шул шигырьне укы. Бу Тукайның үлеме. Үзе язган. Әмма үлгәнен үзе күргән кебек итеп язган. Моны без яттан беләбез һәм көен дә...

Җаһидә укый башлады:

— И мокатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?

Сөем белгәне кадәр мәгънәсен аңлатып бирде. Җаһидә бер укыды, ике укыды, мәгънәсенә төшенде кебек.

— Әйдә-әйдә, көен дә...

Кызлар шигырьне көйгә салып укый башладылар. Җаһидә дә алар артыннан бер-ике тапкыр кабатлады, көйне отып алды. Аның күңеленә сагыш инде. Кичәге «Туган илкәем»не тыңлагандагы кебек, бәгырендә матәм -хәсрәт хисе уянды.

— Бу бик моңлы-авыр, балалар! Сөем:

— Ие, бу Тукайның үлеме көннәрендә укыла, моны укыганда балалар гына түгел, олылар да елый,- диде.

Тукайның шаян-каһкаһәле шигырьләренә күчтеләр. Аскы яктан Хәдичә ханым:

— Балалар, диңгезгә бармыйсызмыни?

[...]* на бактылар ...

— Юк, әни, бармыйбыз,- диделәр.

Көлкеле шигырьләреннән кайберләрен укыдылар. Балалар өчен язылган хикәяләргә күчтеләр.

— «Шүрәле» нәрсә ул?

Кызлар аңлата башлады, аңлата алмадылар.

— Пәри, урман пәрие.

— Урман пәрие нәрсә ул?

Җаһидә аңлый алмады... Сәгыйть Рәмигә күчтеләр. Гөлчәчәк:

— Без мондагы ике шигырьне яттан беләбез. Менә бусы,- дип
«Мин» исемле шигырьне күрсәтте, сөйләп тә бирде:

— «Мин!» дидем мин, «мин» ди дисәм,
Миңа бер зур көч кирә,
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

Сөем мәгънәсен аңлатырга тырышты. Җаһидә бер кат укып чыкты. Аңламады. Икенче кат укыды.

— Әйдә, сез укыгыз,- диде.

Кызлар мәгънәле рөвештә яттан укыдылар. Җаһидә:

— Аңладым. Әмма никадәр горурлык, никадәр куәт... Кем ул?

Шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен сорады. Кызлар белгәннәренчә сөйләде. Җаһидә:

— Моны мин дә ятлаячакмын, - дип дәфтәренә язды. Берничә мәртәбә кызларга укыды.

Сөем:

— Хәзер кара, апа!! Моны без барыбыз да көйләп сөйлибез. Әйдә, укы, моны син бик тиз өйрәнәчәксең. Җаһидә укый башлады.

Сызла, сызла, сызла, күңлем!
Сызла бертуктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча!

Җаһидә шундук аңлады. Кызлар көен җырлап күрсәтте. Җаһидә моны биш-ун кат укыды, сөйләде, тәмамән ятлап бетерде. Җаһидә Шимал төрекләренең рухындагы иң нечкә тамырларны тапты. Һәм аның бөтен мәгънәви хәятенең серенә ачкыч булды. Бу шигырьнең көе гасырларча елаган бер халыкның гасырларча кичергән кайгы, хәсрәтенең чагылышы иде. Бу көй Җаһидә рухының бөтен каплаулы- ябык якларын ачып салучы ачкыч иде.

— Моның көен кем чыгарган? -дип сорады. Кызлар:

— Моның сүзләрен язган шагыйрь көен дә үзе чыгарган, - диделәр.

Җаһидә:

— Нинди куәтле, ничек кодрәтле шагыйрь!.. Нәкъ халыкның үзе кебек,- диде.

Кат-кат укыганнан соң «Сызла»ны тәмамән өйрәнеп бетерде.

Кызларга:

— Моны өйрәнгәнемне беркемгә дә сөйләмәгез, бер сюрприз ясаячакбыз,- диде.

Чират Мәҗит Гафурига килеп җитте, шул вакыт аскы яктан аяк тавышлары ишетелде. Диңгездән кайткан аталары югарыга менеп килә икән. Кызларын келәм өстенә җәеп салынган китаплар арасында күреп, ул бераз аптырап калды:

— Сез һаман китаплар белән мәш киләсезме? Ашау вакыты җитте. Җаһидә:

— Бәй ата, мин ниләр таптым, яңа бер дөнья ачтым. Бакчы, атам, мин хәзер нинди шигырьләр беләм.

Сәгыйть Рәмидән «Мин»не яхшы итеп укып күрсәтте.... Мөһәндис:

— Машаллаһ, машаллаһ! Мәгънәсен аңлыйсыңмы соң?

— Аңлыймын, атам. Нинди куәтле шагыйрь! Бу горурлык аңа каян килгән?

— Халыкның горурлыгы ул, дүрт йөз ел урысларга баш имәгән, бәгырендә бөек куәт булганына инанган халыкның горурлыгы,- диде.

Ашарга төштеләр. Җаһидә һәр китап турында сөйләде. Хәдичә ханымга:

— Бу китаплар бик гүзәл,тутам, бүген бармасак буламы? Һаман шул Истанбул, һаман шул күпер, һаман шул урамнар, һаман шул әрмәнчә, румча кычкырып кибеткә чакыручы бәндәләрнең тавышы... Бу китаплар ничек гүзәл, пакь...

Хәдичә ханым:

— Тормышта барысыннан да бераз алырга кирәк. Бөтен нәрсәнең чамасы булырга тиеш. Шигырь булды. Хәзер тормышның матди тарафын карыйсы калды. Бүген үлмәгеңне алмасаң, иртәгә кунакта күңелең борчулы булыр. Сөем белән китегез, эшеңне бетереп кайтыгыз.

Гөлчәчәк:

— Мин дә апаларым белән барам, әннә. Хәдичә ханым:

— Анда син нишләрсең икән? Син олы кызыбыз буларак, монда каласың! Кунак килсә, минме чәй куячакмын? Өйдә өч кыз булганда шулай килешерме соң!

Гөлчәчәкне калырга күндерделәр ...

— Күлмәгеңнең эшен тәмамлаганга чаклы көтеп торыгыз. Әгәр мөмкин булмаса, иртәгә сәгать унга кадәр һичшиксез китерсеннәр. Хисапны шунда өзәрбез. Хәзерләнегез.

Җаһидә белән Сөем хәзер булгач, Хәдичә ханым:

— Акчагыз-фәлән бармы? - дип сорады. Җаһидәгә: - Бүген әниең янына бар, бәлки үлчәгәч, таманлау вакытында барырсың.

Җаһидә, аркасына салкын су койган кебек, ап-ак булды.

— Бу кичәдән, бу китаплардан соң ничек итеп барырмын икән? Миңа анда каберлек кебек. Анда минем бер генә уртак нәрсәм дә калмады.

— Хәдичә ханым:Бәлки кабер кебектер, әмма анаңның кабере. Дөньяда анадан да мокатдәс һичбер кем юктыр. Җаһидә, син анаң күңеленә юл ачарга тиешлесең. Авыр булса да, бу синең вазифаңдыр. Анаң борчылып тормасын. Үзеңнең киләчәгең өчен аның белән аңлашмак кирәк. Бәлки Сөемнең анда булуы сөйләшүегезне йомшартыр. Анаң белән бик йомшак сөйләш. Ул да хатын-кыз бит. Ярый, хуш, яхшы йөрегез!..

Җаһидә авыр уйлары белән салмак кына йөреп китте. Апасының кинәттән генә кәефе кырылганына тәэсирләнеп, Сөем:

— Син нигә анаңнан куркасың, апа? Ул сине сөймиме? Җаһидә:

— Син аңламассың, шикәрем, син сабый гына әле!. Сөем:

— Аңлармын, валлаһи!

— Аны ярата идем, хәзер суындым... Ул минем сабый вакытымны атасыз калдырып, ятим итте. Ул атама карата миндә дөрес булмаган хисләр тәрбия итте... Аңладыңмы? Мин гаиләмне үзем эзләп таптым. Ул моны ошатмаячак... Мине сездән аерырга маташачак. Мин алай яшәргә теләмимен. Мин атамны да, сезне дә, тутамны да, докторны да - барыгызны да яратам. Кабер кебек тавышсыз-тынсыз, суык тормышка мин ничек итеп яңадан кайттым,ди?

Сөем:

— Без дә сине яратабыз, апа! Син кабат анда кайтма, барыбыз бергә яшәрбез...

Көймәгә утырдылар, Җаһидә янә шигырьләр турында сөйләшкән булып, бераз гына булса да, хыял дөньясында яшәп, борчуларыннан аерылып торырга теләде, ләкин булдыра алмады...

Күлмәк таманлау эшләре бик яхшы тәмамланды. Өч-дүрт сәгать көтсәләр, күлмәк әзер булачак. Көтәргә булдылар. Һәм теләр-теләмәс кенә анасы янына киттеләр.

— Сөем, әгәр анам мине җибәрмәс булса, син әйтерсең: мин ялгыз гына кайта алмыйм, куркам, диярсең. Ул вакытта бәлки рөхсәт итәр. Әгәр рөхсәт итмәсә, ялгыз гына кайта алырсыңмы?

Сөем:

— Кайта алам, әмма синнән аерылырга теләмимен. Мин дә синең белән калырмын.

Җаһидә көлде. Ишек кактылар, ачучы булмады. Тагын берничә тапкыр шакыдылар, ишек ачылмады. Җаһидә ачкычларын алды. Ишекне ачып, эчкәре керделәр. Өйдә берәү дә юк иде. Билгеле инде, анасы биләмгә чыгып киткән. Сөем бу өйгә кызыксынып карады. Фәкыйрь бүлмәләрне йөреп чыкты:

— Монда кыш көнне бик суык була торгандыр, апам?

Чыннан да, бу өйгә фәкыйрьлек суыгы хаким иде. Анасы белән очрашмаганга Җаһидә сөенде. «Кайттым, сине күрмәдем, шушы арада кайтырмын, мин исән-сау» дип тиз генә язу язды. Анасы кайтыр дип куркып, Сөемне берни белән дә сыйлый алмыйча, өйдән чыгып киттеләр. Трамвай белән Баязит бистәсендә яши торган мөһәндиснең якташлары Камалларга барырга булдылар. Зур гына өстәлдәге самавыр янына утырган өй хуҗалары аларны нәзәкәт белән каршылады.

Сөем:

— Безнең Җаһидә апамыз, - диде. Зарифа ханым:

— Боерыгыз! Машаллаһ, ничек үскәнсең! Нәкъ атаң инде! Аллаһ ярдәменнән ташламсын, - диде.

Камал бәй:

— Өлгергәнлек имтиханнарын тапшырдыңмы? Мөгаллимнәрегез кемнәр иде? Әгәр Риязиягә керер булсаң, фәлән кеше минем сыйныф аркадашым, - диде.

Сөем вакытыннан элек картайган сакаллы бу кешегә:

— Госман абый, мәрхабә! Ни өчен безгә килмәдегез? Атам да кайтты, сине сорады. Безгә килсен, диде.

Сакаллы кеше бераз кызмача иде:

— Киләм! Хәзергә бераз эшем бар. Китап язам. Мин эчсәм, сәрхуш булганчы эчәм, укысам да сәрхуш булганчы укыйм, язсам да сәрхуш булганчы язам. Хәзер дә язып ятам. Китап тәмамлаячакмын. Соңра аны сатып, кием-салым алачакмын. Беләсең, бу киемнәр белән кунакка йөреп булмый. Килермен. Син, туташ, мөһәндис Вахитның кызымысың?

Сөем:

— Маржа түгел инде, Госман абзый, төрек! Госман:

— Барысы да бер иш - маржа!. Урыс марҗасы, төрек марҗасы, нугай марҗасы - барысы да бер иш.

Җаһидә:

— «Маржа» нәрсә ул? Сөем:

— Урыс хатыннарына карата әйтелә торган сүз. Зарифа ханым:

— Боерыгыз, чәй эчегез... Госман бәй артык сөйли ул, әмма аңа ачуланмагыз, зинһар.

Госман:

— Шулай. Ачуланмагыз, ул исерек.. Туташ, синең атаң минем дустым. Әмма ул дурак (ахмак).

Зарифа ханым:

— Госман бәй, мөһәндис бәй ничек дурак булсын? Ул бик тә акыллы адәм...

Госман:

— Акыллы булганы өчен дә дурак ул. Дурак кына да түгел, чүп... Син туташ аларның сүзенә ышанма. Болар татар шовинистлары, татарның һәрнәрсәсе яхшы, имеш! Аның пәрәмәче, пилмәне, аның әдәбияты, аның музыкасы, аның хатыны... Барысы да яхшы, имеш. Минемчә, барысы да чүп. Мин урыс мәмләкәтендә укып белем алдым. Мин объектив рәвештә карый беләм. Урысның үзе дә чүп, чүп булмаса, большевик булыр идемени ул? Бары тик аның аракысы гына чүп түгел, әмма анысы да зәһәр агу... Мине шул урыс аракысы агулады. Минемчә, илебездәге тормышыбыз инде ахырына килеп җитте. Чит илләрдә үлеп калганнарыбызның җеназа намазын укып, җәсәден кем күмәр?

Сөем:

— Госман абый, безгә кайчан килерсез икән? Госман:

— Кайчан килим соң? Сөем:

— Бүгел кил, атам өйдә. Госман:

— Бүген акчам юк... Сөем:

— Бездә акча бар, бергә китәрбез. Госман:

— Әстәгъфируллаһ. Мин адвокат Госман башымнан балалардан акча алыйммы! Мин чүп түгел, мин Госман!

Җаһидә:

— Акчаның ни кадере бар? Акча үзе дә бер чүп түгелме, Госман бәй?

Госман:

— Маладис (афәрин), дөрес! Син атаң кебек акыллы икәнсең. Акча да чүп... Бөтен нәрсә чүп, бары тик мин генә чүп түгел!

«Мин»! димен мин, «мин» ди дисәм,
Миңа бер зур көч кирә.
Аллалар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә

— Чүп кенә... Аннан соң аягүрә басып:

— Аллаһка тапшырдык, чүпләр,- диде дә чайкала-чайкала чыгып китте...

Зарифа ханым:

— Бичара, ватаныбызда зур адвокат иде, монда бер эшкә дә керә алмады... Урысча укыганлыктан, эшкә ярамады, эшсез, көчсез калды, кысанлыкка чыдый алмаенча, эчә башлады. Үзе бик яхшы адәм ул, әмма мөһаҗирлек корбаны... Шулай итеп, шундый

кыйммәтле шәхесләр юкка чыкты. Бу болшевиклар революциясе безгә бик кыйбатка төште. (Кызлар китәргә әзерләнә башлагач) Анагызга, атагызга сәлам әйтегез. Тагын килегез,- диде.

Кызлар тегүчегә барып, күлмәкне алдылар. Кичке ашка кайтып өлгерделәр.

***

Сәгать унике тулганда алар докторларның Әрәнкөй бистәсендәге өендә иделәр инде.

Кунаклар арасында Җаһидәгә таныш булмаган урта яшьлӓрдәге бер хатын гына иде. Аңа яшьләр «Хуҗа ханым» ди, олылар «Хәлимә ханым», «Хәлимә апа» диләр.

Бурса шәһәренә киткәнлектән, мөгаллим Салихлар килә алмаганнар. Чакырылганнарның байтагы килмәгәнлектән, мәҗлестә кеше аз иде.

Хуҗа ханым:

— Мин доктор бәйләргә барган идем. Очраклы гына сезне очраттым.

Хәдичә ханымга:

— Мин картайдым инде, ялкауландым. Өйдән чыкмыймын. Рәхмәтлене югалтканнан бирле, ни булды, белмим, тормыштан кызык тапмыйм... Әүвәл мин татилгә чыгу белән Истанбулга чаба идем. Мин барып күрмәгән һичбер якташым калмады. Безнең кордашлар да азайдымы, нидер?.. Аннан соң балалар белән дә артыгы белән мәшгульмен.

Хәдичә ханым:

— Ничек соң, кызыгыз быел мәктәп бетерәме? Хәлимә ханым:

— Ие, быел «Кызлар мөгаллимә»сенең соңгы сыйныфында. Угылым да Җиңү бәйрәмендә кылыч тагачак. Бала-чага карау йөге җиңеләячәк кебек күренә, әмма... Белмәм, киләчәк ни күрсәтер бит әле. Сигез ел буена илебездән беркемнән дә бер хат та алганым юк... Кем исән, кем үлгән?.. Һич белмимен!.. Төшемә кергәннәр белән яшим. Илдә дүрт кыз кардәшем, өч ир туганым бар иде... Кем белә, кайсысы исән калган?.. Иске заманда хат алышырга мөмкин иде. Хаҗга барып кайту бар иде. Хәзер исә илебездән чын мәгънәсендә төрмә ясадылар. Узган ел безнең Әлазиз бистәсенә Кавказдан качып килгәннәрне җирләштергәннәр иде. Алар белән күрештем... Кавказның бөтен шәһәрләрендә безнең казанлылар бик күп диләр. Большевиклар безнең халыкны яши торган урыннарыннан чит илләргә сөрәләр икән... Безнең Казанга бик күп хахул (украиннар) сөрелгән, ди... Гаҗәп, элеккеге тормышны бетерер өчен, иске йолаларны юк итәр өчен шулай кыланалармы? Белмим. Ул мөһаҗирләрнең бизгәк йоктырган балалары килде. Беләсез инде. Мин укытучы... Әмма анда мин доктор да булдым. Хәзер доктор бәйдән кайбер хасталыклар хакында мәгълүмат алырга, кайбер дарулар сорамак өчен килгән идем. Беләсездер, мәрхүмем, Әлазиздә качакларны урнаштыру вәкиле иде. Мин дә һәрвакыттагы кебек укытучы идем. Ул вакытларда дүрт балам бар иде. Килеп урнашуга безнең балалар авырый башлады. Берсенә корчаңгы йокты. Берсе таз булды. Берсе бизгәк йоктырды.

Безнең бистәдә доктор да, даруханә дә юк... Иске китаплар буенча үзем дәвалый башладым. Соңрак яңа медицина китаплары табып алдым. Очраган бер доктордан сорашмый калмый идем. Балаларымны коткарып калдым. Моны күреп торган күрше-күлән миңа мөрәҗәгать итә башлады. Үтенечләрен кире какмадым. Очраклы рәвештә могҗиза булды, балалар сәламәтләнде. Шулай итеп, тирә-якка минем докторлык шөһрәтем таралды. Бер кызым тифтән, бер угылым, белмим нидән, үлеп китте. Әмма тирә-як кешеләре аңа карамады. Рәхмәтлем-мәрхүмкәй хасталангач, Истанбулдагы байтак докторларга караттым. Үзем дә бик күп китаплар укыдым, яхшы гына авыру карап торучы булып киттем. Аның вафатыннан соң балаларны интернат мәктәпләргә урнаштыргач, үземнән үзем башкаларның кайгысын кайгыртучысы булып киттем. Мәктәптә дәресем бетүгә үк ашымны ашыйм да, туп-туры хасталарым янына... Барысы да мәгълүм: бизгәк, корчаңгы, таз... Белгәнемне эшли идем. Сәламәтлек саклау мөдиренә мөрәҗәгать итеп, дарулар алырга теләдем, ләкин дипломлы булу кирәк иде, бирмәделәр.

«Бер кыска курска кереп укысам» дидем. Әмма биредә андый нәрсә юк икән. Авыруларны карап торучы шәфкать туташлары курсы бар икән. Ул эшне артыгы белән белгәнемә күрә, кермәдем. Хәзер мин анда «Татар апасы» дигән исем белән мәгълүм бер доктормын... (көлде). «Зур хаталар эшләмәгәем» дип, кайбер хасталыклар хакында мәгълүмат алырга дип, доктор бәй янына килдем, әмма шундый күркәм мәҗлесне бозарга теләмимен. Мин башка беркөнне дә килә алам.

Доктор:

— Авырулар берәр нәрсә бирәләрме соң? Хәлимә:

— Мин берни дә алырга теләмимен, шулай да берәрсенең бәбәе туган көндә берсе биш йомырка, берсе бераз май, берсе бераз сыр китерә. Минем хасталарым бик фәкыйрь, мин дә Аллаһ ризасы өчен аларга ярдәм итәм. Аннан соң мөгаллимлек акчам ярыйсы гына. Бүләк- санак та биргәлиләр... Минем даруларым: иң мөһиме: санитария-гигиена кагыйдәләренә хөрмәт тәрбия итүдер. Аннан соң һәр елны Мысыр базарыннан төрле хушисле дару үләннәре алдырам. Алардан кирәк дару эчемлекләре хәзерлим. Табигый. химия катнашкан дарулар эшләмим. Минем хасталарымның күбесе фәкыйрь гаиләләрнең балалары. Аннан соң, безнең якта сифилис күп таралган. Бу хасталыкка каршы, доктор бәй, мәхәллә халкы куллана алырлык очсыз дарулар кирәк. Сифилис андагы кешеләрне кырып сала.

Доктор:

— Сез ни бирәсез? Хәлимә:

— Мин андый авыруларны шәһәргә җибәрәм. Әмма мәхәлләдәге авырулар барырга теләми. Бераз даруым бар. Иң яхшысы сифилисле балага малерия йоктырырга кирәк. Сифилислы балага бизгәк йоктымы, котылды, дигән сүз. Аннан соң мин аның малярисен дәвалап бетерәм. Бәбәй таба торган аналарга иң беренче даруым: анасын, баласын чиста тоту өчен тырышам. Мин гаиләсенә күрә, яңа туган баласын ике-өч атна буена үзем барып яхшылап юындырам, соңыннан анасын да шул эшкә иялэштерәм.

Аш китерделәр. Сөйләшү башка темага күчте. Шулпадан соң Әсма ханым тутырган тавык китерде.

Җаһидә:

— Бу ни? Әсма ханым:

— Бу - тавык тулмасы, безнең илдә аны «тавык тутырмасы» яки «тутырган тавык» диләр. Ашаганнан соң нәтиҗә чыгарырсың да...

— Ләкин моны кем бүләчәк? Әсма ханым:

— Җаһидә, бу җайлы киселми, моны бүлгәләүнең үз ысулы бар.

Аны бар кеше дә белми. Бу эшне яхшы белгән osталар башкара.

Хәлимә ханым:

— Пычагыгыз үткен булса, мин бүләрмен,- диде.

Зур табакта яткан тавыкны алдына алды, һәрбер ботын-чатын аеры турап, һәр буынын шундый уңай итеп икегә бүлде ки, ите дә, йомыркасы да, бер сөяге дә вак кисәккә аерылмады. Аерым-аерым пешергән кеби, һәр кисәкне тәлинкәләргә куйды. Батыр белән докторның кече кызына тавыкның ике ботын бирде:

— Болар һәрвакыт сабыйларның хакыдыр,- диде.

Җаһидә беренче тапкыр күргән бу ризыкны бик теләп ашады. Сөйләшүчеләрнең тутырмалар турындагы сүзләрен дә бөтен табигате белән йотып барды. Йомырка белән тутырылган күркәләр турында да сүз күп булды. Тутырган тавыктан соң килгән өч почмаклы бәлешләр белән ризык кабул итү тәмам булды. Каһвә эчкәндә Әсма ханым, Җаһидәгә иске альбом сузып:

— Илебез турындагы истәлекләрдән бары тик шушы нәрсәбез калды. Бак, анда ничек киенәләр, ничек яшиләр иде...

Альбомда Әсма ханымның милли кием кигән аркадашлары белән төшкән бер төркем, гаилә рәсемнәре аерым-аерым мөхәррирләр, шагыйрьләр, артистларның

рәсемнәре, бәйрәм мәҗлесләре, туй мәҗлесләрендә төшкән сурәтләр, милли кичәләрдә алынган рәсемнәр бар.

Рәсемнәрдә төрле милли киемнәр күзгә ташлана. Күлмәкләр, калфаклар, кәләпүшләр, читекләр, кәвешләр белән гомум киемнәрдә шундый милли аһәң бар ки, боларга карап бу халыкның кайчандыр мөстәкыйль гомер кичергәненә хәйран калмау мөмкин түгел иде.

Җаһидәнең зиһенендә байтак сораулар кыймылдый башлады:

— Боларның барысы да Русиядә түгелмени? Биредәге рәсемнәрдә урыслар кайда?

Хатыннар көлешеп алды....

— Ул безнең мәмләкәтебез. Мең ел элек бабаларыбыз яшәгән йорт. Ул сезгә - Русия!... Бездә беркем дә аңа «Русия» димәс. Анда урыслар юк ... ләкин аларны безнең халык үз тормышына катыштырмый. Урыс анда җандарм, акча эшләренең башлыгы, мәхкәмәләрдә ришвәт алып утыручы вак чиновник. Бездә урыслар белән синле-минле яшәү юк. Казан кебек зур шәһәрләрдә сәүдә мәсьәләләре буенча урыслар белән аралашалар, ләкин һичбер заман алар дус, туган түгел. Урыслардан кыз алу булмаган кебек, аларга да кыз бирү булмас. Әлбәттә, анда да чуар йөрәкләр (марҗага өйләнгән, урыска чыккан бозыклар, шаһвәтпәрәстләр) юк түгел. Кайберәүләрнең марҗа сөяркәләре бар, әмма алар сөяркәләрен гаиләгә якын китермиләр.

Җаһидә:

— Бу киемнәр бик гүзәл, әти! Безнең борынгы бабаларыбызның рәсемнәре бармы?

Хәдичә ханым:

— Кайберләре бар. Ләкин Әсма ханымныкы кебек тәртипләп сакланмаган... Күрсәтербез.

Җаһидә:

— Бу киемнәр бик гүзәл! Әсма:

— Боларның үзенә күрә модасы бар. Кара, бусы яшь кыз киеме. Моның башка төрлеләре дә бар. Ләкин барысына да ике төрле ысул хаким: баштагы калфак белән аяктагы шул читек. Аларның да һәрберсенең рәвеше башка төрле була. Бакчы, бу ханымда калфак никадәр зур, бу кызда уртача зурлык, бу кыз бер генә чәчәк таккан. Ирләрнең киемнәре, һәр җирдәге кебек, гаять муһафазакяр, ягъни искечә була. Ләкин алар да әкрен-әкрен генә киемнәрен кыскарта баралар. Бире кил. Сиңа искедән калган бер күлмәк күрсәтим (кызлары аларга комачтан тегелгән туй күлмәге күрсәтте). Бу - минем никахлык күлмәгем,- диде.

Әңгәмә дәвам иткәндә ишек ачылды. Икенче бер кунак килеп керде. Бу - мөгаллим Фәхри бәй иде. Өй тулы кеше күргәч:

— Нинди гүзәл очрашу! Һәрберегезгә аерым-аерым барырга дип тора идем. Балаларга акча җиткерә алмыйм. Безнең байлар да бик саран кылана. Барыгыздан да ясак алачакмын. Мөнәввәрләр әфәнделәр дә бирмәсә, эшем харап... Хәзер ике ятим баланы Дәруш-шәфәкага, ятимнәр йортына урнаштырырга дип тырышам. Беренче бөтен дөнья сугышында әсирлек дәверендә Русиядә безнекеләрдән зур ярдәм күргән бер полковник бар, дип ишеттем. Шуны эзләп килдем, аның кебекләрдән ярдәм алмасак, эшебез харап. Өен эзләп таптым, әмма аучы икән, үрдәк авына киткән. Тагын бер көн заяга узса, белмим, нәтиҗәсе ничек булыр. Балалар кызганыч. Тырыш, зиһенле балалар. Аналары да, аталары да юк... Якташлар аларны кызганып, урыс арасында калмасыннар, дип качып киткәндә үзләре белән алганнар. Алганнар, әмма үз хәлләре дә хәл. Шундый качаклар өзлексез килә тора.. Карс шәһәреннән хат алдым. Тагын бер ир белән хатын дүрт баласы белән чикне узганнар. Качып барганда ирен үтергәннәр... Тагын мәктәп, тагын акча табарга... (кесәсеннән бер кәгазъ чыгарып) Бисмиллаһ! Доктор бәй, сездән башлыйк булмаса...

Әсма ханым:

— Торып тор, Фәхри бәй, каһвәңне эч... Фәхри:

— Мин шул балаларның тормышларын берничә атнага гына булса да тәэмин итсәм: шул вакытта каһвә тагын да татлырак булыр.

Доктор:

— Дөрес,дөрес, рәхмәт, Фәхри бәй! Син барыбызның да йөз аклыгы. Мондый хәерле эшләр белән маташырга безнең вакытыбыз юк. Ялкаулыгыбыз да юк түгел. Якташлар җәмгыятебезнең ябылуы да начар булды.

Фәхри:

— Ничек кенә начар әле! Аны мин беләм. Һәркемне эшендә, конторында, мәктәптә, кибетендә эзләп тап. Кайберләре бу эшне, имеш, мин үз файдама күрә башкарам, дип уйлый!

Һәркем исемлеккә язылды, бирә алырдай акчасын бирде. Фәхри бәй каһвәсен эчә-эчә:

— Дөресен әйтим, бик арыдым. Полковникны бер сәгатьтән артык эзләдем. (Шул вакыт Хәлимә ханым керде) Һа-а, Хәлимә ханым, сез бередәмени? Хафаларыгыз узар булсын, (узып китәр булсын) әйбәттерсез, шәт, иншаллаһ? Сезнең балаларыгыз, машаллаһ, яхшы эшли. Бер атна әүвәл мөдирләрен күргәнием. Эшләгәннәренә бик шат- мәмнүн булдым. Ничек булып чыкты, котылдыгызмы инде?

Әсма ханым:

— Нәрсә булды, берәр нәрсә бармы, Хәлимә ханым? Хәлимә:

— Баш китәрлек берни дә юк, «дипломсыз дәвалый» дип, вилаять мәркәзенә шикаять язганнар. Шуның аркасында судка куйдылар. Ул арада бер җандарм эфисәре килде, богау салып, мине вилаятькә алып китте. Менә шул хәл имеш-мимешкә сәбәп булды. Димәк, монда кадәр дә килеп ирешкән икән! Судта, үз файдама тырышмавымны, бары тик кулымнан килгәне кадәр генә тыйбби ярдәмдә булганлыгымны ачыкладылар. Бистәбездән бик күп шаһит килде. Нәтиҗәдә акладылар.

Доктор:

— Кара син  бу хәлгә, ә! Шушы хатын йөзләрчә хасталарны савыктырды... Гыйльми тәрбиясе дә безнең мәктәпне тәмамлаган яшь докторларыбызның күбесенкеннән артык... Америкада булса, аңа хәзер үк докторлык дәрәҗәсе бирерләр иде. Монда исә богаулап судка өстериләр.

Хәлимә:

— Наданлык! Башка берни дә түгел! Жандарм эфисәре дә үзенчә эш күрсәтергә тырышкан була инде. Иң кызыгы да шунда ки, шул вакыйгадан соң ике ай узгач, хатыны бала табалмыйча мөшкел хәлдә калды. Мине чакырдылар. «Дипломым юк, дипломлы әби тапсыннар», дидем, бармадым. Кабат килделәр, үтенделәр. «Җандарм эфисәре ни сәбәпле чакырганлыгы турында ап-ачык итеп язып, мине чакырсын, шунда килермен», дидем. Хат китерделәр... Карадым,  имзасы-фәләне юк... «Рәсми кәгазьгә язсын да имзаласын» дидем. «Анысын эшли алмыйм. Хатыным үлсә, доктор ярдәме күрсәтелмәде, дип сине судка куячакмын» дигән... Мин дә игътибар итмәдем. Ике сәгатьтән соң рәсми кәгазъ белән килделәр. Мин дә тиз генә киттем. Хатыны бик хәлсез иде. Аллаһ ярдәм итте, тап-таза бер ир бала дөньяга килде, хатыны да савыкты. Бүләкләр, рәхмәтләр бер-бер артлы ява торды. Бүләкләрен кире җибәрдем. Бирегә килер алдыннан хатыны кулымны үбәргә килде.

«Хуҗаханым гафу ит» диде. Табигый ки, гафу иттем, әмма әйтәсемне дә әйттем. Эшләр кулай түгел. Мәктәп тә бар. Әма минем Мәшрутият дәверендәге хезмәтләремне санга сукмадылар. Шул сәбәпле,  сигез еллык хезмәтем бушка китте. Хәлбуки, мөгаллимлектән  пенсияга китәргә кирәктер.

Чәй мәҗлесе бик яхшы узды. Мөгаллимнең угылы пианинода уйнады. Бала-чага җырлады. Кызлары үзара пышылдашып  алганнан соң, берсе пианино янына килеп, «Сызла»ны уйный башлады.

Җаһидә:

Сызла, сызла, сызла күңелем!
Сызла бертуктамыйча,
Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча...

Җырның азагына чаклы җырлады. Һәркем тәэсирләнеп тыңлады.
Һәркем «машаллаһ, афәрин» диде...
Доктор:
— Ярый, кызым, син башка җыр беләсеңме? Җаһидә:
— Юк, бу иң ошаганы булды да, шуңа өйрәндем. Доктор:
— Ни өчен ошаттың? Җаһидә:
— Каян белим, минемчә, бу сезнең мохитнең рухи халәтенә бик туры килә, ничек дип әйтим, бик тә характерлы.
Доктор:
— Тагын да дөресрәге, хиссиятемезне иң дөрес аңлатучысы бу шигырь.
Җаһидә:
— Әлбәттә, шулай. Доктор:
— Шуңа күрә дә, бөтен Идел-Урал мәйданында бу шигырьне сөйләмәгән, бу көйне көйләмәгән кеше юктыр. Хәлбуки, аның чыкканына утыз ел да юктыр әле. Шушы бер шигырь шагыйрьнең исемен мәңгеләштерде. Халыкка якынайтты. Хәзер бер төрек шагыйренең Төркиянең һәрбер авылында укыла торган, җыры җырлана торган берәр шигырен беләсеңме? Юк... Ни өчен? Чөнки ул шагыйрь Истанбул баласы, ул халкының матди, мәгънәви барлыгын, мәгънәсен аңламый. Халык тойган шатлыкны, аның хәсрәтен тоймый. Биредәге шагыйрьләр белән безнең шагыйрьләребез арасындагы төп аерма шундадыр. Бу хәл әдәбиятның башка өлкәләрендә дә шулай. Биредә мәмләкәтнең һәр тарафында уңыш белән уйналган берәр драма, берәр комедияне беләсезме? Юк... Ни өчен? Чөнки биредәге театр әсәрләренең барысы да французчадан, инглизчәдән, алманчадан тәрҗемә яки күчермәләрдер, аларның һичбер милли төсе, милли тәме юк. Китапчыларга барып карасаң, йөздән туксаны тәрҗемә!... Аларның барысы да рухан һәм мәгънәви ят әсәрләрдер. Бу нидән килә? Илебездә мондый әсәрләр бик күп. Чөнки андагы хәрәкәт халык халык өчендер. Бу халыкның бөтен әһелләре аерым ырудан, аерым каннан булган халыклар. Биредәге халык исә космополит тәрбиядә. Албан, бушнәк, көрт, гарәп, рум, әрмән белән теректән болгатылган боламык хәлендә. Космополит мохитта мәдәни хәят тәрәккый итә алыр, әмма милли культураның үсеше, алгарышы өчен милли кысалар булырга тиеш... Мондагы шомлы афәтнең нигезе шулдыр ки: терекнең милли мохите юк... Бу шартларда моны булдыру да мөмкин түгел.
Мөгаллим Фәхри калыкты:
— Барыгызга дә рәхмәт (кесәсеннән бер кәгазъ чыгара-чыгара). Шикәр бәйрәмендә җыйган сиксән бер лира акчаның нәрсәгә сарыф иткәнлегемне укып чыгам.
Ханымнар:
Кирәкми, Фәхри бәй, беләбез. Фәхри бәй:
— Зарары булмас, укыйм, тыңлагыз. Укучылар өчен күлмәк-фәлән, фәлән кадәр, яңадан мәктәпкә кергәннәр өчен, юл акчасы шулкадәр, ашарга тотылган: шулкадәр, китапка шулкадәр... Сез шикле берни дә әйтмисез, әмма: «Акчаларның хисабы кайда? Ихтимал, үзе тотып бетерә торгандыр», дигәннәр дә аз түгел. Хәзер Пәндигә китәм. Безнекеләрдән су мөһәндисе Габдрахман шундагы җәйлек өенә киткән. Аны тотып, балаларга биш-ун лира алалсам, начар булмас иде. Кызык, хәзер поезд бармы икән?
— Бу вакытта поезд була әле,- диделәр.
Мөгаллим һәр кеше белән аерым-аерым хушлашып, чыгып китте. Мөһәндис:
— Бу кеше, биш еллап булыр, һич армыйча бала-чага мәшәкатьләре артыннан чаба... Моның кулыннан узмаган һичбер мөһаҗир бала юктыр. Берсен мәктәпкә җирләштерә, берсенә чыгарылыш имтиханнарын җайлый, берсенә китап табып бирә, берсенә акча таба... Ул булмаса, алар белән кем маташыр иде икән?
Доктор:
— Бу - халкыбызның гадәтедер... Анда һәр мәхәлләдә шундый фидакарь берәрсе табыла иде түгелме? Бездә аның кеби эшләр майтара торган вакыф та, хөкүмәт тә юк.

Шуңа күрә, гавам үзе өчен үзе тырышырга мәҗбүр. Халык та үз эченнән шундый хәерле эшләр башкаручы шәхесләр тәрбияләп чыгара.

Хәлимә:

— Әлбәттә, бездә һәр эш шәхси фидакарьлеккә генә корылган. Әнә шул Бубилар, шул Хөсәеновлар... Аларның һәрберсе фидаи миллиятчеләр (милләт өчен үзләрен корбан иткән кешеләр). Беренче бөтен дөнья сугышында (урыска әсир төшкән) шул төрек офицерларын унарлап, йөзәрләп качырып коткарган, шуңа күрә, Русия мәмләкәтендә үлем җәзасын үз күзләре белән күргән шул фидаиләр түгелме? Йәнә Дөнья сугышы вакытында урысларга әсир төшкән утыз меңнән артык төрекне тәрбия иткәннәр фидакарьләр түгел идеме? Әгәр безнең әсирләребез белән мәшгуль булган «Швециянең Кызыл ай җәмгыяте»нең рапортларын укыган булсагыз, Русиядәге татарларның никадәр фидакарьлекләр белән аларны ачлыктан, үлемнән коткарганлыкларын үз күзегез белән күрер идегез. Ләкин аянычы шул ки, бу әсирләрнең берсе дә шуннан исән чыгып та, бу турыда язмады. Безгә төрле большевик гәзитләре һөҗүм иткән чакта да һичберсе яклап чыкмады...

Вакыт соң иде инде. Бөтен кунаклар да үз юлы белән китте.

Мөһәндис Вахитнең гаиләсе дә төн уртасында гына кайтырга чыкты.

Икенче көн матур гына узды. Җаһидә янә китаплар белән мәшгуль булды, балалар белән диңгезгә су коенырга төште. Атасы белән кичә күргән кешеләр хакында сөйләште, аның фикерләрен тыңлады. Өйлә ашы да вакыйгасыз, кунаклардан башка гына узып китте. Каһвә көткән арада бер хәрби кеше мөһәндис бәйгә бер хат китереп тапшырды. Атасының имзасын алды да ул чыгып китте. Хат букчасын ачкач, Вахит бәйнең йөзе бераз үзгәрде, иренең хәрәкәтләрен күзәтеп торучы Хәдичә ханым:

— Тагын юлга чыгаргамы?- диде. Кәгазьне алды, укыды...

— Һич тә рәхәтләнеп ял итәргә бирмиләр.(Җаһидәгә) Безнең тормыш гел шулай инде. Менә хәзер атаңны Тракия юлларын тикшерү коммисиссенә рәис итеп куйганнар. Кайчан китәчәксең?

Вахит:

— Белмим. Бүген бүлек җитәкчелегенең идарәсенә барырга кирәк.

Мин хәзер Истанбулга китәм.

Хәдичә:

— Ялың ике атна да булмады бит, тагын китәсең. Кайчан кайтырсың икән? Кайтканда һавалар ничек булыр инде? Син үзең дә баш тартмыйсың. Башка берәү булса, юлларын табар иде.

Вахит:

— Без бирегә хөкүмәтне алдарга дип килмәдек, нинди әмер-боерык булса, шуны башкарырга бурычлыбыз.

Аягүрә басты. Истанбулга китәргә җыена башлады. Бу вакыйга барысының да кәефен кырды... Хәдичә ханым да ире артыннан чыкты...

— Юлга ни хәзерлим икән? Сәфәрең озакка сузылырмы? Вахит:

— Хәзергә берни дә әйтә алмыйм. Миңа калса, атна-ун көн узар.

Бүген ахшамга кайтырмын,- диде дә китте.

Ахшамга кайткач:

— Иртәгә кичке поезд белән Әдирнә шәһәренә китәбез. Миңа моннан бишенче биш минуттагы көймә белән китәргә туры килә.., - диде.

Бөтен кич һәм икенче көннең иртәсе юл хәзерлеге белән күңелле узды. Ашаганнан соң мөһәндис Вахит Җаһидәне читкәрәк тартты:

— Менә, кызым, эшләр шулай тора, синең белән озаклап күрешеп, озаклап сөйләшеп тә булмады... Кайткач, иншаллаһ, вакыт булыр. Әлбәттә, син монда бит. Ләкин, кызым. Анаң белән мөнәсәбәтеңне рәтлә. Үзен күреп, хәлне аңлат. Аның кулыннан кызын тартып алырга теләмибез, әмма кызыбызның бездән ераклашуын да теләмибез. Дарелфөнүн мәсәләсенә килгәндә, кергәнең яхшы булыр, минемчә. Синең укый торган чагың узмаган

эле. Һәвәсең дә бар, сәләтең дә... Син дарелфөнүнгә керергә тиеш. Минемчә, сиңа әдәбият кулайрак булыр. Бәлки «Уртак төрек әдәбияты» хакында үзеңә бер юл ачарсың. Анысы да зур хезмәттер. Әниеңне күндерергә тырыш. Чыгымнар миннән. Фәкать бер шартым бар, кызым. (Җаһидә атасына бакты) Укыган вакытыңда анаң белән бергә торырсың.

Җаһидә һичбер сүз әйтмәде. Мөһәндис Вахит өстәп куйды:

— Бу сиңа: безнең белән яшәмә, дигән сүз түгел, моны ялгыш аңлама. Фәкать, анаң өчен уйланырга тиеш булган бер комбинация генә... Дәресләрдән соң ашыңны бездә ашарсың. Аннан соң Лаләли бистәсендә без бер өй таптык, кичләрен анаң янына кайтырсың. Ул

«ялгыз калдым» дигән уйга батмасын. Аңладыңмы?

— Ярый, атам! Анама карата син бик тә киң күңелле, их, үз вакытында ул да сиңа карата шулай булган булса иде.

Вахит:

— Син анаңны тәнкыйть итмә, кызым. Син аңламаган нәрсәләрнең дә булуы ихтимал бит. Буласы булган инде. Яхшы киләчәгең өчен сиңа бер идарәче, ягъни синең эшләреңне җайлаучы бер кеше кирәк. Аңладыңмы? Кабат анаңнан качма. Синең бу кыланышың анаңа каршы итагатьсезлек төсен алмасын. Берәр нәрсәгә ихтыяҗың булса, тутаңа сөйләрсең. «Мәсьәләне үзем хәл итәрмен» дидем, әмма анаң тарафыннан хәзер беркем дә юк, агаларыңны мин хөрмәт итмим, аларның сүзе миңа үтмәс. Элек анаңның бер агасы бар иде, ул бераз фикерле адәм иде. Вафат булган чагында ул әйтте: бу авыр вазифа синең яшь җилкәңә йөкләнә, диде.

Йөкләнгән вазифаның, чыннан да, физик авырлыгы бар кебек, Җаһидәнең муены бөгелеп төште, берни дә әйтмәде.

Аталарының китүе бөтен бала-чагага күңелсез тәэсир итте. Барысы да көймәгә хәтле озата барды. Әмма мөһәндис Вахит Истанбулга барырга берсенә дә рөхсәт итмәде.

Ахшам ашы күңелсез узды. Хәдичә ханым тормышларының гел шулай узганыннан бераз зарланып та алды. Балалар да аналарын юаткан кебек, пышылдап кына сөйләште. Икенче көнне өйләдән соң Җаһидәнең фасыллы пәлтәсен киеп-таманнарга дип Истанбулга барырга карар итеп, бүлмәләренә кереп киттеләр.

***

Җаһидә Адага китеп бер атнадан артык вакыт узганнан соң бер тапкыр да анасын күрмәде. Бер тапкыр кайтты. Очрата алмады, көтеп тормады, икенче тапкырында хат язып калдырды һәм тагын почта аша бер хат язып салды. Моңа кадәр Җаһидәнең анасыннан бу кадәр озак вакытка аерылып торганы булмады... Шуңа күрә, Мәләхәт ханым

«Аптыраш, Җаһидәгә бер-бер хәл булдымы?» дип иртән иртүк ашамлыклар кибетенә шылтыратып Җаһидәне, йәки мадам Марикане чакырттырды. Телефонга мадам Марика килде:

— Мәрхабә, мадам Марика!

— Мәрхабә, Мәләхәт ханым... Мәләхәт:

— Безнең Җаһидәнең хәле ничек анда? Мадам Марика аңлата башлады:

— Җаһидә бик һәйбәт, күрсәгез икән, түгәрәкләнде, гүзәлләр гүзәле булды ул, шикәр кебек, бик тә татлы кыз булып китте. Беләсезме, Җаһидә атасын тапты бит... Атасы иленә кайтып китмәгән икән. Анадолуда булган, имеш. Моңа кыз шулкадәр сөенде ки... Алар да Җаһидәгә ниләр генә бүләк итмәделәр. Алтын сәгатьләр, алтын беләзекләр, ул йөзекләр, ул алкалар, ул күлмәкләр... Җаһидә сарай хатыны кебек булды. Ул атасын күрсәгез, никадәр игелекле адәм икән ул...

Мәләхәт:

— Җаһидә кайда хәзер?

— Җаһидә аларда, барысы да бергә. Кечкенә туганнары бар, бик тә татлы балалар... Бергәләшеп ашыйлар. Бергәләшеп эчәләр. Бергәләшеп кунакка йөриләр. Җаһидә шулкадәр канәгать ки...

Марика тагын да озак сөйләгән булыр иде, әмма Мәләхәт ханым аның сүзен кисеп:

— Мадам Марика, мин шылтыратканны Җаһидәгә әйтмә, - диде дә телефонны куйды.

Шундый да хәбәрне Марика ничек әйтмәсен, ди, әлбәттә, әйтәчәк, әмма Җаһидә кайда соң үзе? Күрше бакчасына карады - юк. Бәлки диңгезгә киткәннәрдер. Кызганыч ки! Анасы ничек сөенде, диде ул авыз эченнән генә.

Мәләхәт ханым кызы хакында хәбәр алуга боз кебек булды, тамырларыннан кан качкан кебек булды. Бизгәк тоткан кебек калтырый башлады. Йөгерә-чаба пристенгә төште. Беренче көймәгә менде. Хәйбәли присенендә төште. Туры Мариканың өенә китте. Вакытыннан элек картая башлаган бу хатын бүген Марикага үлем фәрештәсе кебек күренде. Күзләре эчкә баткан, күз нуры сүнгән, иреннәре зәп-зәңгәр. Хәл-әхвәл сорар-сорамас:

— Җаһидә кайда? - диде. Мадам Марика:

— Кайтмады әле,- дигәнен дә көтеп тормастан, тиз генә Җаһидәнең бүлмәсенә менеп китте. Мариканың сүзләренә колак салмыйча, күзләре белән тирә-ягына сөзеп бакты... Җаһидәнең күлмәген күрде. Тотып карарга теләмәде, әмма хатын-кызның кызыксынуы өскә чыкты. Югары сыйфатлы итеп тегелгән өр-яңа күлмәкләрне җентекләп, дикъкать илә күздән кичерде. Мадам Марика да бу кызыксынуны көтә иде булса кирәк:

— Бакчы, Мәләхәт ханым, эчке киемнәре нинди, барчасы ефәк..,- дип тартманы тартып чыгарды да, күлмәкләрне берәм-берәм күрсәтә башлады, аннан соң оекларга ымлады:

— Хәзер боларның бәһасе күпмедер, кем белә. Алтышар пар алдылар. Йә, аяк киемнәрен күрсәң... Торып-тор, менә беләзеге...

Мәләхәт ханым эчтән бер нәфрәт тойса да, хатын-кыз кызыксынуы белән барысын да карап чыкты. Өстәл өстенә күз ташлады. Иске хәрефләр белән басылган берничә татарча китап... Ялгыз калыр өчен:

— Мадам Марика, син Җаһидәне көтеп тор. Кайтуга ук монда чакыр, ләкин килгәнемне белгертмә, - диде.

Марика:

— Кайтсалар, моннан күренеп тора, алар әнә шул күрше йортта тора. Һәрвакыт бакчада ашыйлар-эчәләр... Ярый, мин карап килим, -дип чыгып китте.

Мәләхәт ханым ялгыз калгач, тагын бер кат бүләкләрне карап чыкты. Бу кадәр күп күлмәкне Җаһидәнең үз гомерендә күргәне юк. Ул сәгать, ул йөзек, ул бизәнү әсбаплары, ул халатлар, ул яңгырлык- ябынчалар... Димәк, болар бик бай. Тартма актарганда аның күзенә саклык кенәгәсе чалынды. Ачты. Җаһидәнең сабый чактагы рәсеме, аның исеме. Кулында болай әйләндерде, тегеләй борды. Язылганнарны укыды. Чынлап та, бу саклык банкасының дәфтәре иде. Җаһидә исеменә язылган. Ие, андый дәфтәр электән дә бар иде. Мөһәндис белән яшәгән чагында үзенә калдырып китә торган иде. Ул да аннан кирәге чаклы акча ала иде. Саный башлады. Очына чыга алмады. Соңгы битен ачты... Берничә мең лира... Бу - Җаһидәнең акчасымы?

Күрше бакчада тавышлар ишетелә башлады. Мәләхәт ханым пәрдә артына посып, күрше бакчаны күзәтә башлады. Җаһидә белән җитәкләшкән кечкенә кызлар... Җаһидә җыйнакланган, йөзе алсуланган, тирә-якка нур чәчеп тора. Марика Җаһидәне чакырды. Бер мизгелдән соң Җаһидә анасы каршысында басып тора иде. Һич көтелмәгән бу хәлдән Җаһидә шашып калды: «Анам» диде, башка бер сүз дә әйтә алмады. Мәләхәт ханым кызына сөзеп карады:

— Син нишләдең,кыз? - диде.

Бу кырыс сөаль Җаһидәне сискәндерде:

— Анам, мин берни дә эшләмәдем, гаиләсе белән атамны таптым. Мәләхәт:

— Мин сине шушының өченме тәрбия иттем, шуның өченме тормышымда фидакарьлек кылдым, оялмыйсыңмы?

— Аннәм, мин сиңа зарар китерә торган берни дә эшләмәдем. Оялырдай бер эш тә юк (анасының кулын тотты). Син кызма, аннәм, сиңа каршы һичбер шәй юк. Бары тик мин атамны таптым.

Мәләхәт ханым елый башлады:

— Син минем бөтен гомерем буе булдыра алганча кылган фидакарьлекләремне юкка чыгардың. Синең тәрбияң өчен, сине асыл итәр өчен сарыф иткән көчемне бушка санадың. Яңадан шул искергән татар мохитенә килеп егылдың. Мине тагын бер тапкыр хур иттең.

Җаһидә:

— Аннә, мин беркемне дә хур итмәдем. Бигрәк тә сине беркайчан да хурлыкка калдырмадым. Арабызда берни дә үзгәрмәде, син минем анам, мин синең кызың... Элек ничек булса, хәзер дә шулай. Ләкин элеккедән бер генә аермасы бар, мин атамны таптым. Аталы булуның никадәр олы бәхет икәнен аңладым мин. Башка бер үзгәреш юк...

Мәләхәт:

— Йә, шулкадәр михнәтләр белән тәрбияләп-үстергән бердәнбер баламны мин шуларга бирергә тиешме? Шул йолкышларга бөтен ягы камил кызымны сатарга тиешме мин? Юк,юк... Хәзер үк өйгә кайтып китәбез. Алар белән араңны өз...

Җаһидә елый башлады:

— Аннә, мин хәзер кардәшләремне таптым (тәрәзәдән күрсәтеп), аларның барысы да минем туганнарым. Мин аларны яраттым, алар да мине ошатты. Бу табигый эш, аннә. Син агаларымны яратасыңмы?

Аларның хәтере өчен синең ниләр эшләгәнеңне мин беләм бит. Минем дә үз кардәшләремне сөяргә хакым бармы, юкмы?

Мәләхәт:

— Алайса, аларга күч, ул чакта син минем кызым түгел. Җаһидә:

— Ничек итеп мин синең кызың түгел,ди? Уйлап бакчы, аннә, бу мөмкин эшме?.. Аннан соң минем дә аларга күчеп китәргә ниятем юк. Ләкин, алар белән булган мөнәсәбәтемне өзәргә дә көчем җитмәс.

Ул арада ишек ачылды, Гөлчәчәк керде:

— Апа, әни икегезне дә чәйгә чакыра, пәрәмәч пеште!.. - диде. Җаһидә:

— Шикәрем син, минем аннәм килде, без бераз сәйләшәбез, сез барыгыз, мине көтмәгез... Мин аннәм белән Марикада янында ашармын,- диде.

Гөлчәчәк аптырап чыгып китте. Җаһидә үзен кулга алды:

— Бу очраклы гына килеп чыкты. Мин аларны үзем эзләп тапмадым. Көймәдә шушы кечкенә кызларны очраттым. Менә мәсьәлә шуннан гыйбарәт. Синең турыда һичбер кемнән хөрмәтсез сүз ишетмәдем. Киресенчә, атам кичә юл эшләрен тикшерергә китәр алдыннан: «Җаһидә, анаңны борчуга салма, сиңа карата аның хакы зур. Синең атаңны табуың табигый, әмма анаңа итагатьсез мәнәсәбәттә булма. Мин дә моны кабул итмәм... « диде.

Кулыннан коралы тартып алынган дошман кеби, Мәләхәт ханым:

«Нишләмәк кирәк?» дип уйга талды. Аның дәшми утырганыннан сүзләренең аңа тәэсир иткәнен аңлап, Җаһидә дә тын калды. Тирән тынлыкка чумган мохиткә Хәдичә ханым килеп керде:

— Гафу итегез, Мәләхәт ханым! Бу вакыйгага чаклы бер-беребезне күрмәгән булсак та, бер-беребез хакында байтак нәрсә беләбез. Мин Җаһидә кардәшләренең анасы буламын...

Кулын сузды. Җаһидә аягүрә басты. Мәләхәт ханымның йөзенә олы хәсрәт чаткысы чыккан иде, теләр-теләмәс кенә ул да кулын сузды.

Хәдичә:

— Бик үтенәмен, Мәләхәт ханым, балалар бүген бик теләп, апалары Җаһидә ярата торган ризык пешерделәр. Сез килгәнне хәбәр иттеләр. Сезне дә безнең белән берәр тустаган чәй эчәргә зинһарлап чакырырга кердем. Мин сезнең халәтегезне бик яхшы

аңлыйм, Мәләхәт ханым, сабыйларның хәтере өчен генә булса да, чакыруымны кабул итегез... Аталары юл тикшерергә китте, беркем юк... Ни әйтсәң дә бала бала инде ул. Олылар арасында булган аңлашылмаучылыклар аркасында балалар ни өчен хәсрәт чигәргә тиеш? Беләсез бит, балалар бездән дә хисчәнрәк. Вакытыннан алда мәгънәсез шәйләрне ни өчен алар алдында ачып ташлыйк.(Мәләхәт ханым көтелмәгән хәлдән аптырап калды, ни әйтергә дә белмәде.)

— Күп рәхмәтләр, мин иртәнге ашны ашаган идем инде,- диде. Хәдичә:

— Беләм, мәсьәлә ашау-эчүдә түгел, Мәләкәт ханым, балаларның бергә булулары өчен бер табын янында сезнең дә булуыгыз зарури. Балалар бер-берләренә шулкадәрияләште ки, хәзер аларның арасы киселсә, сабыйлар рухына начар тәэсир итәчәк. Җаһидәне теләгәнегез җиргә җибәреп, теләмәгән урынга җибәрмәү сезнең хакыгыз. Чөнки аны сез үстергән. Сез тәрбия иткән. Һәм дә шулкадәр яхшы тәрбия иткәнсез ки, безнең барыбыз да сезнең бу хезмәтегезгә хәйран калучылар булдык. Мин дә ана кеше, бала үстерүнең никадәр авыр икәнен беләмен. Ләкин очраклы гынамы, дип әйтим, юкса, бөек бер илаһи кодрәтнең ихтыяры, дип әйтимме, бу балаларның танышып, кушылуларыннан шундый бер халәт килеп чыкты ки, ике тарафка да хәсрәт китермичә генә моңа йомгак ясарга мөмкин дә түгелдер. Минемчә, ана хиссияте булган бер генә хатын да балалар мәнфәгатенә каршы бармас. Шуңа күрә, Мәләхәт ханым, бик үтенәмен, зинһар, чакыруымны кабул итегез, яңа хәлне бозмаска тырышыйк. Моның шулай булачагы тәкъдирдәдер, без - гаҗиз коллар, бу тәкъдирне үзгәртә алмаганыбыз кебек, бары тик кирәкле-кирәксез хәсрәтләр китереп чыгармасак иде.

Җаһидә бер анасына, бер Хәдичә ханымга багып, бу гаиләгә аерым ике ноктадан караган, дөньяны аңлау дәрәҗәсе ике төрле булган ике көндәш хатынның мәгънәви көрәшеннән ниләр килеп чыгар икән, дип карап тора иде.

Мәләхәт ханым да карашын идәнгә текәгән, бу мәгъкуль сүзләргә җавап бирерлек куәт табалмаганнан, ике ут арасында изалана иде.

Хәдичә ханым Мәләхәт ханымның дәшмәвен ризалашу дип аңлады:

— Тәшәккүр итәмен, Мәләхәт ханым, боерыгыз, китәбез,- диде.

Мәләхәт ханым авырлык белән урыныннан торды, карашы көзгегә төште. Кипкән балык кебек ябык гәүдәсеннән, җан әсәре калмаган чыраеннан куркып китте. Нидер эзләгәндәй, карангалап алды. Өстәленнән алып, Җаһидә анасының кулына хушбуй сипте... Мәләхәт ханым кулын-йөзен сөрткәләде. Берни әйтмичә, әкрен генә ишеккә таба китте. Бер ягында Җаһидә, икенче тарафында Хәдичә ханым йөреп, ишектән чыктылар. Хәдичә ханым теленә ни килде, шул турыда сөйләнә башлады.Чәй янына килгәндә балаларына:

— Бу - апагызның әнисе - тутагыз булыр,- диде.

Балалар Мәләхәт ханымның кул аркасын үпте. Мәләхәт ханым балаларны бер-бер артлы күздән кичерде. Чират ир балаларга килеп җиткәч, төртелеп калгандай:

— Минем дә бер угылым буласы иде,- диде.

Шуннан соң: «Бу хатын урынында мин хуҗа булырга тиеш идем. Мин үз тәкъдиремә үзем китереп типтем... Менә, соңгы балам да китә», дип уйлады.

Балалар үзара сәйләшә башлады. Җаһидә дә алар сүзенә катнашып китте. Шулай итеп, гүя, анасы барын да онытты кебек.

Хәдичә ханым да Мәләхәт ханымга туктаусыз сөйли, еш-еш кыстый иде. Чыннан да, Мәләхәт ханым пәрәмәчне бик ошатты. Берсе артыннан икенчесен ашый тора, чәй эчә. Шулай итеп, ул чит-ят мохиткә ярашырга тырыша. Өзлексез рәвештә ул үз фикерләрен рәткә китереп утыра иде.

Балалар иртәнге ашны тәмам итеп, табын яныннан китте. Җаһидә борчулы бер халәттә, ни кылырга белмичә, анасы белән тутасы арасында утыра, үзе качып китәргә форсат көтә иде. Бу форсат бик тиз килеп чыкты.

Балалар:

— Апа! - дип аны чакырып алдылар.

Ул да китте. Көлә-көлә балалар белән куышлы уйный башлады. Хәдичә ханым Җаһидәгә күрсәтеп:

— Багыгыз, Мәләхәт ханым! Җаһидә лисә бетергән, әмма рухан әле сабыйдыр. Багыгыз, сабыйлардан ул никадәр ләззәт ала. Хакы бар. Ялгыз үскән, ялгыз яшәгән... Хәзер аның сабыйлыгын бозу язык түгелме? Килсен, тагын бераз сабыйларча яшәсен... Килер вакыт, хәят бу зәхмәтне, мәшәкатьне үзеннән үзе ачыклар... Димәк, мин шуны телимен ки, Җаһидәнең бирегә килүенә, күңел ачуына рөхсәт бирегез. Күңеле теләгән вакытта килсен. Атасына «дарелфөнүнгә керергә телимен, син ничек уйлыйсың, бәй атам?» диде. Атасы: «Анаң ничек уйлый, әүвәл аның фикерен-рөхсәтен алырга тиешсең» диде... Җаһидә зиһенле кыз. Гыйлемгә омтылышы бар. Мәләхәт ханым, ун көн дәвамында мин аңа дикъкать иттем, машаллаһ, һәрнәрсәне шундук отып-аңлап ала. Әмма бик яшь әле.

Балалар арсында шау-шу купты. Бөтен бакчаны каһкаһәле көлеш тавышлары яңгыратты. Араларында иң нык көлгәне Җаһидә иде.

— Карагыз, Мәләхәт ханым, ул әле сабый гына. Үзе үскән, әмма рухы сабыйларча. Ул әле гаилә корырлык түгел. Минем бу эшләргә катнашырга хакым юк, әмма дәрелфөнүнгә керсә, мин бик тә канәгать калыр идем. Насыйбы булып, бер кияү табылса, никах өчен дипломның кирәге юк. Ләкин тормышны аңламаган көе яшь бер кызны кияүгә бирүләреннән яхшы нәтиҗә көтмимен. Никахлашу өчен хатынның да фикере өлгергән булуы зарурдыр.

Мәләхәт ханым бераз ачыла төште. Ара-тирә ике-өч кәлимәлек җөмләләр белән җавап кайтара башлады. Хәдичә ханым шуңа канатланып, атасының киткәндә Җаһидәгә:

— Дарелфөнүнгә керүеңне хуплыймын. Чыгымнарын да үз өстемә алырмын, әмма шушы шарт белән: анаң белән бергә яшәргә тиешсең, - дигәнен сөйләде.

Мәләхәт ханым элеккеге иренең исемен әйтмичә генә:

— Ул һәрвакыт киң күңелле булды. Бернигә дә карамастан, миңа карата киң күңеллелеген һаман саклап килә икән, - диде.

Ул карашын җиргә текәде дә, күзенә килеп тыгылган яшьләрен тыяр өчен бөтен көчен куеп тырыша иде. Ул инде җиңелгән иде. Хәдичә ханым сүзне икенчегә борды. Ул үз вазифасын башкарып чыкты. Мәсьәләнең җитди әһәмиятен аңлатты, Җаһидәгә иркенлек хәзерләп куйды.

Шулай итеп, Мәләхәт ханым монда калырга булды. Җаһидә йөгерә-чаба анасы янына килде. Ана белән кыз әкрен генә Җаһидәнең бүлмәсенә кереп киттеләр. Буран инде узып киткән иде. Җаһидәнең халәте үз эзенә кайтып төште. Җаһидә Адада калырга булды. Алда килеп чыгачак мәсьәләләр дә үз юлына төшәчәк кебек иде.Көймәгә озата төшкәч, Мәләхәт ханым хөрмәт илә Хәдичә ханымның кулын кысты да җиңүче хәлендәге хуҗабикәгә:

— Җаһидәгә күрсәткән игелекләрегезгә чын күңелдән рәхмәт әйтәмен, Хәдичә ханым!- диде.

Ул көймәгә таба китте. Башы иелде, буе бераз тәбәнәкләнеп китте кебек. Йөзенә үлем куркусы кеби бер курку чыкты. Көймә киткән вакытта Җаһидә болгаган кульяулыкны күргәч, анасы кызын югалткан кебек хис итте.

Әлбәттә, Җаһидә аның белән яшәячәк... Әмма тәне белән генә яшәячәк иде, аның рухы бирердә, шушы сабыйлар янында булачагы көн кебек ачык иде.

Мәләхәт ханым:

— Бу да тәкъдирдер,- диде.

Ике күзеннән ике тамчы яшь чыгып, яңаклары буйлап аска таба тәгәрәде... Көймә кузгалып, ераклаша барды.

Моң шер – минем кадерлем

Мөһәндис – инженер

Каһвә – кофе

Юнанстан греөия

Харита – географик карта

Дәлаләт итү – өйрәтү, юл күрсәтү

Modus vivendi – вакытлыча килешү

тыйп – медицина

Хамам – мунча

Комач – бу урында: материя

Татил – каникул

Куруш – төркия акча берәмлеге: тиен

Мәфтүн – бик канәгать булу

Зарафәт – гүзәллек, зиһенлелек

Хәрарәт – канарлык

Дарелмөгаллимин – укытучылар хәзерли торган уку йорты

Дарелфөнүн – югары уку йорты, университет

Риязия – математика

Полис – полиция

Яугирләр – бу урында: ярдәмчеләр, адьютантлар

Тыйббият – медиөина факультеты

Мөһаҗир – чит җирләргә күчеп китүче

Лира – Төркиядә акча берәмлеге: сум

госманлы шивәсе – төрек теле

Шивә – тел, сөйләш

*гәзитәдә бу урында язу чыкмаган

Шимал төрекләре – тоньяк төреләр ягъни татарлар

Кылыч тагачак – бәлиг булачак

Комач – ачык кызыл төстәге материя

Кызма – ачуланма

Тәшәкүр – рәхмәт

**Татар кызы.** – Повесть 1930-1960 елларда Истанбулда нә- шер ителгән «Соң почта» («Соңгы почта») «көндәлек сәяси» гә- зитәсендә 1949 елның 29 сентябрь - 3 октябрь һәм 7 октябрь - 24 ноябрь саннарында (барлыгы 54 санда) төрек телендә, латин имлясында басылып чыккан. Төрекчә Текст ахырына: «Бетте, Истанбул, 5 сентябрь 1942» дип куелган.

Г. Исхакый Истанбулдан Анкарада яшәүче кызы Сәгадәткә 1949 елның 2 октябрендә язган хатында: Минем монда язган «Татарның кызы» исемендәге хикәям «Соң почта» гәзитәсендә чыга башлаган икән, шуның 4 номерасын сиңа күндердем»,- дип хәбәр итә. Язучы 1951 елда үзе төзегән әсәрләре исем- легендә бу әсәрен «роман» дип атаган.

«Татарың кызы» повестен том өчен язучы Рабит Батулла тәржемә итте.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 5 том. - Казан:

Татарстан китап нәшрияты, 2009. Б. 159-258

Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче

**Гайнанова** Лена Рәшит кызы